Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

04
апрель 2018
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ХАРИС ЯКУПОВ. «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСТӘЛЕГЕНӘ»

Нәүрүз – дуслык бәйрәме

24 мартта башкалабызның Казан ипподромында төрки халык вәкилләре катнашында Нәүрүз бәйрәме узды. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, татарстанлыларны әлеге бәйрәм белән котлап, Нәүрүзнең Дуслык бәйрәме булуын искәртеп үтте. «Нәүрүз – күпмилләтле республикабызның мәдәни муенсасындагы чын энҗе бөртеге», – диде ул.

Александр Эшкинин фотосы

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

04 (292)

апрель 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

42

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Габдулла Тукай**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Нурсолтан.** *О.Иванова*
10 **Мәскәү һәм татар дөньясы**
16 **Кулаткы укулары**
19 **Иске Пенәгәр: метрикаларда авылым язмышы.** *З.Нәҗметдинов*
24 **«Сәнәкчеләр» фаҗигасе.** *Г.Мостафина-Рәфыйкова*
28 **Татарларның Казакъстан дәүләт төзелешенә керткән өлеше.** *М.Кәримов*
31 **«Хатыннары тәрбияле булган милләт — тәрбияле...»** *Д.Гыйммранова*
35 **«Тюрк-татар дюньясына нур сачкъан Тукъай!»** *И.Кәрим*
40 **«Мусульманская газета»да Габдулла Тукай вафатына нисбәтле язмалар**

ТАТАР ГАМЕ

44 **Безнең заман каһарманы.** *Р.Батулла*
50 **Хаж сәфәре.** *И.Әхмәтҗанов*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

56 **Туган телен данлаучы шагыйрь**

ДИНИ МИРАС

58 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

64 **Тукай белән Дусай арасы.** *М.Әхмәтҗанов*
68 **Безнең Чыңгыз Айтматов.** *Р.Мирхәйдәров*
71 **«Бишектән үк иртә төшкәннәр...»** *И.Фазлуллин*
74 **«Яңгыр җиле» — шифалы җил.** *Э.Шәрифуллина*



68 БЕЗНЕҢ ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ.
Рауль Мирхәйдәров

80 ГАЯЗ ИСХАКЫЙ
(1878-1954)

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закиров
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-91)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

80 Гаяз Исхакый

ХӘТЕР САНДЫГЫ

86 Макс Гатау шигырьләре
88 Истә, һаман да истә!
90 Равил Шәрәфине беләбезме? *Ю.Сафиуллин*
91 Әз-мәз үзем турында. *Р.Шәрәфи*

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

94 Тарихи мизгелләрне мәңгеләштерүчеләр. *Ш.Мостафин*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

102 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 Татарстан Республикасының Милли китапханәсе
108 Ташкичүдә — «Мәрҗани» музее
111 Киез итекләр иле.

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Март*

Заказ №Е-659. Тираж – 1860 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.03.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Габдулла Тукай истәлегенә»**. *Харис Якупов рәсеме.*

Габдулла ТУКАЙ

(1886-1913)

ҮЗ-ҮЗЕМӘ

Телим булырга мин инсане гали[1],
Тели күңлем тәгали биттәвали[2].

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм,
Кырылмасмы вавы[3], валлаһе әгъләм? ■

---

[1]Инсане гали – бөек кеше.
[2]Тәгали биттәвали – туктаусыз югары күтәрелү.
[3]Кырылмасмы вавы – «вәгъдәм» дигән сүзнең баштагы «в»сы кырылса, «юк» дигән мәгънәдәге «әгъдәм» сүзе килеп чыга. Вәгъдә күп булса да, бар да бушка, юкка булмасын, дигән мәгънәдә (сүз уйнату).

НУРСОЛТАН

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Яңа санга кечкенә генә өзек әзерләп биргән саен, Ольга ханымның каләм көченә һәм иҗади батырлыгына сокланмый булдыра алмыйм. Тау хәтле мәгълүматны актарып, шундый киң манзаралы хезмәт тудыру, күп кенә тарихчыларыбыз да белеп бетермәгән детальләрне торгызу һәркемнең дә кулыннан килми. Бу трилогияне язу никадәр җегәр таләп иткәнен тәвәккәлләп тәрҗемәгә керешкән без фәкыйрегез генә түгел, китап битләрен актарган гади укучы да аңлыйдыр, дип уйлыйм...

Мөдәррис Вәлиев

Нурсолтан яраткан эскәмиясе янында туктап калды. Кыштан соң бакча бөтенләй ялангач-буш күренә икән. Узган елгы яфраклар әнә, каралып киткән пәрәвез җебе кебек, агач утыргычны һәм аның нәфис кенә бөгелеп килгән арка терәгечен уратып алган. Биредә тәртип урнаштыру өчен колларны җибәрергә кирәк булыр иде, тик ханшаның гадәти эшләр белән шөгыльләнергә вакыты юк, ахрысы. Нурсолтан авыр сулап куйды да бакчаның таш сукмакларыннан алга таба кузгалырга уйлаган иде, ләкин шулчак аның игътибарын җәелеп үскән бер куак итәгенә гүя ки кояштан чәчрәгән тамчылар кебек ачык-сары вак кына чәчәкләр

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2018) санында.

«түтәле» җәлеп итте. Нурсолтан хәтта кулларын чәбәкләп куйды: менә бу – могҗиза ичмасам! Кар, китәсе килмичә, җиргә җан-фәрманга ябышып, әле кайбер төшләрдә түң соры утраучыклар булып ятуын белә, ә болар шундый бәләкәй, әмма бик кыю сары гәрәбәдәй, бөтен дөньяга: «Яз килә, яз!» – дип аваз салу өчен, инде якты көнгә чыгарга өлгергәннәр! Яшь хатын алар янына чүгәләп утырды да, алтынсу бөртек-чәчкәләр белән бизәнгән куе яшел нык сабакларны коткару өчен, иске яфракларны нечкә бармаклары белән сак кына өзеп ата башлады, шул арада чәчкәләрнең мамыктай йомшак нәни генә «бүрек»ләреннән сыйпаштырып алды.

– Күлмәгегезне пычратып-буяп бетерәсез бит.

Арка ягыннан көтмәгәндә килгән тавыш-өн аны сискәнергә һәм бик тиз борылып карарга мәҗбүр итте. Ул үзенең җайсыз чүгәләгәнен онытып җибәргән икән, әгәр Ибраһим солтанның куллары тотып калмаса, аннары аягына басарга булышмаса, бәлки, егылып та киткән булыр иде. Тик торып баскач та, солтан кулларын бушатырга ашыкмады, хатын-кызның чит ир-атка ачылырга мөмкин булган бердәнбер хәзинәсе – күзләреннән игътибарлы карашын алмыйча, иңнәреннән тотып торуын дәвам итте. Нурсолтанның тыныч-аяз йөзенә кинәт кенә каурый болыт күләгәсе төшкәндәй булды. Ул, кашларын җыерып, кисәк кенә артка тартылды һәм, шул рәвешле, иңнәреннән ят кулларны сыпырып-кагып төшерде.

Нурсолтанның яраткан туганын һәм бердәнбер балачак-яшьлек дустын җуйган көннән бирле Ибраһимны күргәне юк иде. Аның авыр хатирәләрен, кайгы-сагышын искә төшерүче бу адәмне бүтән бер дә очратасы килмәде. Сарайда Шаһназ солтанның зәгыйфь ашказаны, үлеменә сәбәпче булган бирәнлеге турында ямьсез рәсми хәбәр тараттылар. Нурсолтанның беркайчан да мондый зур мәгънәсезлекне ишеткәне-күргәне юк иде, әмма тирә-юньдәгеләрнең барысы да Ибраһим шаһзадәнең шул әкиятенә ышандылар, ә ул, Нурсолтан, әлеге вакыйгалар артында зур җинаять ятканын тоеп, берни дә әйтмәскә булды. Ул үзе ашыкмыйча гына бу пычрак йомгакны сүтеп очына чыгарга теләде, әмма бу турыда уйлана башлауга, туганының явыз үлем белән соңгы тапкыр идәндә тарткалашып ятканы исенә төшеп, Нурсолтан аңын югалта яза иде. Ул килеп җиткәнче һәм Шаһназның салкын йөзен күкрәгенә кысып иңрәгәнче булган хәлләр әлегә барысы да куе томан пәрдәсе эчендә калды, бары тик өзек-өзек аерым күренешләр генә күз алдыннан китмәде. Ул вакытта бит ул бусагада катып калган Ибраһимны күрде. Аның битараф тавышы әле дә булса колагында яңгырап тора. Хатыны һәлакәтенә, имештер, ниндидер агу сәбәпче булуын сөйләве дә исендә. Йә, нишләп әле һәрвакыт шундый шат күңелле һәм бәхетле Шаһназ агу эчәргә тиеш, әллә аны бу адымга нәрсәдер яки кемдер этәргән, мәҗбүр иткәнме? Туганының үлеме турында куркыныч дөреслекне белгән хәлдә ни кылып була: ханның үзеннән тикшертүне сораргамы яисә, Аллаһның гадел хөкеменә ышанып, догалар белән генә юаныргамы? Ул, балачактан белгән догаларын укып, Аллаһтан киңәш тә сорап карады, ләкин кодрәтле Хөкемдар дәшмәде, шулай итеп, хатынны тагын да тирәнрәк шик-икеләнүләр упкынына ташлады. Авыр хатирәләреннән күпме генә котылырга теләсә дә, булган фаҗига һәр юлы үзен тагын да көчлерәк итеп сиздерә иде.

Менә әле дә, серле рәвештә вафат булган кыз туганының ире Ибраһим солтан каршысына килеп чыккач, аңының иң ерак почмагына яшерелгән кичерешләр янә яңарды. Кайчандыр Шаһназ, Ибраһим мине ярата, дип ышандырырга тырышкан иде бит. Әмма яраткан ир булырга тиешле солтан, хатынының үлем тырнагында бер чарасыз тилмереп ятканын күреп тә, үзен чамадан тыш сәер тотты. Ә инде шулчак бертуган агасының хатынына кул сузарга маташуы искә төшсә, бүген дә кызармас-

лык түгел. Ул, җирбит, Шаһназның җаны күкләргә ашып барган мизгелләрдә, Нурсолтанга мәхәббәтен аңлата язды! Никадәр генә тырышмасын, ханзадәгә, инде йөрәк түренә кереп урнашкан нәфрәтен җиңеп, хөрмәт күрсәтергә үзен мәҗбүр итә алмады хатын. Хәтта әдәп кагыйдәләре таләп итсә дә, аның белән ни сөйләшергә, ни аралашырга теләмәде. Ибраһимнан читенеп, Нурсолтан аны буш урын кебек урап узды да Мәҗлесләр залына юнәлде, әмма ир аның юлын бүлде.

– Ирегезнең бердәнбер туганына карата үзегезне бик матур тотмыйсыз түгелме, Нурсолтан? Нишләп әле миңа тиешенчә хөрмәт күрсәтмәскә булдыгыз? Әллә атагызның олысында Сезне күркәм гадәтләргә өйрәтмәделәрме?

– Юлымнан китегез, солтан, адым саен шул кагыйдәләрне бозучы белән әдәп-әхлак турында сөйләшеп торасым килми!

Ул яңадан әйләнеп узарга тырышып карады, ләкин Ибраһим, көлә-көлә, тагын аның юлын буды.

– Ачуыгыз чыкканда, күзләрегездә шундый усал утлар уйный. Сезнең нәфрәтле тавышыгыз миннән кала теләсә кемне куркытырга мөмкин. Тик мине түгел! Безнең уртак хатирәләр шулкадәр күп, Нурсолтан, җае чыкканда, алар турында сөйләшеп алу комачауламас иде, шулай түгелмени, кадерле киленкәй?

– Сезгә миннән ни кирәк?!

– Аз гына, бик аз гына, Нурсолтан! Миңа ягымлырак итеп каравыгызны, ешрак гәпләшүебезне телим. Безне бит уртак кайгы – мескен Шаһназыбызның үлеме берләштерә...

– Ул хакта сүз кузгатасы булмагыз! – Нурсолтан бәләкәй йодрыкларын йомарлады. – Вафат булган хатыныгызны табын яныннан китә алмый торган ачкүз итеп бөтен сарай алдында мыскыл итүегез җитмәдемени әле?! Сез хәзер дә аның кабере өстендә авыз ерырга әзер. Чынлап та аждаһа икәнсез, Ибраһим, Сезгә карасаң, адәм баласы булган анадан тугансыз, дип ышануы кыен!

– Телегезне тешләгез! – Солтан, авырттырганын да тоймаслык булып, яшь хатынның кулына ябышты. – Сез, Нурсолтан, һәрвакыт мине мыскылларга гына торасыз, бу яктан Сез туганыгыздан ерак китмәгәнсез, күрәсең! Ләкин вакыты килер, мин үземне хөрмәтләргә мәҗбүр итәрмен әле, шуңарчы сак булыгыз!

Нәфрәттән сулышлары кысылып, алар бер-берсенә карашып тордылар.

– Туганыгызның нигә үлүе турында алдагансың, дип гаеплисез мине. Әйе, Нурсолтан, мин алдадым! Әмма бөтен дөреслекне әйтеп бетерсәм, Шаһназ, хәзер җаны кайда гына – оҗмахтамы яки җәһәннәмдәме булсын, – сезгә бәддога укыр иде. Ышаныгыз, Шаһназның һәммәбезне дә оят тагарагына утыртуына караганда, үлемен шулай көлкерәк итеп тасвирлау безнең барыбызга да яхшырак!

– Оят?! Сез ни турында сөйлисез, солтан? Минем бәхетсез туганымны тагынниләрдә гаепләмәкче буласыз?

– Ай, бәхетсез кыз туганыгыз вак-төяктә генә гаепле булды, Нурсолтан! Ул каравылчы белән зина кылганда тотылды.

Әгәр күктәге бөтен күкрәүләр һәм яшеннәр хан бакчасына берьюлы орса, алар Нурсолтанны, мөгаен, Ибраһим сүзләре дәрәҗәсендә үк аяктан ега алмас иде. Кинәт телсез калып, ул ханзадәгә тамчы да ышанмый торган күзләрен төбәде, тегесе Нурсолтанның бу карашында ачык кына аңлатуны таләп итүен күрде. Ибраһим солтан шуны аңлады: Шаһназның үлеме гомерлек сер булып калуы яки инде иртәгә үк бөтен сарай буйлап гайбәт таралу ихтималы биредә, хәзерге вазгыятьтә, бары тик үзеннән генә тора. Ул чакта кемсәләр ханзадәнең күзенә карап кайгысын уртаклашкан булып кылансалар, артында ук бөтен валчыкларын җыеп чәйнәячәкләр.

– Ай, кадерле киленкәем! – Ибраһим үз тавышын кинәт кайдандыр читтән килгән кебек ишетә башлады һәм моңа хәтта үзе дә гаҗәпләнде. Хәер, аның тавышы менә хәзер нәкъ шулай яңгырарга тиеш тә иде, бу – имештер, йөрәге сызлавын көчкә тыеп торган адәм тавышы. – Шаһназны мин шулкадәр яраттым! Аның хакына Фатыймасолтанны бөтенләй оныттым. Кыз туганыгызга кыйммәтле бүләкләр бирдем, аны артык иркәләдем, кадерләп-назлап тоттым, ә ул аркама пычак кадады! Хатын-кыз хыялланырга мөмкин бар нәрсәне алса да, аңа болар гына аз тоелды. Таныргa тиешмен: аның сөяркәсе, Аллаһ каргаган ул сакчы, бик чибәр иде. Чырае матур бер малай, майлы күзләре исә Сезнеке кебек үк зәңгәр иде, Нурсолтан. Хатыным юлына ул ир-егетне, ахрысы, Иблис үзе чыгаргандыр, югыйсә, Шаһназның хыянәтен башкача аңлата алмыйм.

– Күзләре минекедәй иде, дисезме? – Бу сүзләрне инде хуҗасын тыңламый башлаган иреннәреннән көчкә сытып чыгара алды Нурсолтан. – Ай Ходаем, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел! Ул әлеге сакчыда Хөсәенне күргәндер... Йа кодрәтле Аллаһ, ничек моңа юл куя алдың?!

Яшь хатынның агарынып калган йөзеннән күз яшьләре инеш булып ага башлады. Ул, нәфис җилкәләрен бөкрәйтә төшеп, бер генә теләгем: яраткан туганымның түбәнлеккә төшү хурлыгы турында ишеткәнче, үлүем яхшырак булган икән, дип, үзенең сүзсез кайгысына чумып елый иде.

***

Ә ул арада хан сараеның Мәҗлесләр залына соңгы кунаклар җыелып бетте һәм инде менә-менә тантана башланырга тора иде. Сәрби ханша һаман тынычлана алмый. Дулкынланудан затлы алтын беләзеген тарткалый, шулай итә торгач, ул аны сындырып ук чыгарды. Ханымның тулы-симез йөзеннән, иннек-кершән катламында соры буразналар сызып, ишелеп тир акты. Ниһаять:

– Фатыймасолтан, җаным, – дип эндәште ул үз яныннан бер адым да китмәгән икенче килененә. – Мин Хәлил солтан өчен бик борчылам. Нурсолтан һаман күренми, ә, бәлки, чынлап та, бакчада ул берәр ир-ат белән очрашып ятадыр, ә? Моны тикшерергә беркемнән дә сорый алмыйм, Сез бит аңлыйсыз, иң мөһиме – мондый чакта чит-ят күзләр күрергә, оятсыз колаклар ишетергә тиеш түгел. Фатыймасолтан, үтенәмен, бакчага чыгып, Нурсолтанны залга алып кайтыгызчы, әгәр сез икәү килеп керсәгез, бу шулкадәр табигый булыр иде!

– Әлбәттә, мөхтәрәмә Сәрби ханша, Сезгә болай ук дулкынланырга кирәкми. Мин хәзер үк киленегезне табып кайтам.

Фатыймасолтан, олы яшьтәге ханымның күңелен күтәрерлек итеп елмайды да, урыныннан кузгалып, хан бакчасына илтүче ишекләргә таба китте.

Ә бу вакытта Ибраһим солтан, үзен шактый киеренке тотып, Нурсолтанның агарынып киткән чыраеннан күзен алмыйча, сүзен дәвам итә иде:

– Алдыгызда ике юлның берсен сайлау тора. Бу бик мөһим, Нурсолтан! Туганыгызның нилектән үлгәнлеге серен ачып, Сез аның исемен ахырзамангача хур итәсез, ә әшәке гайбәт нәҗесе хан йортындагы һәркемгә ябышачак һәм беренче чиратта – Сезгә! Сез бит һәрвакыт бик якын сердәшләр булдыгыз. Кешеләр, Шаһназның фахишәлек белән шөгыльләнгәнен белгәч, ни диярләр? Бу гамәлдә Сезне үк гаепләмәсләрме?

– Солтан... – Аның ялкынланып сөйләвен бүлдергән тавыш бик хәлсез, әмма ишетмичә калырлык та түгел иде. Ибраһим, шул мәлдә сүзеннән туктап, ханымны тыңларга булды. – Ялварып сорыймын: Шаһназны агу эчәргә кем мәҗбүр итте?

– Ә Сез ничек уйлыйсыз, кадерлем?

Ул яшь хатын янына эскәмиягә утырды да аның кулларын сак кына үз учына алды.

Нурсолтан моңа карышмады. Бу бәләкәй җиңү Ибраһимны тагын да рухландырды, ул:

– Шаһназга агу кайдан килгәнен белмим, – дип дәвам итте. – Мондый өметсез адымга ул, күрәсең, бик каты курыкканга күрә баргандыр. Мескенем, минем аңа һичнинди зарар салмасымны, хыянәте турында беркемгә хәбәр итмәсемне белмәгәндер. Билгеле, тулысынча кичерү турында сүз дә була алмый. Ул мине рәнҗетте һәм мәхәббәтемне аяк астына салып таптады! Аны, йөрәгемнең уртасына кадаган пычак ярасы төзәлгәнче, шәһәр читендәге берәр биләмәмә генә җибәреп торырмын, дигән идем. Ләкин Шаһназ үзе башкача карар кабул иткән! Ул көнне иртән йокы бүлмәсенә кергәч, мин, аның ничек газаплануын күреп, тораташка әйләндем. Шул чакта нәрсә әйткәнемне,ниләр кыланганымны хәтерләмим, мондый фаҗигане аңлый алмыйча, зиһенем таралган иде һәм Сезнең салкын мөнәсәбәтегез шул иртәдә үз-үземне ипсез тотуым белән бәйле булса, гафу итә күрегез, Нурсолтан! Мин чынлап та ул чакта югалып калдым, нишләргә дә белмәдем.

Ниһаять, Ибраһим солтан уенны бик әйбәт башкарып чыга алганын һәм үз дигәненә ирешкәнен аңлады, чөнки шушы минуткача иң соңгы көчләрен җыеп түзгән Нурсолтан үксеп елап җибәрде дә аның кочагына авып төште. Яшь хатынны тынычландырган булып, ханзадә аны ныграк кыса барды, колагына ягымлы-йомшак сүзләр пышылдады, елаудан калтыранган аркасыннан сыйпады. Ул арканың җылысы учларын үтәли яндырган кебек булды. «Йа Аллаһ, – дип уйлады Ибраһим, үзенең шулай иркәләвеннән тәм табып, – бу хатын йөрәккә сагыш вә кайгы да, мәхәббәт һәм кайгырту да тутыручы энҗегә охшаган. Ул иң акыллы ирне дә юлдан яздыра ала. Аның матурлыгына ия булыр өчен, кыя-таулар күчерермен, юлымдагы барча киртәләрне юк итәрмен, ул минеке булыр, ә бу гамәлемдә кайсысы булышыр: Аллаһмы, әллә Иблис үземе – миңа барыбер!»

Алар икесе дә киң ябалдашлы ясмин куагы артына поскан Фатыймасолтанны күрмәделәр, сизмәделәр. Ибраһимның хатыны, тәхет варисының хәләле ниндидер ир куенына сыенганын күреп, җиргә үк сузылып ятты. Текәлебрәк карагач, әлеге мәҗнүннең Ибраһим икәнлеген таныды. Кычкырып җибәрмәс өчен, кулындагы япмасының почмагын чәйнәп, хатын, чынлап та, аның үз ире икәнлегенә ышаныр өчен, йөзенә туп-туры карап китәргә тырышты. Ибраһим солтанның ярым йомылган күзләре һәм иренендәге әле генә каймак ялаган карак мәчедәй елмаюы бер генә нәрсә турында сөйли: Фатыймасолтанның җефете шулкадәр көчле гыйшык дәртенә чумган ки, ул тирә-юнендәге бернәрсәне дә күрми, берни дә ишетми. Бу мизгелдә аның бөтен дөньясы үзенә кысып кочаклаган хатын белән генә чикләнә. Терсәкләре, тезләре белән юеш җиргә таянып, кулларын, учларын, матур күлмәген пычракка манчып, Фатыймасолтан артка таба шуышты. Хатынның болай да кызышкан битләрен яндырып, яңаклары буйлап күз яшьләре акты. Фатыймасолтан, аларга туфрак сылаганын да сизмичә, яңакларын учы белән сыпырды. Аның бер генә теләге бар иде: кеше-кара күзенә чалынмыйча Сәрби янына кайтып җитү һәм, ханша күкрәгенә ятып, ачы гарьлеген елап бушату.

Нурсолтан бакчадан Ибраһим ханзадә эзеннән диярлек кайтып керде, йөзе гадәттәгедән ныграк агарган булса да, аның кыяфәтенә бик аз кеше генә игътибар иткәндер. Хезмәтче хатын тәмам күз яшьләренә чыланган Фатыймасолтан көтеп торган кече якка чакырып чыгармаса, Сәрби ханшаның да моңа исе китмәгән булыр иде.

– Мөхтәрәмә ханшам, адәм ишетмәгән хәл бит бу! Уйнашчы нугай кызы башыбызга хурлык китерә! Ә безнең Хәлил белән ни булыр, ул моны ничек кичерер?! Аңа Нурсолтанның Ибраһим белән очрашып йөрүләре билгеле булуын гына да күз алдыма китерә алмыйм! Нәрсәдер эшләгез инде, ичмасам, нугай кәнтәенә, күрмәгәненңне

күрсәтәм әле, диегез. Садагыгызны ачып, ярсулы җаягез өстенә җаза угын куегыз да аңа төбәгез! – дигән ялварулы сүзләр белән каршы алып, озатып калды аны Фатыймасолтан.

Сәрби ханша зур капчык кебек кесәсеннән ефәк яулык чыгарып, шуңа, бик шаулатып, борынын сеңгерде. Өлкән килленнең беренче сүзләреннән үк ханша кулларын йөрәге турысына кушырды, аннары, бик авырлык белән генә, алпан-тилпән килеп, бәйрәм табынына кире чыгып китте.

Тәхет варисының анасы әлегәчә дәшми-тынмый утырган иренә текәлде, аңардан, мәҗлес төгәлләнү белән очрашып сөйләшик әле, дип сорады. Барча кунаклар күңел ачканда, ханша инде, эчен җәһәннәм утлары яндырса да, тыштан елмайган булып утырды, ә уенда бер генә теләк: азгын киленкәйне тизрәк җазага тартырга рөхсәт алу иде.

Ул, эчендәге ялкынны инде күзләренә чыгарып, җене сөймәгән Нурсолтанны хәзер үк көйдермәкче иде, ләкин, сарай кешеләренең бу хәлгә аптырашлы карашын тоеп, керфекләрен түбән төшерде. Ханның мәҗлестән чыгуын түземсезләнеп көтте дә, ул кузгалу белән артыннан китте.

Сәрби ханша хәзер инде хаким иреннән күзләрен алмыйча, аның һич кичекмәстән кискен чара күрүенә, үз күкрәгендә дөрләгән ут дәрәҗәсендә ачу-нәфрәт давылы кузгалуына өметләнде. Әмма Мәхмүд, үч алырга ашкынып торган ханшаны аптырашка калдырып, ашыкмыйча гына ниндидер кәгазьләрендә казына башлады, үзе авыз ачып һичбер сүз әйтмәде.

– Хуҗам, рөхсәт итегез әле, – дип, аңа якынрак килеп эндәште сабырлыгы төкәнә башлаган Сәрби ханша. – Рөхсәт итегезче, мин үзем Нурсолтанны Сезнең хозурга чакырыйм. Аңа аклану җаен эзләргә вакыт бирмәгез, без аннан мондый кыланмышларын хәзер үк аңлатуын таләп итәргә тиеш!

– Юк.

Ханның әкрен, тыныч тавышы һәртөрле кычкырудан да көчлерәк булып чыкты, шуңа хатын гадәттәгечә аңа буйсынып, әмма бер күзе белән иренә сынаулы караш ташлау хәйләсен табып, тынарга мәҗбүр иде. Мәхмүд хан кәнәфиенең сырлап эшләнгән култыксасына бөтен гәүдәсе белән авыр гына таянды.

– Бу көн барыбыз өчен дә артык мәшәкатьле булды. Нурсолтан белән Хәлил инде үзләренең йокы бүлмәсенә кереп китте, аларны мин гадәти хатын-кыз гайбәтләре аркасында гына борчырга теләмим.

– Әй хуҗам! – Сәрби ханша ярсуыннан хәтта кызарып чыкты. – Сез нәрсәне гайбәт дип саныйсыз? Мескен Фатыймасолтан үз күзләре белән күргәннеме?! Аңа тынычландыргыч чәйләр эчертеп, өенә илтеп куйдылар, чөнки солтанша мәҗлескә керерлек хәлдә түгел иде. Аның әле генә бәбидән котылганын онытмагыз! Үз вазыйфасын намуслы үтәп килгән, иренә таза-сау балалар китергән хатынга нинди авыр сынау бу. Ибраһим солтан аның күз алдында үз туганының хатынын бозык юлга бастырырга уйлаган! Ә Нурсолтан аның иркәләүләрен ачыктан-ачык кабул иткән! Йа Аллаһ, мондый хәлне хатыннар гайбәте дип ничек атарга мөмкин, акылыгызга килегез, ирем, бүген үк гадел хөкем чыгарыгыз! Иртәгә соң булуы бар бит!

– Сәрби ханша, мин инде Сезгә әйттем: варисым белән аның хатынын нәкъ менә хәзер борчыйсым килми. Бүген минем, Сезгә никадәр генә мөһим булып тоелмасын, бер эш белән дә шөгыльләнү теләгем юк. Үз бүлмәгезгә китегез, хезмәтчеләр мине йокыга әзерләсен, комачауламагыз!

Хатынына күзен дә күтәреп карамыйча, хан, кискен генә тартып, йокы бүлмәсенең ишеген ачты. ■

МӘСКӘҮ ҺӘМ ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

2016 елда Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре ***Булат Рәхимҗанов****ның* ***«Москва и татарский мир: сотрудничество и противостояние в эпоху перемен, XV-XVI вв.»*** *исемле китабы басылып чыкты. Санкт-Петербургтагы «Евразия» нәшриятында дөнья күргән бу китап фәнни җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты. Профессор* ***Фәйзелхак Ислаев*** *тәкъдиме белән, редакциябездә әлеге китап турында «түгәрәк өстәл» оештырдык. Анда автор үзе, Ф.Ислаев, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, күренекле әдип* ***Разил Вәлиев****, Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты галиме Булат Хәмидуллин, журналыбызның баш мөхәррире* ***Ләбиб Лерон****, редакция хезмәткәре* ***Ленар Гобәйдуллин****, журналистлар* ***Рәшит Минһаҗ*** *һәм* ***Лилия Гаделшина*** *катнашты.*

ЛӘБИБ ЛЕРОН: «Әлеге хезмәт киң масштаблы кинокартинаны хәтерләтте»

Тарихыбызга, бай мирасыбызга нисбәтле фундаменталь китаплар дөнья күрә килә, шөкер. Соңгы елларда гына басылган шундый хезмәтләрнең берсе – Булат Рәхимҗановның «Москва и татарский мир...» китабы. Дөнья мәшһүре Лев Толстойның «Сугыш һәм солых» әсәре буенча төшерелгән кинофильмны хәтерлисездер: анда киң планда бирелгән, өстән – югарыдан төшерелгән сугыш күренешләре бар. Булат Рәхимҗановның әлеге саллы хезмәте миңа әнә шул күләмле һәм колачлы тарихи кинокартинаны хәтерләтте. Мәгълүм ки, әле чагыштырмача яшь булуына карамастан, Б.Рәхимҗанов – Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, ә бәлки чит илләрдә дә танылу алган галим.

БУЛАТ РӘХИМҖАНОВ: «Чынбарлыкның ничек булганын мин үзем дә белмим»

Бу китапны язарга мине нәрсә этәрде соң? Мәктәп һәм студент чорым 1980 еллар азагы-1990 еллар башына – татар халкының милли күтәрелеш вакытына туры килде. Катнаш гаиләдә туып үскәнлектән, үземнең татар тамырларым белән кызыксына башладым. Кайбер белгечләребез язган фәнни-популяр мәкаләләрне укыгач, аларның тарихны гади генә шәрехләүләренә гаҗәпләнә идем. Казан ханлыгы изге җир булган да, аңа агрессив, көчле урыс дәүләте һөҗүм ясап, яулап алган. Вазгыять шулай гына булганмы? Әлбәттә, мине бу шикләндерә иде. Университетта безгә совет чорында язылган дәреслекләр белән укырга туры килде. Аларда кайбер темалар буенча зур бушлык бар. Алтын Урда ничек тә тәкъдим ителгән булса да, 1480 елдан соң, Угра елгасы буендагы вакыйгадан алып, Алтын Урда дәүләте формаль рәвештә таркалгач, Казан яулап алынганчы бушлык. Әйтерсең, XV гасыр азагы-XVI гасырның беренче яртысында татар дөньясында бернинди вакыйгалар булмаган. XVI гасырның икенче яртысында гына урыс дәүләте Алтын Урданың «калдыкларын» җыеп ала. Бу миңа бик тә сәер тоелды.

Касыйм кебек шәһәрләр берничә булган. Башта шуларны өйрәнергә уйлаган идем, тикшерә торгач, чыганакларның җитмәве ачыкланды. Әмма, аның каравы, тагын да киңрәк темага тотындым: Мәскәү һәм татар дөньясы, православие һәм ислам. 1990 елларда Ядегәр ханны баһадир, Казанны Явыз Иван яулап алганда актык көченә кадәр көрәшкән, дип язалар иде. Әмма монда да вакыйгалар сюжеты бер генә яклы булмаган икән! Дөрес, ул ахыргача сугышкан, аннары аны әсир итеп алганнар. Ни өчен хан белән мәрхәмәтле булганнар? Соңыннан гына Ядегәр ханның, чукындырылып, сигез ел дәвамында Мәскәү дәүләтенә хезмәт иткәне, шунда яшәгәне ачыкланды. Ул үзенең киләчәген Казан белән бәйләргә омтылып карый, әмма бу сәяси карьерасы барып чыкмый, теләк-нияте чынга ашмый. Бар да без уйлаганча гади генә түгел. Китабымда менә шушы мәсьәләләрне тикшерергә булдым.

Тарихчы Искәндәр Измайлов, кулъязманы укып чыкканнан соң, аның стилен һәм методологиясен үзгәртергә, хезмәтне «җитдирәк», Россия историографиясендә кабул ителгәнчә, позитиврак язарга тәкъдим итте. Әмма китап басылып чыкканнан соң, ул: «Син мине тыңламадың һәм дөрес эшләдең!» – диде.

Мин бу китапта барысын да һәм чынбарлыкта ничек булганын да яктыртырга теләмәдем. Дөресен әйткәндә, чынбарлыкның ничек булганын үзем дә белмим. Мин чыганакларны укыйм, аларны үз аң-фәһемем аша үткәреп, субъектив фикеремне генә белдерәм.

Совет историографиясендә теге яки бу шәхеснең шәхси амбицияләренә игътибар ителмәде, хәтта алай эшләү кирәк түгел, дип саналды. Имеш, бер кеше икенчесен рәнҗеткән икән, теге яки бу вакыйгага моның әллә ни йогынтысы булмаган. Мин, шәхесара факторның татар тарихына тәэсире искиткеч зур, дип уйлыйм.

Китапка ун рецензия язылды. Шуларның икесе – читтәге басмаларда, сигезе – үзебездә, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты чыгара торган җыентыкта. Җидесе – уңай, фәкать берсе генә кискен тәнкыйди характерда. Аны Россия тарихы институты галиме Андрей Беляков язды. Монда бер нюансны да әйтергә кирәк: Рязань өлкәсеннән булган бу галим үзе дә шул ук тема буенча китаплар яза. Ул: «Рәхимҗанов, бәхәскә кереп, үзенең дөреслеген расларга теләми», – дип, дәгъва да белдерде. Әмма мин беркемгә дә үземнең хаклыгымны дәлилләргә җыенмыйм, чөнки, әйткәнемчә, дөреслекнең ничек

булганын –хаклымы мин, хаксызмы – үзем дә белмим. Минем тарихи процесска үз фикер-карашым бар, әмма хакыйкать бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле. Шул исәптән, миңа башкаларның да субъектив фикере кызык.

Тиздән китабыма немец басмасында АКШ галиме Чарльз Галпериннның инглиз телендәге бәяләмәсе басылып чыгачак. Аның азагына: «Мәскәү һәм татар мөнәсәбәтләре белән шөгыльләнүчеләр генә түгел, ә Мәскәү дәүләтен өйрәнүчеләр дә бу китапны укып чыкса яхшы булыр иде», – дип язылган.

ФӘЙЗЕЛХАК ИСЛАЕВ: «Бу китап – тарих фәнендә җәдитчелекнең икенче сулышы»

Булат Рәхимҗановның Касыйм ханлыгы турындагы китабына бәяләмә язганда ук: «Бу өметле егет», – дигән идем. Дөрестән дә, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында иң өметле егетләрнең берсе безнең арада утыра. Ике зур монография чыгарып, Россия һәм дөнья күләмендәге белгечләрне үзенә җәлеп итә алган тарихчыларыбыздан ул.

Галим хезмәтенең өстенлеге нидә? Беренчедән, ул И.П.Ермолаевның – фундаменталь тарихчының һәм олпат остазның укучысы. Бу – зур бәхет. Яшь галимнәрнең киләчәге фәнни җитәкчедән тора. Икенчедән, Булат чит ил әдәбияты һәм чыганаклары белән эшли, Европа һәм Америка галимнәрен шәхсән белә, алар белән аралаша. Без тарихның эченнән йөрсәк, Булат – аның өстендә. Ул процесска читтән дә карый. Миңа калса, мондый сәләт аңа тумыштан бирелгәндер, нәселендә берничә милләт канының кушылуыннан да булырга мөмкин.

Безнең тарих фәнендә традиция өстенлек итә. Әмма шуны яңача алып бара торган галимнәр дә бар. Шуларның берсе – Булат Рәхимҗанов. Әгәр дә үткән белән чагыштырсак, без – кадимчеләр сафында, Булат – җәдитче. Традициянең начарлыгы нәрсәдә соң? Гадәттә тарихчыларыбыз электән килгән калып буенча яза, аларның хезмәте укылса да, фәнни җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә алмый. Элек, хәтта совет чорында ук язылган ялгыш фикер бер фәнни хезмәттән икенчесенә күчә, шулай итеп, дәреслекләргә дә кереп китә. Гади генә мисал: ни өчен Казан ханлыгын оештырган Олуг Мөхәммәткә башкалабызда һәйкәл юк? Чөнки, традицион фән буенча, Казан ханлыгына Мәхмүт 1445 елда, үз атасы Олуг Мөхәммәтне үтергәч нигез салган, дип язып килделәр. Моның дөрес түгеллеген Булат Рәхимҗанов әлеге китабында дәлилләде.

Татар халкы тарихы аерым бер калыпка, электән килгән традицияләргә сыймый. Мәгълүм ки, Иван Грозныйның максаты – хәтерне юкка чыгару! Ә чыганак – тарихи хәтер. Урысларның елъязмаларын, яңа патшалар килгән саен, яңадан язган. Сталин «Краткий курс КПСС»ны язган кебек, Путин да «тарихи-мәдәни стандарт»ны уйлап чыгарды. Бер калыпның эчтәлеге гел алышынып тора. Имеш, халыкка һәр чорда шулай итеп аңлатсаң, әйбәтрәк тоела.

Бер китапка ун бәяләмә язылу – әлегә кадәр татар тарихы фәнендә булмаган күренеш. Начар китапка бәяләмәне беркем дә язмый. Бу китап – тарих фәнендә җәдитчелекнең икенче сулышы.

БУЛАТ ХӘМИДУЛЛИН: «XVII гасырдан татар яңадан хезмәттәшлеккә керешә»

Адашым борынгы һәм урта гасырлар урыс чыганакларын, дипломатия, илчеләр китапларын, халык санын алу кенәгәләрен укый, аларны тирәнтен анализлый. Булат татар дөньясы, Алтын Урда, аннан соңгы дәүләтләр, Мәскәү кенәзлеге һәм дәүләте

историографиясен бик яхшы белә. Болар өстенә, инглиз һәм немец телләрендә язылган тарихи әдәбиятны, фәнни хезмәтләрне тәрҗемә итә, чит ил белгечләренең китап, мәкаләләрен үз фәнни хезмәтләрендә бик актив файдалана.

Мин китапны зур кызыксыну белән укып чыктым. Фактик материал гаять бай. Шулай да, фактларны, вакыйгалар хронологиясен җентекләп белә торып, автор күп кенә нәрсәләргә горизонталь яссылыкта түгел, ә системалы рәвештә, тарихның өстеннән торып якын килгән. Китапның зур яңалыгы әнә шунда.

Әлбәттә, тарих фәнендә XV-XVI гасырлардагы татар һәм урыс мөнәсәбәтләре, «сотрудничество и противостояние» темасы Булат Рәхимҗанов тарафыннан беренче мәртәбә күтәрелми. Бу юнәлештә XIX гасыр ахыры-XXйөз башында хезмәт куйган Николай Трубецкой, Пётр Савицкий, Георгий Вернадский һәм Кырым ханлыгы турында язган Василий Смирновларның хезмәтләрен искә төшерик. Совет чорында һәм аннан соңгы елларда ул хакта Шамил Мөхәммәдьяров, Мөхәммәт Сәфәргалиев, Миркасыйм Госманов, Сәлам Алишев, Равил Фәхретдинов, соңрак Дамир Исхаков, Анна Хорошкевич, Вадим Трепавлов, Илья Зайцев, Дмитрий Котляров, Андрей Беляков, Роман Почекаевлар язды.

Дөресен әйткәндә, Булат мондый хезмәт язар, дип көткән идем. Аның «Касыйм ханлыгы» дигән китабы, атаклы тарихчы В.В.Вельяминов-Зерновның 1860-1880 елларда язылган 4 томлы шул исемдәге китабыннан соң, икенче саллы хезмәт. Булат Рәхимҗанов, йөз елдан артык вакыт үткәч, беренче мәртәбә бу теманы киң масштабта күтәрде. Алтын Урда таркалганнан соң оешкан башка татар ханлыклары турында да күп санлы мәкаләләр язды, алар арасында «Большая Российская энциклопедия»дә басылганнары да бар. Бу мәкаләләрендә ул берничә мәртәбә «Мәскәү һәм татарлар» темасын тикшерде. (Форсаттан файдаланып, шуны да әйтим: аның адашы Булат Хәмидуллин исә, ягъни мин фәкыйрегез дип белегез, Михаил Худяковтан соң 80 ел узгач, беренче буларак, Казан ханлыгы һәм анда яшәүче халыклар турында монография язып бастырган иде.)

«Сотрудничество и противостояние» темасын киләчәктә тагын да киңрәк хронологиядә күрергә теләр идем. Хәзәр каһанлыгы, Кара диңгез, Кавказ, Дунай һәм Идел буендагы болгар дәүләтләре халкының, бөҗәнәк, кыпчак, каракалпакларның («чёрные клобуки») да урыслар белән мөнәсәбәтләрен искә алырга кирәк. Мәсәлән, каракалпаклар мисалында төрки бабаларыбызның урыс кенәзлекләре белән бәйләнешы аеруча ачык күренә. Алтын Урда чорын алсак, Бату ханның улы Сартак белән Александр Невский мөнәсәбәтләрен, Чыңгыз ханның оныкчыгы, бүген православие изгесе дип саналган Петр Ордынскийны (татар исеме Даир Кайдагул), Үзбәк ханның православие чиркәвенә кылган изгелеген искә төшерик.

Күптән түгел Мәскәү Кремлендәге музейда балалар өчен оештырылган лекциядә булдым. Лектор Мәскәүнең күтәрелүе, Иван Калита турында сөйләде, әмма зур, бердәм дәүләт патшасы – Алтын Урда җитәкчесе Үзбәк хан турында бер генә сүз дә әйтмәде. Ә бит без бик яхшы беләбез: нәкъ менә үзе мөселман булган Үзбәк хан православие чиркәвен кайгырткан, аны барлык салымнардан да азат иткән. Хан ярдәме белән тәхеткә күтәрелгән Иван Калита чорында Мәскәү башкала, урыс кенәзлекләренең үзәге буларак үсеп китә!

Булат китаптагы вакыйгаларны 1407 елдан, Туктамыш улларының Мәскәү кенәзлегенә китүеннән башлап җибәрә. Биредә Польша-Литва татарларының да язмышын искә алырга кирәк. Алар үзләрен Тукатамыш хан чорындагы Алтын Урда ва-

рислары дип саный. Китап шартлы рәвештә Себер ханлыгы яулап алыну вакыйгалары белән тәмамлана. XV-XVI гасырларны автор «сотрудничество и противостояние» чоры дип атый. Мәскәү һәм татар ханлыклары арасындагы XV гасырда булган хезмәттәшлек XVI гасырда кискен каршылыкка күчә, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары яулап алына. XVII гасырдан «сотрудничество и противостояние»не мин, киресенчә, «противостояние и сотрудничесво» дип әйтер идем. Бу елларда вазгыять нәкъ менә шул юлга кереп китә дә инде. Татарның болгавыр дәвердәге ролен генә искә алыйк. Идел буе, казан татарлары, мишәрләр, ополчениедә катнашып, Мәскәүне чит ил баскыннарыннан коткара. Ә шул ук вакытта биредәге урыс элитасы, Мәскәүдән аерылып, бәйсез Казан патшалыгы төзергә омтыла. Бу вакыйгалар барысы да Казан яулап алынганнан соң ярты гасыр вакыт узгач булган. 1552 елдан башлап 1585 елга кадәр Урта Идел буенда өч мәртәбә «чирмеш» сугышлары булганын искә төшерегез. Татар, мари, удмурт, чуаш халыклары уртак Ватан – Казан ханлыгы азатлыгы өчен урыс хакимияте белән сугыша, ә инде соңрак Мәскәүне чит ил баскыннарыннан коткара. Димәк, татар яңадан хезмәттәшлеккә керешә...

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ: «Булат – Чатыртауга менеп түбәнгә караган тарихчы»

Бу китап – татар халкын һәм аның дәүләтчелеген өйрәнүдә яңа фикер. Халкыбызның үткәне – дөньядагы иң катлаулы тарихларның берсе. Совет чорында милли тарихны язарга рөхсәт булмады, ә хәзер фикер төрлелеге шулкадәр күп, аларның кайсы дөрес һәм объектив икәнен белеп тә бетереп булмый. Әлбәттә, фикер күптөрле булырга тиеш, шуның нәтиҗәсендә генә киләчәктә хакыйкатькә якынаербыз, дип уйлыйм.

Моннан 15-20 еллар элек, Азнакай хакимияте башлыгы Әнәс Исхаков: «Әйдәгез, мин сезне Чатыртауга алып менәм», – ди. Мин әйтәм: «Нигә анда менәбез?» Ул: «Азнакайны Чатыртауга менмичә аңлап булмый, аны минем кабинетта утырып кына, кешеләр белән аралашып кына да белеп булмаячак. Азнакайны аңлар өчен, Чатыртауга менеп, өстән аска карарга кирәк», – ди. Сезнең сөйләү буенча, Булат – Чатыртауга менеп түбәнгә караган тарихчы.

Мин китаптагы чыганакларга игътибар иттем. Алар гаять бай. Боларны укып чыгар өчен генә дә бер гомер кирәк. Бервакыт Надир Дәүләт, Миркасыйм ага Госманов һәм мин сөйләшеп утырабыз. Шунда М.Госманов әйтә: «Мин үземне начар тарихчыга санамыйм, әмма Надирның миңа караганда бик зур бер өстенлеге бар – аның чыганаклар даирәсе киңрәк». Дөрестән дә, Надир төрек телен, димәк, бөтен төрки дөньяны, немец һәм инглиз, кытай телләрен яхшы белә, шул телләрдә язылган чыганакларны укый. Ә чыганак – тарихчының нигез ташы.

Китаптагы чыганак һәм әдәбиятның 90 процентын урыс һәм көнбатыш илләре галимнәре язган, ә шәрык белгечләренеке аз. Югыйсә, Казан каласы күбрәк шәрык белән бәйле. Мин, 1996 елда Кытайга баргач, китапханәгә кердем һәм җир астында борынгы документлар саклануын күрдем. Шунда китапханә директорыннан: «Сездә татар халкы тарихы турында китаплар бармы?» – дип сорадым. Ул: «Искиткеч күп, әмма аны бер генә татар галименең дә өйрәнгәне юк», – ди. Димәк, безнең анда барып өйрәнәсе бар, ә моның өчен кытай телен яхшы белгән милли җанлы галимнәребез кирәк. Миркасыйм ага, Ватиканда да бик күп татар чыганаклары булырга тиеш, дигән иде.

Заманында Мәскәү зур татар дөньясының бер өлеше генә булган, әмма бүген аның тарихы Алтын Урда һәм башка татар ханлыкларына караганда яхшырак өйрәнелгән. Күптән түгел Калуга өлкәсе парламенты 1480 елгы «Стояние на реке Угре» вакыйгасын бәйрәм итү буенча нигезнамә җибәрде. Без тискәре карар кабул иткәч, алар тавыш куптарды, хәтта губернаторы, безнең Президентка шылтыратып: «Вәлиев комитеты Калуга белән Татарстанны чәкештермәкче була», – диде. Бер караганда, юк кына вакыйга, шуннан зур, дәүләт дәрәҗәсендәге бәйрәм ясамакчылар. Ә бит андый сугышлар тарихыбызда бик күп булган.

Яхшы беләсез: Казандагы татар чыганаклары юкка чыгарылган. 1990 елларда ТР Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев белән патриархка хат җибәрдек. Хатта, патриарх архивына кереп, татар халкы белән бәйле чыганакларны өйрәнү теләген белдергән идек. Кызганыч, руханилар башлыгыннан җавап килмәде. Моны мин яхшыга гына юрадым, чөнки чыганаклар булмаса, патриарх, юк, дип язарга тиеш, ә ялганлап язарга дини кешенең намусы кушмый. Димәк, Казан ханлыгына бәйле чыганаклар аларда бар. Кайчан да булса безнең галимнәребезгә дә анда барып өйрәнергә мөмкинлек булыр.

Мәскәү белән татар арасындагы мөнәсәбәт элек ничек булса, бүген дә аның чагылышы бар. Алтын Урда чорындагы Мәскәү кенәзлегенең хәле белән хәзерге Россия Федерациясендәге Татарстанның хәлен чагыштырыр идем. Дөрес, салым мәсьәләсендә ул замандагы Мәскәү дәүләтенең хәле бүгенге Татарстанга караганда күпкә яхшырак булган.

Сөембикәгә һәйкәл кую турында да сүз бара. Казакъстанда яшәүче Камил Муллашев безгә һәйкәленең проектын тәкъдим итте. Аны Казанда түгел, ә Чаллыда куярга уйлыйлар икән, дип ишеттем. Әмма бу һәйкәл Казанда булырга тиеш. Казакъстанда Сөембикә урамын һәм һәйкәлен булдырдылар. Алар ханбикәбезне күптән үзләренеке дип саный. Сөембикәнең тууына 500 ел тулу уңаеннан, халыкара конференция үткәрергә кирәклеген искәртеп, ТР ФА Президенты Мәгъзүм Сәлаховка хат яздык. Башка төрки халыкларның да галимнәре Казанга җыелып, Сөембикә турында сөйләшсә, бик яхшы булыр иде. Ә ачыклыйсы мәсьәләләр бихисап. Ханбикәнең язмышы турындагы мәгълүматлар ничек инде бөтенләй юкка чыгарга мөмкин? Ул бит ханбикә! Аның язмышы ничек булып беткәнен ачыклап булмыймы икән? Кабере кайда? Касыйм зиратында бер язусыз таш тора. Кабере шулдыр, дип әйтәләр, әмма төгәл билгесез. Сөембикә – безнеке, татарныкы булырга тиеш. Әгәр дә, сезнеке түгел, диләр икән, бер генә урыс патшасының да нәселе урысның үзенеке генә түгел икәнен искә алыйк.

Әйткәнемчә, Мәскәү һәм Казан мөнәсәбәтләре традициясе шактый катлаулы. Әдәбият институтында профессор, тарих фәннәре докторы, кайчандыр Сталинградның обком секретаре булып эшләгән М.А.Водолагин, Бөек Ватан сугышы турында лекция укыганда: «Кырым татарлары – хыянәтче!» – диде. Күңелем кайнап чыкты да: «Мин Сезнең лекциягезне тыңлый алмыйм!» – дип чыгып киттем. Шуннан соң мине өч айга стипендиядән мәхрүм иттеләр. Дөрес, хәзер бу турыда кычкырып әйтүче галимнәр юк дип беләм. Әмма бүген дә әлеге мөнәсәбәт дәвам итә: салымнар мәсьәләсе, шартнамәне озайтмау, татар телен укытуны чикләү һ.б.

Урыс дәүләте белән татар арасындагы мөнәсәбәтне җентекләп өйрәнү әлеге халыкларның хәзерге дәүләтебез үсешенә керткән өлешен ачыклау өчен бик тә кирәк. Бу китапның фәнни-популяр варианты Казанда да басылып чыгар, дип уйлыйм.

Язманы ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ

Аллаһның рәхмәте илә, 9 март көнне шәһри Болгарда XVIII Кулаткы укулары узды. Әлеге дини, фәнни һәм педагогик чара бу юлы Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуга багышланган иде. Игътибарыгызга Ульяновск өлкәсенең Кулаткы районы хакимияте башлыгы, академик **Эдуард Әнвәр улы Ганиев** *һәм КФУ доценты* **Илһам Фаил улы Фәттахов***ның Кулаткы укуларында ясаган чыгышларын кыскартып тәкъдим итәбез.*

Эдуард ГАНИЕВ: «Рухи мирасны югалтырга хакыбыз юк»

Без ата-бабаларыбыз мирасын барлаганда еш кына XIX гасырның икенче яртысы-XX гасыр башына мөрәҗәгать итәбез. Бу – безнең халык өчен хәлиткеч чор. Менә шулвакытта да инде татар-мөселман тормышында Мәрҗанинең дөньяви һәм дини башлангычны тыгыз берләштергән өндәмәләре яңарыш программасы ролен үтәде. Ул, дини реформаторлыкның гына түгел, милләт яңарышының, милли мәгарифтә үзгәрешләрнең дә күренекле идеологына әйләнде. Ә реформаланган мәдрәсә тәрбиясе татар халкын яңа югарылыкка алып чыгучы төп фактор булды.

Мәрҗани татар җәмәгатьчелегенә дин белән фәннең бергә янәшә яши алуын исбатлый алды. Галим, дини белемне фәлсәфи белемгә каршы куймыйча, безгә бары тик аларның куллану өлкәләрен генә аерып күрсәтте.

Шиһабетдин Мәрҗани Русиядә татарлар арасында милли идеологиягә нигез салучы һәм җәдитчелек хәрәкәтенең алхәбәрчесе иде. Аның дини-фәлсәфи карашлары, педагог, дини реформатор, мәгърифәтче, тарихчы, фәлсәфәче буларак эшчәнлеге, татар тарихына гына түгел, бөтен Русия һәм дөньякүләм мөселман иҗтимагый фикеренә дә зур өлеш кертте. Ул гомерен гади халык мәнфәгатьләре, прогресс өчен көрәшкә, кешеләрне рухи агартуга, аларның дөньяга карашларын киңәйтүгә багышлады.

Шиһабетдин хәзрәт хезмәтен аның рухи шәкертләре Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин, Галимҗан хәзрәт Баруди кебек фидакарь милләт каһарманнары дәвам итте. Аларның

эшләрен хәзерге көнгә кадәр җиткерүгә сәбәпче булган хәзрәтләребез дә бар иде. Болар – Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин, Габделхәбир хәзрәт Яруллин, Габделхак хәзрәт Саматовлар. Әлеге остазлар дин исламда буыннар чылбырын саклап калды. Бу чылбырны өзәргә, алардан килгән рухи мирасны югалтырга, таркатырга безнең хакыбыз юк, чөнки хәзерге чынбарлык татар-мөселман өммәтенә яңадан-яңа таләпләр куя.

Моннан йөз ел элек татар милләте белән ислам дине Бербөтен, ягъни аерылмас булган. 1990 еллардан соң динебезгә традицион булмаган агымнар килеп керү сәбәпле, милли факторны читкә этәрү галәмәте башланды. Бүген, Аллага шөкер, миллилекнең әһәмиятен аңлау бар һәм халкыбыз тарихында яңа чор бара. Милләтпәрвәр булган яңа буын хәзрәтләре дә үсеп чыкты. Моннан 20 ел элек мәгърифәтче якташыбыз Илдус Әмирхан күтәреп чыккан татар милли-дини яшәеш системасы, ягъни мәхәллә идеологиясе, акрын-акрын Татарстанда гына түгел, Русия төбәкләренә дә тарала башлады. Бу уңай агымнарны нәтиҗәле итәр өчен, өлкәннәрнең тәҗрибәсе, яшь буынның тырышлыгы сорала. Безгә, өлкән буын кешеләренә яшьләргә милләт, дин эшләрендә юл бирү, халыкны дини һәм дә мәгърифәти агарту турында онытмаска кирәк.

Кулаткы укулары менә шул юнәлештә эшли һәм татар халкының җыен, дини укулар, уртага салып халык белән сөйләшү кебек традицияләрен дәвам итә. Бу җыенның төп максаты традицион ислам кануннарын торгызу, борынгыдан килгән гореф-гадәтләребезне, Әбү-Хәнифә мәзһәбен пропагандалау, мәхәлләләрнең торышы, мөхтәсибләрнең эшчәнлеге белән таныштыру, милли мәсьәләләрне күтәрүдән гыйбарәт. Кулаткы укулары барышында замана өчен мөһим булган динебез вә милләтебез кыйммәтләре, ислам вә милләт тарихы, дини мирасыбыз хакындагы мәсьәләләр күтәрелә. Шунысы мөһим: бу җыен дәүләт эшлеклеләре, галимнәр, дин әһелләре, сәнгать вә мәдәният вәкилләре, гади халык катнашында уза. Проблемалардан курыкмыйча, җентекләп уртага салып сөйләшү форматында узганга кыйммәтле дә инде Кулаткы укулары.

Безнең хезмәтләр киң җәмәгатьчелектә зур теләктәшлек тапты. Инде Кулаткы укуларын оештыру рәвеше башка төбәкләр тарафыннан да өйрәнелә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.З.Закиров, укуларны югары бәяләп: *«Кулаткы укуларын уздырып, биредә җитди проблемалар күтәрү, аларны хәл итү юлларын эзләү, динебез һәм милләтебез үсеше турында фикер алышу Ульян татарларының ныклы позициядә булуын күрсәтә»*, – диде.

Алга таба без гореф-гадәтләребезне, күренекле имамнарыбызны өйрәнергә, аларның иҗатын, кардәшләребезнең уңышлы эшләрен белергә телибез. Бу юнәлештә заманыбызның күренекле галимнәре, имамнары, милләт асыллары ярдәм итәр, иншаллаһ. Әгәр без үз милләтебезнең бай тарихын вә гореф-гадәтләрен, күренекле шәхесләребезне онытмасак, киләчәгебез дә өметле вә ышанычлы булыр.

Илһам ФӘТТАХОВ: «Шиһабетдин Мәрҗани – Габденнасыйр Курсавиның рухи дәвамчысы»

Остазы Габденнасыйр хәзрәт Курсави вафатыннан соң утыз ел узгач, Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани Бохарада аның «Әл-иршәде лилгыйбәд» («Туры юлга өндәү») китабын яшертен генә укып чыга һәм фикердәшенә әйләнә. Галимнең дини мирасына гадел бәя биреп, Ш.Мәрҗани: *«Курсави – татар дөньясын үзгәртеп коруга нигез ташын салучы»*, – дип әйткән. Үз заманында Мәрҗанине дә, Курсави кебек, динсезлектә гаепләп, диннән язган, дип атаганнар.

Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...»ы – Г.Курсави турында иң тулы мәгълүматны туплаган чыганакларның берсе. Ул әсәр олуг мәгърифәтче иҗатына карашның үз чорын-

да ук каршылыклы булуын ачык күрсәтә. Бу китапны ачсак, кайбер чордашларының сүзенә караганда, Курсави – *«бик зур галим булмаса да, сәламәт табигатьле, дөрес фикерле, алдан күрүчән, тәкълидне кире кагучы, әкрен генә, сеңдереп кенә сөйли торган, батыр йөрәкле, замандашлары арасында тиңдәшсез булган»*. Ә менә Мәрҗани болай язган: *«Ул чын мәгънәсендә гыйлем һәм мәгърифәт иясе, ә нотыгы матур һәм нык ышанычлы иде. Каты холыклы, әче телле булганлыктан, галим исемен йөрткән бик күпләрнең хәтерен калдырып, аларны үзенең дә һәм фикеренең дә дошманына әйләндерде. ...Әгәр ул ашыкмыйча, мөлаемрәк итеп, акыллырак рәвештә, сүзләрен йомшак, матур итеп өйрәтү юлын тота алган булса иде, күпләр, хакыйкый хәлнең һәм мәсьәләнең асылына ирешеп, аның йөзендә үзләренә җитәкче табып, ялгышу һәм кяферлектән азат була алган булырлар иде»*. Хезмәтләрен гарәп телендә язса да, галим Югары Курса авылында үзе оештырган мәдрәсәдә балаларга дин белемен туган телебездә биргән.

Мәрҗанинең карашлары турыдан-туры Курсави әсәрләре йогынтысында формалаша, мәгърифәтче фикерләре аның хезмәтләрендә дәвамын таба. Мәрҗани исә, үз чиратында, Р.Фәхреддиннең галим буларак үсешенә тәэсир итә.

Бохара мәдрәсәсендә укыту тәртибе белән килешмәгән Курсави кебек үк, аның дәвамчысы, рухи варисы Мәрҗани дә, Бохарадагы дәрес ысулларын үзгәртү турында остазлары белән киңәшләшсә дә, файдасы булмаган. Бервакыт үзе кайбер шәкертләренә: *«Бохарада вакытымда кайбер остазларым белән ошбу дәрес тәртипләре хакында сөйләшеп карадым. «Бу фикерне сөйләү җиңел булса да, Бохарада дәрес тәртипләрен үзгәртү гаять мөшкел эш», – дип кенә җавап бирделәр»*, – дигән. Курсави шикелле үз башына бәла алудан куркып, Мәрҗани Бохарада вакытында әлеге мәсьәләне артык күтәрмәгән. Әмма «Мокаддимәт вафийәтел-әсляф» хезмәтендә Бохарадагы укыту тәртибе турында болай язган: *«Безнең халык уку-укыту тәртипләрендә Бохараны үрнәк тотып, Бохараны хөрмәт илә генә «Бохараи шәриф» дип сөйләсәләр дә, Бохараның халкы вә хөкүмәте мәгарифтән бик ерак, идарәләре бозык, уку-укытулары гаять тәртипсездер. Укулары да китап тәртибе илә түгел, бәлки ахырдан башлап кирегә таба укып киләләр. Бохарада укыган фәннәренең кагыйдәләреннән, әһәмиятле фәннәрдән вә китаплардан хәбәрсез булып калалар. Бохарада Коръән, хәдис, гыйльме ысул, гарәп әдәбияты, хикмәт, җәгърафия, тарих, әхвале галәм фәннәренең үзе дә, әсәре дә юк. Болар хаҗәт гыйлемнәрдән дә саналмый. Бохарада боларга ихласлы затлар да аз. Бохарада кулланылышта булган фикъһ китапларының да күбесе зәгыйфь мәгълүматлы соңгы заман галимнәре тарафыннан язылган китаплар. Ул китапларда мәзһәп башлыклары булган зур галимнәргә нисбәт ителеп язылган, теле зәгыйфь яки бөтенләй акылсыз нәрсәләр бик күп. Бохара голәмасы шул китаплардан күбрәк файдаланганлыктан, фикъһта булган мәгълүматлары нигезле түгел. Алар фикъһта көчсез булып, шәригать максатларыннан тиешенчә хәбәрдар түгелләр»*.

Бу китап басылып чыккач, *«Мәрҗанинең Бохара хакында язган сүзләре Казан һәм Казан тирәсендә кыямәт кубарган»*, татар халкы Урта Азиядә укыту тәртибенең камил булмавы хакында укып, башка илләрдән гыйлем чыганагы эзләргә мәҗбүр булган. Мәрҗанинең унлап шәкерте һәм үз улы Борһанетдин Төркия белән Мисырда белем алган.

Аллаһка шөкер, бүген Казаныбыздагы «Мөхәммәдия», «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» мәдрәсәләрендә укыту тәртибе заман таләпләренә җавап бирә: ислам һәм шәригать фәннәре белән беррәттән, татар теле һәм әдәбияты, Татарстан һәм татар халкы тарихы, компьютер технологиясе нигезләре, педагогика һәм психология дә укытыла.

... Мәрҗани үзенең остазы Курсави каберен хаҗ кылганда, ягъни 1880 елда Истанбул тирәсендәге зиратта эзләп таба һәм аның рухына Коръән укып, дога кыла. ■

ИСКЕ ПЕНӘГӘР: МЕТРИКАЛАРДА АВЫЛЫМ ЯЗМЫШЫ

Зыятдин Нәҗметдинов*

Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Иске Пенәгәр авылы халкы совет чорында өч зур хәзинәне – 1826 елда салынган мәчетне һәм аның манарасын, борынгы гарәби-дини китапларыбызны, метрика кенәгәләренең бер өлешен саклап кала алган. Хәзерге көндә чормада очраклы рәвештә генә табылган 25 еллык кенәгәләр – авылыбыз, аның халкының тарихын өйрәнүдә бәһасез чыганак. Алар безгә гаҗәеп күптөрле кызыклы фактларны ачыкларга ярдәм итә. Шуның өстенә, 26 еллык метрика Башкортстан Республикасы Үзәк Дәүләт архивында саклана. Аңлашыла ки, өйрәнер өчен чыганакның күләме зур. Шулай итеп, авылыбызда туган 1200дән артык һәм шул ук санда вафат булган кеше хакында гарәп графикасында язылган текстларны укып өйрәндек. Документларда теркәлгән 281 никах язмасы гына да искиткеч зур мәгълүмат чыганагы булып тора.

---

* Зыятдин хәзрәт Мөхәррәм улы Нәҗметдинов – Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Иске Пенәгәр авылы имам-хатыйбы.

Архивларда авылыбызның 1678 елдан башлап ун мәртәбә халык санын алу материаллары барлыгы билгеле булып, аларны да өйрәнергә туры килде. 1925 елгы халык исемлеген, метрикалар белән бергә, 1858 елгы халык санын алу материалларына тоташтыру хәзер авылда яшәүче гаиләләрнең 10-12 буын бабалары исемнәрен, аерым кешеләр арасында туганлык мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итте. Бу инде нәсел агачлары төзүгә ныклы нигез һәм алыштыргысыз чыганак булып тора.

Иске Пенәгәр метрикалары указлы муллалар тарафыннан язылган. Аларның типографиядә махсус басылган битләре китап итеп тегелгән, мөһер сугылган. Ел саен тутырылган метрика китаплары Диния нәзарәтенә тапшырылып, квитанция һәм расписка алынган. Икенче ел өчен яңа метрика китабы булдырганнар. Белешмәләргә караганда, нәзарәттән икешәр китап алынган, шул сәбәпле, документның бер нөсхәсе авылда сакланып калгандыр, дип уйларга мөмкин.

ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУШКАН?

Иң элек дөньяга килгән балалар язылган. Метрикада аларның туган көне, исеме, әтисенең исеме һәм аның социаль хәле күрсәтелгән. Хәтта баланың бабасы һәм бабасының әтисе дә язылган. Әнисе һәм әнисенең әтисе турында да белешмә бар. Сабыйның кайсы авылда туганлыгы хәбәр ителә һәм документка кем тарафыннан язылганы да теркәлә.

Игътибарны аеруча җәлеп итә торган нәрсә – балаларга бик матур исемнәр кушылган. **Нәҗметдин, Гарифулла, Мостафа, Әхмәджан, Габделвәли, Гатиятулла, Гыйсмәтулла, Шәмселхәят, Шәһрезадә, Сәхиббану, Гөлбаһар, Сәгадәтбану, Фәсыйхәтбану, Гыйззәтбану, Сәлимҗәүһәр** исемнәре бүген инде бик сирәк яңгырый. Катнаш исемнәр дә күп. Ир-атларның күбесенә алга *Габде* өстәлеп, Аллаһның исемнәре (**Габдесамат, Габделлатыйф, Габдесаттар** кебек) һәм *Мөхәммәд* исеме кушылса (**Мөхәммәдшәриф, Мөхәммммәдзакир, Бикмөхәммәд** кебек), хатын-кызларга *Биби* белән башланган (**Бибисабира, Бибифатыйма, Бибинәфисә** кебек) яки *Җамал, Камал* белән тәмамланган (**Хәбибҗамал, Хөсниҗамал, Хәсбиҗамал, Гайникамал** кебек) исемнәр бирелгән.

Ара-тирә үзебезнең борынгы, чын төрки-татар исемнәре дә очрый. **Бикташ, Бикбау, Бикчәнтәй, Бикчура** исемнәре XX гасыр башында инде кушылмаган диярлек. Әмма XIX гасырда туган әтиләре һәм бабалары арасында андый исемлеләр бар.

Социаль хәлгә килгәндә, авыл халкы нигездә игенчелек белән шөгыльләнгән. Метрикада бар баланың да диярлек әтисе *зәригатьче (игенче)* дип язылган. Сирәк кенә *солдат, мөәзин, мелла (мулла)* угыл-кызлары да күренә.

Гаиләләрдә балалар күп туган. Моңа ел да кабатланып торган бер үк әти-әни исемнәре дәлил. Бу хәл авыл халкының тулы исемлеген булдыруга һәм кайбер елларны мулла тарафыннан тулы язылмаган исемлекне төгәлләштерергә дә ярдәм итә.

ҮЛЕМ – КОТЫЛГЫСЫЗ...

1880 елларда ел саен диярлек 30-40 бала туса, аларның шактые яшьли үлгән. 1890 елда 36 кеше вафат булган. Шуларның 22се – бала. Үлем сәбәпләре – *зәгыйфьләнү, зыяндаш, тир зәхмәте, эч бору, тамак зәхмәте, ютәл зәхмәте, шеш.* Халык аеруча *ютәл зәхмәте*ннән еш кырылган. Гадәттә, гүр иясе 60 яшьтән арткан булса, метрикага *картлык* дип язганнар. 1890 елда картлык белән 3 кеше бакый дөньяга күчә. Калганы – яшьләр.

Ә инде йогышлы авырулар вакытындагы вазгыятьне күз алдына китерү дә авыр. 1848 елда холера чире котыра. Пенәгәрдә июль аенда гына да 31 кеше бу чирдән дөнья белән хушлаша. 1860 елда чәчәк авыруыннан 10 яшькә кадәрге 40ка якын бала вафат була. Ул елны барлыгы 64 җеназа укылып, ай саен 5-6 кеше бакый дөньяга күчкән.

1865 елда 66 кеше вафат булган. Аларның да күбесе – яшьләр. Сәбәпләренә килгәндә, беренче урында – зыяндаш авыруы, икенчедә ютәл һәм тамак чире тора. Хатын-кызлар арасында исә ютәл һәм тамак авырулары ешрак. Балаларын яшьли җирләгән хатын-кызларыбызга күпме кайгы-хәсрәт кичерергә туры килгәнен бер Ходай гына белә.

Сакланып калган 38 еллык метрикаларда 1005 кеше вафат булуы турында язылган (мәрхүмнәрнең яше күрсәтелгән)		
474 ир-ат		**531** хатын-кыз
1 яшькә кадәр	**127**	**94**
1-10 яшькә кадәр	**185**	**186**
10-60 яшькә кадәр	**93**	**196**
60 яшьтән өлкән	**69**	**55**
10 яшькә кадәр	**312**	**280**
10 яшькә кадәр барлыгы: **592 бала**		

Таблицадан күренгәнчә, 38 ел эчендә вафат булган 1005 кешенең күбесе – 1-10 яшьлек балалар (371), аннан кала – 1 яшькә кадәргеләр (221). Бер елга уртача 26 кеше вафат булып, шулардан 16сы 10 яшькә хәтле балалар булган. Моны гомер озынлыгын, медицина торышын күрсәтүче саннар, дип уйларга нигез бар. Алар авылыбыздагы тормыш дәрәҗәсен дә, табигый сайланышны да ачык күрсәтә. Халыкның иң ныклары, сәламәт булганнары гына исән калган.

Авылыбыз зур: 140 хуҗалыкта 750гә якын кеше яшәгән. Бер төр йогышлы авыруларның башка елларда да кабатлану очрагы булган. Хәзерге көндә еш очрый торган йөрәк, шеш авырулары ул чорда да күзәтелгән.

Никахлар бүлегендә ир-атның икенче яки өченче никахы турындагы язмалар бар. Моңа хатын-кызларның урта яшьләрдә еш үлеме сәбәп булгандыр. 1890 елда гына да 4 шундый очрак теркәлгән. 20-30 яшьләрдә вафат булучылар арасында хатын-кызлар аеруча күп. Алар ютәл, йөрәк зәхмәте һәм башка авырулардан бакый дөньяга күчкән.

НИКАХ һӘМ ТАЛАК

Безнең кулда булган метрика кенәгәләрендә барлыгы 281 никах теркәлгән. Безне мәктәптән үк борынгы әби-апаларыбызны «бик яшьли кияүгә биргәннәр» яки «үзләреннән бик олы кешеләргә кияүгә чыкканнар», дип өйрәттеләр. Әмма бу сүзләр дөреслеккә туры килми. Статистикага күз салсак, кызларыбызның күбесе без уйлаганча 13-19 яшьтә түгел, ә 20-25 яшьтә генә кияүгә чыккан.

Егетнең яше олырак булу табигый хәл итеп кабул ителгән. Кияүләр элек тә олы булгандыр, дип уйлаган идем, юк икән, ялгышканмын. Киресенчә, кызның яше олырак булган никахлар шактый.

Никахларга килгәндә, ир-атлар хатынны икенче авылдан, нигездә, Кукмара, Казаклар, Балыклы, Кәчимердән алган. Үз авылыбыз эчендәге никахлар саны аз. 281ләп билгеле булган никах арасында барлыгы 57 авыл 160 мәртәбә телгә алына.

Бер ел эчендәге никахлар күп түгел, аерылышулар да аз. Талак әйтүнең сәбәбе графасына *«өлфәт һәм мәхәббәт булмаган»*, дип язылган.

Никах вакытында егет кеше кәләше өчен мәһәр бирергә тиеш. Безнең якта ул калым дип атала. Никах язмаларындагы калымнарга игътибар итик әле.

16.01. 1852	Малмыж өязе **Пенәгәр** авылының ясашный зәригатьче **Мостафа Мөхәммәдрахим** улының кызы 24 яшендә булучы **Мөхибҗамал**ны шул ук **Пенәгәр** авылының ясашный зәригатче 21 яшендә булучы **Хөрәмша Гыйззәтулла** улына никахландырылды.	Кыз тарафыннан атасы **Мостафа Мөхәммәдрәхим** улы вәли вәкил булды. Кияү тарафыннан атасы белән бертуган агасы **Мөфәхәр Гыйззәтулла** улы вәли вәкил булды. Ир белән хатынның ризалыклары шаһидлары: әүвәл **Һибәтулла Сәлимҗан** улы тамгам салдым. **Корбангали Бәкер** улы тамгам салдым.	Мәһәр мөсәмме *йөз җитмеш сум*. Хәзердә *бер ат* белән *14 арбалы арыш кибәне – йөз ун сум*. Калганны мәзкүрә **Мөхибҗамал** сораган вакытта кияү булучы **Хөрәмша Гыйззәтулла** улы бирәчәк булып тамгам салдым. Мәзкүр шартка кызым **Мөхибҗамал**ның ризалыгы белән вәли вәкил булучы атасы **Мостафа Мөхәммәдрәхим** улы тамгам салдым.
22.02. 1869	Малмыж өязе **Пенәгәр** авылының ясашный зәригатьче **Тимергали Корбангали** улының кызы 21 яшендә булучы **Бибикадичә**не Казан губернасы Мамадыш өязе **Мазарасты** авылының ясашный зәригатьче 21 яшендә булучы **Габдерахман Галиәкбәр** улына никахландырылды.	Кыз тарафыннан атасы **Тимергали Корбангали** улы вәли вәкил булды. Кияү тарафыннан атасы **Галиәкбәр Габдерәхим** улы вәли вәкил булды. Ир белән хатынның ризалыклары шаһидлары: **Әхмәдша Йосыф** улы тамгам салдым. **Ибраһим Йосыф** улы тамгам салдым.	Мәһәр мөсәмме йөз тәңкә. Хәзердә илле тәңкә. Әүүәл *әдрәс* (8 тәңкә) *кашага* (2), *басма* (2), *ука* (5), *кәҗи* (3), *шәл* (5), *сандык* (3), *читек* (2), *яулык* (2), *3 төрле ситсы* (10 тәңкә), *9 тәңкә акча*, калганны мәзкүрә **Бибикадичә** сораган вакытта кияүнең атасы **Галиәкбәр Габдерәхим** улы бирәчәк булып тамгам салдым. Мәзкүр шартка разый булып атасы **Тимергали Корбангали** тамгам салдым.

Таблицада искә алынган әйберләрнең күбесен бүген безгә музейларда гына күрергә туры килә. Никах язмалары авыл халкының тормышын (мәһәр күләме буенча), яшьләрнең никахка керү вакытын, нәселләрне өйрәнү өчен зур материал булып тора. Менә шушы язмалардан аерым бер нәселнең тамгаларын да күрәбез. Алар аркылы да туганнарны ачыкларга мөмкин. Тамгаларны өйрәнү аерым бер темага җирлек булып тора.

ИМАМНАРЫБЫЗ

Метрикалар ярдәмендә авылыбыз имамнары турында да шактый мәгълүмат туплый алдык. Чыганакның үзендә үк аны кайсы имам тутырганлыгы язылган. Бездә ул бер-берсен алыштырып килүче бер нәсел вәкилләре – **Йөзи Рәхим улы, Мөхәммәдсафа Йөзи улы, Габдерахман Мөхәммәдсафа улы, Гомәр Габдерахман улы**. Шулай итеп, имамнарның тулы бер шәҗәрәсен төзергә мөмкин. Бүген авылыбызда аларның 9 нчы буыны яши.

1902 елгы метриканың бер бите – имамнар, аларның кайда укуы һәм кайчан указ алуы, мәчетләр, авыл халкы турында аеруча саллы мәгълүмат бирә. Пенәгәр авылы турындагы шушы гаҗәеп кызыклы материални сезгә дә тәкъдим итү урынлы булыр иде.

Мәсҗид хозурында булган имам вә мөәзиннәрнең исем-фамилияләре һәм туган язуы язылыр	**Указларының ел вә число һәм әмерләре, шунда ук дәрәҗәләре язылыр**	**Гыйлем тәхсыйль иткән урыннары, остазлары язылыр**	**Бу метрика бирелгән авылның низам каршында булган исеме һәм мөселманча булган исеме язылыр**	**Бу мәсҗидкә караган авыллар булса, аларның исемнәре һәм бу мәсҗид белән авылга ничә чакрым икәнлеге язылыр**
Старший имам мелла Габдерахман мелла Мөхәммәдсафа улы Юзиев. 1835 сәнәдә, апрельнең 15ендә туган	1867 ел, 5 сентябрь, №445, имам җәмиг хатыйб мөслим	Мәчкәрә мәдрәсәсендә мелла Габдулла Яхъя улыннан тәхсыйл әл-гыйлем кылган	Низам каршында Пинигерский дип языладыр, мөселманча Пенәгәр авылы	Мөселманча Пенәгәр авылы дип исем кылынган һәм бу авылга караган утыз чакрым җирдә Яңа Пенәгәр исемендә авыл бар
Имам мелла Гомәр мелла Габдерахман улы Юзиев. 1865 елда	1890 ел, 29 сентябрь, №5775, имам мөслим	Мәчкәрә мәдрәсәсендә мелла Мөхлисулла мелла Мәксуд улыннан тәхсыйл әл-гыйлем кылган		

МЕТРИКА ҺӘМ КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

Хәзерге көндә районыбызда һәм күрше Кукмара төбәгендә Кара Чишмә исемле авыл юк. Әмма имамыбыз Пенәгәр исеме белән бергә «Кара Чишмә карьясе»н дә искә ала. Билгеле, анда туучылар да, үлүчеләр дә аз теркәлгән. Элек мин аларны укымыйча гына калдырып бара идем, әмма соңыннан өйрәнеп карасам, Кара Чишмә 1885 елда Иске Пенәгәрдән аерылып чыккан Яңа Пенәгәр авылы икән бит! Бу авылның метрика эшләрен дә Иске Пенәгәр имамы алып барган.

Шуны да онытмыйк: авылыбыз элек читтә урнашкан. Ул 1800 еллар башында гына бүгенге урынына күчеп утырмадымы икән, дип уйлыйбыз. Мәчетебез дә XIX гасырның икенче чирегендә салынган. Архив документларында 1835 ел дип күрсәтелсә дә, соңрак табылган чыганакта Балыклы авылыннан бер байның 1826 елда Пенәгәрдә мәчет салырга рөхсәт алуы турында әйтелгән. Рөхсәт шул елда алынып, тугыз ел эчендә мәчет төзелеп, анда беренче намаз уку вакыты яки гыйбадәтханәнең рәсми теркәлү датасы 1835 ел булгандырмы? Монысын без әлегә белмибез.

Пенәгәр авылы элекке язма чыганакларда «Пинигерь при ключе Пиар» дип теркәлгән. XVII-XVIII гасырдагы халык санын алу документларында Пенәгәр бары тик «Пиар» дип кенә язылган. Пенәгәр метрикасында «Азнаур» да телгә алына. Андый исемдәге торак урыны безнең тирәдә гомумән юк. Бу һәм башка мәгълүматлар киләчәктә тарихыбызны тирәнтен өйрәнү өчен тагын бер сәбәп булыр, дигән өмет бар.

***

Метрикаларны өйрәнеп, авылыбыз тарихы турында зур мәгълүмат тупланды. Авылдашларыбыз үзләренең әби-бабаларын ачыклап, нәсел шәҗәрәсен тулыландырды. Без яңа гына өйрәнә башлаган әлеге тема үзендә күп сер саклый. Әлбәттә, кечкенә генә мәкаләдә метрикаларны тулысынча ачып бетереп булмас. Шулай да, укучыларда өйрәнелә торган материал турында күзаллау барлыкка килер, кызыксыну артыр, дип уйлыйм. ■

Гасимә Мостафина (уртада) иптәшләре белән. 1932 ел

«Сәнәкчеләр» фаҗигасе

Гасимә Мостафина-Рәфыйкова

Габдулла абый, карт чуаштан котылырга теләп:

– Ул авыру. Мин аны Әлмәткә илтәм, – диде. Әмма карт, аның ай-ваена карамыйча, атның дилбегәсеннән тотып, безне комендантка алып китте.

– Син нәрсә коммунистканы яшерәсең? – дип ябырылды Габдулла абыйга комендант һәм шунда ук Габдулла абыйны кире Чыршылыга озатырга, ә мине кулга алырга боерды. Инде акылдан шашар хәлгә җиткән, фикер йөртерлек хәлдә түгел идем.

Мине нindидер караңгы чоланга бикләп куйдылар. Шунда төн үткәрдем.

Иртән көн аяз-кояшлы, салкын иде. Канцелярия бүлмәсенә китерделәр. Чыршылыга ничек эләгүемне сорап газаплаганда мине бер кеше танып алды. Ул әниемнең Миңлебай авылында туган, хәзер исә чуаш авылында яшәүче ерак кардәше булып чыкты. Әлеге туганым сорау алучыларга кем икәнемне аңлатып бирде һәм үз кулына тапшыруны сорады. Килештеләр. Аннан мине Миңлебай авылына илтеп, әниемнең абыйсы Хәйретдингә тапшыру турында вәгъдә алдылар. Шулай итеп, ул Миңлебай авылына алып китте.

Ахыры. Башы журналның 3 нче (2018 ел) санында.

Гасимә Мостафина (уңнан беренче) Евпаториядә ял иткән дус кызлары белән. 1938 ел

Хәйретдин абзый, бик куркак һәм надан кеше, йоклар алдыннан намазлыкка басып, үз йортында зур «җинаять» кылган кызны кабул иткән өчен, Аллаһтан кичерү сорады.

Йокларга ятсам да, күзне йоммадым. Онытыла башладым, дигәндә генә, күз алдыма кулына сәнәк тоткан кеше килеп баса һәм мин тирән чокырга очам...

Иртән уянгач, Хәйретдин абзый урамга чыкты һәм тиздән ниндидер ир кешене ияртеп керде. Аннары кискен тавыш белән аңа:

– Менә бу аяклы казаны тизрәк Әлмәткә илтеп куй! – дип боерды.

– Киттек, – диде миңа әлеге кеше һәм без урамга чыктык.

Хәйретдин абзый белән аның хатыны Зифа апа бик зур җинаятьчедән котылган кыяфәт белән озатып калдылар.

1920 елның соңгы көннәре үтеп бара. Мин – гомеремне Ватанга хезмәт итүгә, яшь буынга белем бирүгә багышлаган татар кызы, менә шундый түбәнсетүләрдән, мәсхәрәләүләрдән соң, ниһаять, туган авылым Әлмәткә кайта алдым.

Әлмәт. Анда минем әтием яшәде. Мине Бәкер-Иштирәк авылына укытучылык итәргә илткәндә ул үз кызының томана кешеләр тарафыннан шундый түбәнсетүләргә дучар ителәчәген күз алдына китермәгәндер.

Әлмәткә кайткач, озак авырдым. Йоклаганда: «Сәнәкләр!» – дип кычкырып, торып утырганмын. Идәнгә сикереп төшеп, җәзалаучылардан котылырга теләп, сәке астына яшеренгәнмен. Бу хакта миңа, терелгәч, тынычлангач, туганнарым сөйләде. Миндә көчле психик киеренкелек күзәтелде.

Туганнарым ярдәмендә, савыгып, аякка бастым. Фаҗигале кичерешләрне тыныч тормыш агышы алыштырды. Элеккеге халәтемә кайттым.

Миңа Чыршылы авылында калган иптәшләремне кызылармиячеләр отряды коткаруын әйттеләр. Бу тормышыма яктылык өстәде.

Тагын бер ай узды. Март җитте. Әлмәт авылында тыныч. Мәхмүт Исхаков белән Нури Каматов Әлмәттәге активистларның хатыннары өчен наданлыкны бетерү курслары оештырды. Барлыгы 12 кеше җыелды. Алар арасында Мәхмүт Исхаков тәрбияләгән 15 яшьлек яшүсмер Локман Шәрәфиев тә бар иде.

Һәм менә мин, күпме фаҗигале хәлләр кичергәннән соң, бу кешеләрне укырга-язарга өйрәтә башладым. Курслар май азакларына хәтле эшләде.

Ватаныма нормаль шартларда хезмәтем шулай башланды.

«Сәнәкчеләр» восстаниесе бастырылды... Аның ничек башланып китүен, күпме фаҗигале вакыйгаларга сәбәпче булуын, халыкны агарту өлкәсендә хезмәт куючыларның ничек зыян күрүен кыскача тасвирлап үтәргә карар кылдым...

1919 елның соңгы айларында Әби дигән татар авылындагы кулаклар, Аналык һәм Чыршылы авылындагыларны да берләштереп, баш күтәрәләр. Җитәкчеләре – комендантлар, оештыручылар Куакбаш авылында була. Шундый көчләр Карабаш, Бөгелмә тирәсенә дә туплана. Аларның лозунглары яшь Совет хакимиятен юк итү, иске тормышны кайтару була. Моның өчен күп көч куярга кирәкми. Һәрбер авылда укытучылар, медицина хезмәткәрләре, Советларның җитәкчеләре бар. Әгәр ул кешеләрне юк итсәң, Совет хакимияте бетәчәк. Беренче чиратта менә шуларны юк итәргә – атарга, асарга, бозлы суга батырырга кирәк! Әби авылыннан шундый лозунг белән килгән беренче башкүтәрүчеләр Чыршылыда рус укытучысы Зоя Зверкованы, китапханә мөдирен һәм аның хатынын атып үтерәләр. Хәрби комиссариатта постта торган дүрт кызылармиячене урамга алып чыгып аталар. Карабаш авылында явызлар укытучы Хәбибҗамал Катееваны Зәй елгасына ташлыйлар. Ул, батмыйча, икенче бәкедән калкып чыккач, кулларын сындырып, яңадан суга салалар. Шулай итеп, аның гәүдәсе Зәй елгасы төбендә кала. Фетнәчеләр ана булырга җыенган укытучы Гафифә Ишкининованы: «Корсагыңда тагын бер коммунист бар, шул коткарыр сине!» – дип кычкырып, күпердән ыргыталар. Нәдер авылыннан укытучы Тәзкирә Ильясованы, Нәдер һәм Кәшер авыллары арасындагы кечкенә урманга алып барып, агачка бәйләп куеп, газаплы үлемгә дучар итәләр. Бәкер авылы балаларына дәрес биргән Фатыйх Туйкинны, класстан сөйрәп чыгарып, үтергәнче кыйныйлар. Укучысы Рамазанованың Фатыйх Туйкин өстеннән салдырылган киемнәрне саклавы турында хәбәр иткән хаты әле дә югалмаган. Куакбаш авылында укытучы Касыйм Насыйбуллинны, мәктәптән алып чыгып, бик каты кыйныйлар һәм үлгән дип уйлап, мәктәпнең ат абзарына ташлыйлар. Ул нindидер могҗиза белән исән кала. Куакбаш авылына килгән кызылармиячеләр, фетнәне бастырып, аны шуннан табып алалар. Касыйм аңына килә. Дәвалангач, ул

Гасимә Мостафина (уртада) «Правда» газетасындагы мәкаләне тикшергән җыелыш вакытында. 1950 нче еллар

әле озак еллар буе Әлмәт шәһәре Дәүләт банкы директоры булып эшли. Минем белән тоткынлыкта булган Зифа Исламова, үзен һаман эзәрлеклиләр дигән уй белән газапланып, акылдан яза.

Биредә санап үтелгән иптәшләр – Татарстандагы «Сәнәкчеләр» фетнәсе вакытында төрле газапларга дучар ителүчеләрнең мин хәтерләгәннәре генә. Күпме алар? Анысын тарих кына белә...

Бу фаҗига озакка сузылмады, әмма шул кыска гына вакыт эчендә дә күпме кадерле иптәшләребез һәлак булды!

Гражданнар сугышы тәмамлангач, Бөгелмәдә башкүтәрүчеләр өстеннән суд ясалды. Коралны ташларга мәҗбүр булган фетнәчеләрне һәркөнне, берәрләп кенә түгел, ә дистәләп атып үтерделәр.

Тыныч тормыш башланды. Авыр чор артта калды. Әлеге фаҗигале вакыйгаларны берләштереп, яшь буынга гыйбрәт итеп, зур әсәр язучы булмады. Бу фаҗигале вакыйгаларда зыян күрүчеләр каяндыр читтән килүчеләр түгел бит, үзебезнекеләр – моның сәбәбе шундадыр, дип уйлыйм. Шуңа күрә, әле күзләрем күргәндә, кулым ручка тота алганда, үзем күргән-белгән кадәрлесе турында язып калдырырга карар кылдым.

Вакыт үтәр, мин инде булмам. Бу юлларны, мине кем дә булса искә төшереп, шушы дәфтәрне укып чыгар, дигән өмет белән язам.

1986 елның ноябре. Миңа 86 яшь. Күпме гомерем калгандыр.

Укучы, бәлки, нигә ике фамилия, дип уйлар?

Беренче ирем белән без 1921 елның маенда яши башладык. 1925 елның 27 сентябрендә ул, мине ике бала белән тол калдырып, вафат булды.

1939 елга хәтле ялгыз гомер иттем. Шул елны Габдулла Мостафинга кияүгә чыктым. Ул Фин сугышына китте һәм әйләнеп кайтмады.

Шуңа күрә бу ике фамилияне дә йөртергә хокукым бар, дип уйлыйм.

РЕДАКЦИЯДӘН: *Гасимә Мостафина-Рәфыйкованың бердәнбер улы Үзбәк Гариф улының кызы Светланага, әбисенең тарихи истәлекләрен кадерләп саклаган өчен, ихтирам һәм рәхмәтебезне белдерәбез.* ■

ТАТАРЛАРНЫҢ КАЗАКЪСТАН ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

Морат Кәримов

Казакъ ханы Тәвәккәл (1586-1598 елларда идарә итә), хәрби берлек төзү максатында сөйләшүләр алып бару өчен, Мәскәүгә Колмөхәммәт җитәкчелегендәге илчеләрен җибәрә. Ә урыс патшасы Федор Иванович (ялгышлык белән Иван Федорович дип язылган. – **М.К.***) 1595 елда Тәвәккәл ханга үз илчесен юллый. Вельямин Степанов җитәкчелегендә 1595 елның 28 мартында җибәрелгән әлеге делегациягә, тәрҗемәче итеп, татар Данило Семенов (керәшен. –* **М.К.***) та кертелә. Федор Иванович та илчеләре алдына берлек төзү максатын куя. Хәер, урыс патшасының планнары күпкә зуррак була. Ул казакъ ханын Урта Азия ханлыклары белән уңышлы сөйләшүләр алып баруда, казакъ гаскәрләре белән берләшеп, Себер ханы Күчемгә каршы хәрби походта файдаланырга, Бохара ханлыгы белән сугышу өчен, Тәвәккәл ханны фарсы шаһы Габбас белән берлек төзүгә этәрергә уйлый.*

Урта җүз ханы Есем вакытында, Җәмеш күленә (ул хәзерге Ялышево, Павлодар өлкәсе биләмәсенә керә), тоз чыгару өчен, 20 йомышлы татар килә. Иртыш елгасы ярлары буенда яшәгән Урта җүз казакълары бу якларга элегрәк килеп чыккан татарлар белән таныш була. Алар үзара авырлыксыз

аралашканнар, чөнки казакъ һәм татар телләре бик охшаш. Татарлар Иртыш буенча Кытайга, ә Сырдәрья буенча Төркестан, Ташкент һәм Бохарага кәрваннар йөрткән, ягъни татарлар монда элек тә булган.

Морза, генерал-майор (1755), Петр Інең Прут (1711) һәм Фарсы (1722-1723) походларында, 1717 елда кенәз Бекович-Черкасскийның казакъ далалары аша Урта Азиягә икенче экспедициясендә катнашкан А.И.Тәфкилев Хива ханы Шергазы Бекович-Черкасскийны һәм 4 мең экспедиция әгъзасын үтергәндә дә ничектер исән кала...

XVII гасырда бирегә илчеләр, сәүдәгәрләр һәм сәнәгатькәрләр делегациясе еш килә. Йомышлы татарлар хәрби йөкләмәләр дә үтиләр, калалар һәм кирмәннәр төзүдә дә катнашалар. Татар сәүдәгәрләре һәм йомышлылары казакълар һәм Урта Азия җирләре белән шәһәрләре турында кыйммәтле мәгълүматлар җыюда, бу җирләрнең карталарын төзүдә ярдәм иткәннәр. Әлбәттә, Россия әлеге карталарны киләчәктә бу киң биләмәләрне басып алу нияте белән дә төзегән. Әмма Казакъстан, Үзбәкстан һәм Урта Азиянең башка дәүләтләренең география фәне өчен ул уңай рольне дә уйный.

Г.Т.Жораева үзенең диссертациясендә билгеләп үткәнчә, Тәүке хан XVII гасырда, Җунгар ханлыгы оештырылу уңаеннан, ханлык чикләрен ныгытырга кирәклеген аңлый. Моның бер юлы булып, Рус дәүләте белән элемтәләрне җайга салу тора. Әлеге максатта Тобольскида илчелек булдырыла. Аны Ташим батыр җитәкли һәм илчелек составына казакъ һәм урыс телләрен белгән татарлар Ильчигинеев һәм Териков кертелә. Алар тәрҗемәче булып хезмәт итә, дипломатик сөйләшүләр алып бара ала. Илчелек Тобольскида 3 ел яши. Тәүке хан исә 1680-1718 елларда идарә итә. «Дипломатия теле»н белгән кешеләрне табу өчен, анда яшәүчеләрнең күп санлы булуы кирәк. Шулай булгач, бу вакытка (XVII гасыр) казакъ ханлыгында (өч җүз ханлыкларында) шактый татарлар яшәгән. Г.Т.Жораева татарларның Казакъстанга, аның шәһәрләренә күпләп күчеп килү вакытын XVIII гасыр дип саный. Аның фикеренчә, Оренбургка нигез салыну вакытыннан *(1735 ел, бу каланы торгызуга татарлар зур өлеш кертә. –* **М.К.***)* башлап, ул татарлар өчен иркен, уңайлы яшәү урынына әйләнә.

Әбелхәер хан Кече җүзне (шулай ук Урта җүзнең бер өлешен дә) Русиягә кушуны 1731 елда гамәлгә ашыра. Россия исеменнән сөйләшүләрне Котлымөхәммәт Мәмәш улы Тәфкилев (чукынганнан соң аңа Алексей Иванович Тевкелев исеме бирелә) алып бара. Аның нәсел шәҗәрәсе Алтын Урданың Барак һәм Куерчык ханнарыннан башлана. Морза, генерал-майор (1755), Петр Інең Прут (1711) һәм Фарсы (1722-1723) походларында, 1717 елда кенәз Бекович-Черкасскийның казакъ далалары аша Урта Азиягә икенче экспедициясендә катнашкан А.И.Тәфкилев Хива ханы Шергазы Бекович-Черкасскийны һәм 4 мең экспедиция әгъзасын үтергәндә дә ничектер исән кала... Ул шул вакытлардан бирле казакъ далаларын, казакъларның көнкүрешен, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен яхшы белә. Тәфкилев, Оренбург краенда 1730 елдан бирле хәрби-административ хезмәттә булып, Кече җүз ханы Әбелхәер Россия

империясе белән алып барган сөйләшүләрдә турыдан-туры катнаша. Россия империясенә тугрылык антын Кече җүзнең 28 ыруы һәм Урта җүзнең 28 ыруы имзалый.

1735 елда Оренбург белән янәшәдә Каргалы авылына нигез салуга да татарлар зур өлеш кертә. Башта монда Сәгыйть Хәялин белән 200 татар килеп урнаша. Каргалы авылы зур сәүдә үзәгенә әйләнә. Сенатның 1744 елдагы карары нигезендә, биредә «Татар бистәсе» торгызыла. 1761 елга Каргалыдагы сәүдәгәрләр саны 1160 кешене тәшкил итсә, 1765 елга ул 1600 кешегә җитә.

Сәгыйть Хәялинның туганы Габдулла Хәялин Урта Азия белән ирекле сәүдә итү хокукы бирелгән сәүдә компаниясе оештыра. Татарлар Россия-Казан-Казакъстан-Урта Азия сәүдәсенең тоташтыргыч буыны булып торалар. Шулай итеп, 1760 елда Кече җүз белән Урта Азия арасындагы сәүдә тулысынча казан татарлары кулында була. Бу вакытта Кече җүздә һәм Оренбург губернасында дистәләрчә мең татар яшәгән, дисәк, һич кенә дә арттыру булмас. Ханнар, солтаннар һәм старшиналар алар арасыннан хезмәткә эш алып баручылар һәм тәрҗемәчеләр алганнар.

1748 елның 1 августында Кече җүз ханы Әбелхәер аның иске көндәше – Урта җүз солтаны Барак тарафыннан үтерелә. Нәтиҗәдә, Кече һәм Урта җүзләрнең казакъ ырулары арасында дошманлык кабына. Әбелхәер ханның уллары һәм тарафдарлары аның үлеме өчен үч алу теләге белән яналар. Мәрхүмнең хатыны Бопай (Пупай) ханбикә һәм уллары, Бароктан үч алуда ярдәм итүне үтенеп, аны эзәрлекләп җәза бирү өчен, губернатор Неплюевтан гаскәр җибәрүне сорыйлар (Бопай ханбикәнең һәм Хуҗа Әхмәтнең 1748 елның 28 августында язылган хаты).

1748 елның 29 августында Неплюев хан гаиләсенә тәрҗемәче Гуляевны һәм башкорт старшинасы Күбек белән татар Галине (фамилиясе күрсәтелмәгән) җибәрә. Тәффкилевнең киңәше буенча, алар белән элек Әбелхәер ханның улы Нуралидә хезмәттә булган, хәзер инде Орск кирмәне атаманы Исмәгыйль муллага да барырга кушыла. Гуляевка исә мондый күрсәтмәләр бирелә: Бопай ханбикәнең һәм улларының ниятләрен ачыклап, алар артыннан күзәтеп торырга; Барак солтаннан үч алуны булдырмый калырга; яңа ханны сайлауга катнашмаска, ә инде ул сайлангач, аның старшина һәм бәйләрен, Нуралине хан буларак раслату үтенече белән, император галиҗәнапларына барырга күндерергә. Шулай булмаган очракта, Нурали хан дип йөртелә һәм хаким буларак имза куя алмас иде. Башкача әйткәндә, Гуляев, илче вазыйфасын башкарып, дипломатик миссия үти. Моңа Гуляевның, Әбелхәер хан улы Нуралинең кияве (кызының ире) Җанибәк солтан һәм 7 старшина белән, Нуралине хан итеп раслату өчен, Санкт-Петербургка бару факты дәлил. Әлеге фактка Неплюев һәм Тәфкилевнең, Хивага юл тоту өчен, 20000 мең сумлык сәүдә кәрваны әзерләвен һәм аңа Гуляевның дипломатик вәкил буларак кушылуын да өстәргә мөмкин. ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

«ХАТЫННАРЫ ТӘРБИЯЛЕ БУЛГАН МИЛЛӘТ – ТӘРБИЯЛЕ...»*

Диләрә Гыймранова

Төрле өлкәдә үзен таныткан галим Ризаэддин Фәхреддиннең мирасы күпкырлы. Ул – тарихи фактлар нигезендә мөхтәрәм шәхесләребез турында күптомлы «Асар» исемле энциклопедик басманы әзерләгән тарихчы, әдәп-тәрбия мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнеп, «Гыйльме әхлак» («Әхлак гыйлеме») сериясендә бер-бер артлы нәсыйхәт китапларын язган киң колачлы педагог, дин гыйлеменең барлык нечкәлекләрен тәфсилләп тикшереп халыкка аңлаткан дин әһеле, татар әдәбиятында хатын-кыз проблемаларын күтәргән, мәгърифәтчелек идеяләрен укучыга җиткергән әдип.

Р.Фәхреддиннең хатыны Нурҗамал абыстай кызлары Зәйнәп, Әсма һәм сеңлесе Нургаян белән

* Узган елның ноябрь аенда Әлмәт районының Кичүчат авылында, Р.Фәхреддиннең кызы Әсма Шәрәфнең тууына 110 ел тулу уңаеннан, «Р.Фәхреддин: рухият, мәдәният һәм мәгърифәт. Кыз бала тәрбияләгәндә...»дип аталган II Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булды. ***Фотолар – beznenmiras.ru сайтында.*** Бу мәкалә Р.Фәхреддин мемориаль музееның директоры, филология фәннәре кандидаты Диләрә Гыймранованың шул конференциядә ясаган чыгышы нигезендә әзерләнде.

Җәмгыятьтә нинди вазыйфа башкаруына карамастан, мәгърифәтченең игътибарыннан уку-укыту һәм тәрбия-әхлак мәсьәләләре беркайчан да читтә калмаган. Р.Фәхреддин тәрбия темасына язган әсәрләрендә балалар, төрле буын кешеләренең аңзиһенен, әдәп-әхлагын кайгырта. Галимнең **«Тәрбияле бала»**, **«Тәрбияле ана»**, **«Әһле гыяль»**, **«Тәрбияле хатын»**, **«Шәкертлек әдәпләре»**, **«Нәсыйхәт. Балалар өчен»**, **«Нәсыйхәт. Кыз балалар өчен генә»**, **«Нәсыйхәт. Олуг вә бөекләр өчен»**, **«Адабе тәгълим»**, **«Гаилә»** исемле китапларын тормыш дәреслекләре дип тә атарга мөмкин.

Р.Фәхреддин: *«Дөньяга килгән сәгать белән, балалар тәрбиягә мохтаҗлардыр, боларны тәрбияләүчеләр дә аналардыр»*, – дип яза. Шуңа күрә, ана буласы хатын-кызның үз-үзен тәрбияләү мәсьәләсенә аеруча игътибар итә. Галим фикеренчә, бала тәрбияләү – ананың гаиләдә генә түгел, ә бөтен җәмгыять алдындагы изге һәм җаваплы бурычы. Әни кеше үз балалары белән тыныч һәм тигез тавыш белән сөйләшергә, аларны кызыксындырган сорауларга сабыр гына җавап бирергә тиеш. Шул ук вакытта балаларны, кече яшьтә булуына карамастан, кылган гамәлләре өчен җавап тота белергә өйрәтүнең дә мөһимлеген ассызыклап китә ул. «Тәрбияле бала» әсәрендә Р.Фәхреддин: *«Тәрбия һәм әдәп кадәр кешеләрне сөекле күрсәткән нәрсә дөньяда юктыр, шулай ук тәрбиясезлек, әдәпсезлек кадәр дошман күрсәткән нәрсә дә юктыр»*, – дигән асыл фикерен әйтә.

Кыз балалар өчен генә язылган «Нәсыйхәт» әсәрендә галим олы үгет-нәсыйхәтен белдерә: *«Бөтен гомерегез – кызлык, хатынлык, аналык диелгән өч хәлдән гыйбарәт булганлыктан вә хәстәләрне карау хезмәте дә бу кешеләрнең хезмәте булганлыктан, бу хезмәтләрне игътибар белән үтәгез!»* Р.Фәхреддин нәсыйхәтенең ахырында кыз балаларга китаплардан, яхшы кешеләрдән гыйбрәт алырга кирәклеген ассызыклый, мәгърифәтче буларак, аларга: *«Әхлагыгызны бозмас, кызлык, хатынлык, аналык вазыйфаларына кимчелек итмәс вә белгәннәрегез белән тәкәбберлек итмәс шарты белән, ни булса да булсын, укыгыз!»* – дип, аларны гыйлем алырга өнди.

Олуг вә бөекләр өчен язылган «Нәсыйхәт» әсәрендәге «Гыйлем әдәпләре» дигән бүлектә: *«Һәрбер кеше вә һәрбер кавем вә милләтнең бәхетле булуларына баш сәбәп – гыйлемдер. Ашлыклар өчен яңгыр никадәр кирәк булса, адәм баласы өчен дә гыйлем шул рәвештә кирәкледер»*, – дип билгеләп үтә ул. «Шәкертлек әдәбе» хезмәтендә гыйлем алырга балаларны ничек чакырган булса, олуг вә бөекләрне дә белем үзләштерергә, һәрдаим үз-үзләрен тәрбияләргә һәм камилләштерергә өнди. Ләкин белем тәкәбберлек ниятеннән яисә башкаларның дәрәҗәсен төшерү исәбеннән булырга тиеш түгел, ә җәмгыятькә файда итү, балалар тәрбияләгәндә куллану, милләтебезне үстерү өчен кирәкле булганга күрә үзләштерелергә тиеш.

Балаларны тәрбияләгән вакытта, гадел һәм инсафлы итү белән бергә гүзәл холыклы булулары өчен дә тырышырга кирәк. Бу – аталарның иң изге бурычы. *«Балаларыгызны кеше дип санап, аларның адәм булуларын теләсәгез, аналары белән гүзәл вә шәригать әдәбе белән могамәлә итегез»*, – дип, Р.Фәхреддин ирләргә мөрәҗәгать итә. Бала кече яки олы яшьтә булуга карамастан, уллар – этисенә, ә кызлар әнисенә охшарга тырыша. Ана кешегә ата хөрмәт күрсәтми икән, ир бала да анасына карата мәрхәмәтсез булып үсәргә мөмкин. Галим фикеренчә, үз анасын ихтирам итмәгән ир бала, киләчәктә, гаилә башлыгы буларак, үз хатынын да атасы үрнәгендә хөрмәт итмәс. «Җәвәмигуль кәлим шәрехе» дип аталган күләмле хезмәтендә пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.): *«Хатыннар өстендә булган хакларның олысы – ир хакы, ирләр һәм хатыннар өстендә булган хакларның олысы – ана хакыдыр»*, – дигән хәдисен аңлатып, Р.Фәхреддин, ирләр өстендә хатыннарның да, аналар вә аталар өстендә балаларның да хаклары барлыгын раслый.

Мәгърифәтче, хатын-кызның аз чыгымлы вә аз мәшәкатьле булуы гаиләнең тыныч-

Хатыннарына кул күтәреп, җикеренеп-кычкырып торган ирләр үзләре дә, яндагылары да гаилә тынычлыгын күрә алмас, мондыйларга бәрәкәт тә иңмәс.

лыгын, бәрәкәтен тәэмин итә, дигән фикерне язып, гүзәл затларыбыздан чыгымнарны кыскартуны үтенә. Югыйсә, мода корбаны булган хатыннар ирләрен утка салып, гаиләнең тынычлыгын алыр һәм аның таркалуына сәбәп булыр. Мондый тәрбиясез хатын-кызлар турында Р.Фәхреддин «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәрендә аерым тукталып, тәфсилләп яза: *«Кием вә җиһазлар белән мактанышып бу дөньяда бер исем калдырыр, бизәнү әйберләрен бер-береннән арттырыр өчен бар көчләрен сарыф итәләр... Үзенә махсус тегелгән күлмәк белән туйга бармаса, бу кадәр олы гаеп һичничек булмас... Ике туйга бер үк күлмәк кию – тәрбиясезлек... Билгеле булганча, мондый тормышта яшәргә гадәтләнгән хатыннар ирләре өчен артык исраф, балалары өчен әдәпсезлеккә үрнәк, шуңа күрә мондый хатыннар күп вакытта милләтебезне өметсезлеккә илтәләр».*

Тәрбиясез, әхлаксыз хатыннар турында сөйләгәндә: *«Яшьлек – диваналыкның бер ботагы, хатыннар – шайтан ауларыдыр»*, – дигән хәдисне дә искә төшерү урынлы. Галим, бу хәдисне аңлатканнан соң, мондый нәтиҗәгә килә: *«Яхшы тәрбия бирмәсәң, хатын шайтан булыр, яхшы тәрбия бирелсә, хатын фәрештә булыр»* . Димәк, хатынны тәрбияләү – ирнең бурычы. *«Каралмаган агачтан яхшы җимеш хасил булмаса, яхшы тәрбия бирелмәгән хатыннардан да фазыйләтле вә инсафлы хатыннар җитешүне көтәргә нинди хак бар»*, – ди Р.Фәхреддин. Ирләрнең яхшылары вә яманнары булган кебек үк, хатыннарның да усаллары вә яхшылары булырга мөмкин, ләкин биредә гаеп күбрәк ирләр өстендәдер, *«...чөнки хатыннарның тәрбияләре ирләргә бурыч булганлыктан, шул бурыч яхшы үтәлсә, лязем булган хезмәтләр сарыф ителсә, табигый, хатыннар да яхшы булып җитешерләр»*, – дип, автор хатыннар тәрбиясенең бар җаваплылыгын ирләргә йөкли. Педагог фикеренчә, ир кеше үз хатынын риясыз сөяргә, аны ышанычлы иптәш дип белергә, сөеклесен һәртөрле авырлыклардан сакларга, аңа җил-яңгыр тидермәскә, йомшак сөйләшергә, артык уен-көлке итмәскә, яхшы нәсыйхәт биреп, шуның белән гамәл кылырга, гайбәтче хатыннар белән катышудан сакларга, малны дөрес сарыф итү белән эш кылу турында һәрвакыт искәртеп торырга, үзе алдында аны кешеләргә мактамаска, хәләл белән хәрамгә сәбәпче булачак эшләрдән хәбәрдар булырга өндәргә тиеш. Хатыннарына кул күтәреп, җикеренеп-кычкырып торган ирләр үзләре дә, яндагылары да гаилә тынычлыгын күрә алмас, мондыйларга бәрәкәт тә иңмәс. Шуңа күрә Р.Фәхреддин, үз хезмәтләре ярдәмендә, хатыннарын тәрбияләүче ирләрнең үз-үзләрен тәрбияләргә кирәклеген дә ассызыклый.

Ислам дине буенча хатын-кыз иренең йөрәгенә үтеп керергә омтылырга тиеш. Моңа ирешү юлының берсе – аның шатлыкта да, кайгыда да ире янында булуы. Хатын кешегә иренең барлык кайгыларын да уртаклашып, шатлыкларын бүлешеп яшәү шарт. Ул иренең көндәлек тормышында аның белән бергә булса гына ир кеше үзен ялгыз хис итмәячәк, сөеклесе янәшәсендә ләззәтле тормыш кичерәчәк.

Р.Фәхреддин гаилә коруның мөселманнар өчен үтә дә җаваплы гамәл һәм мөһим бурыч икәнен төшендерә. Никахлашкан парларның яше һәм әхлагы, гыйлеме һәм табигате бер-берсенә туры килгән очракта гына гаилә ныклы булыр. Галим фикеренчә, гаилә төзек булмаганда һәм тәрбия ысулына нигезләнмәгәндә, милләт ничек кенә бөек булса да, яши алмаячак. Риза хәзрәт милләтләрнең дәрәҗәсен күтәргән һәм аны саклаган нәрсәнең дә гаилә икәнен аңлатып бирә. Милләтнең үсешен тәэмин итү өчен нәкъ менә гаиләнең төзеклеген һәм әхлагын кайгырту иң әүвәлге эш булып тора. Ә гаиләдәге бөтен кешенең бәхет-сәгадәте тәрбияле хатын кулында. Әгәр дә хатын тәрбиясез икән, барчасы да бәхетсез булачак. Р.Фәхреддин фикеренчә, ир кеше ничек кенә гайрәтле

Р.Фәхреддин фикеренчә, ир кеше ничек кенә гайрәтле булмасын, хатыны тәрбиясез икән, аннан да бәхетсез кеше булмас.

булмасын, хатыны тәрбиясез икән, аннан да бәхетсез кеше булмас. Чөнки чын бәхет – тәрбияле хатын белән гаилә корып, рәхәт гомер итүдән гыйбарәт. Шулай булгач, иң кирәкле шәхес тәрбияле хатын булып, милләт аның йогынтысында зур файда күрәчәк.

«Гаилә» әсәрендә: *«Хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле; хатыннары тәрбиясез булган милләт – тәрбиясез; хатыннары тырыш милләт – бай; хатыннары ялкау яки исраф итүчән милләт фәкыйрь буладыр»*, – дип, Р.Фәхреддин хатын-кыз мәсьәләсенең милләт өчен көнүзәк проблема икәнен ассызыклый. Милләтнең бербөтен булып калуын да педагог хатын-кызлар әхлагыннан күрә. Дәүләтнең бер күзәнәге булган гаиләнең ныклыгын тәэмин итү дә хатын-кызга йөкләнгән. *«Изге хатын – бетми торган хәзинә булганы кебек, бу дөнья сәфәрендә иренә юлдаш, мәшәкатьләрдә юатачак юаныч, авырлыкларда таяныч булыр»*, – дип яза Р.Фәхреддин. Балаларына тәрбия бирә белмәгән һәм гүзәл холыклар өйрәтә алмаган хатыннарны автор: *«Милләт эчендә чума авыруы микробыннан да зарарлы булган кешеләр җитештерерләр»*, – дип тасвирлый. Галим фикеренчә, мондый балалар үсеп җиткәннән соң, ата-анасы башына күпләгән газап һәм хәсрәт алып килерләр, милләтнең артка таба тәгәрәвенә сәбәпче булырлар.


نصيحت

اوچونچی

الوغلر وبيوكلر اوچون

(علم اخلاقدن توقزنجی جزء)

اثر:

رضاء الدين بن فخرالدين .

اورنبورغ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ناشری: قزانده

Казань

ЭЛЕКТРО-ТИПОГРАФІЯ

Миллятъ

1909.

Р.Фәхреддиннең «Нәсыйхәт» китабы. 1909 ел

«Ана булу – бөек бер нигъмәт, муллык вә тиңдәше булмаган бер хөрмәт икәнлегенә шик юктыр. Мондый хөрмәткә аналык вазыйфасын вә хатынлык хезмәтләрен җиренә җиткергән затлар гына лаеклы булалар», – дип, Р.Фәхреддин гүзәл затларыбызны олы җаваплылыкка өнды.

Күрүебезчә, галимнең педагогик хезмәтләрендә хатын-кыз – милләтнең йөрәге, ир-ат – аның акылы. Р.Фәхреддин фикеренчә, хатыннарның тәрбиясе – ирләр, гаилә һәм милләтнең тәрбиясе хатын-кызларыбыз кулында. Алар, бер-берсенә терәк, бер-берсенең тәрбия һәм камилләшүенә этәргеч булып, гаилә корганда һәм әхлаклы, инсафлы балалар тәрбияләп үстергәндә генә тулы, матур җәмгыять төзеп булачак. Милләтебезнең киләчәге дә менә шундый бәхет-сәгадәт дәрьясында йөзгән гаиләләрнең күп булына бәйле. ■

«ТЮРК-ТАТАР ДЮНЬЯСЫНА НУР САЧКЪАН ТУКЪАЙ!»

(Сугышка кадәрге Кырымда Габдулла Тукай)

Исмәгыйль Кәрим*

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай кырым татарлары белән шәкерт чагында ук, 1895-1906 елларда Җаек шәһәрендәге «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда таныша. Мәдрәсәдә аны урыс теленнән танылган кырымтатар педагог-мәгърифәтчесе ***Бекир Эмекдар*** *укыта. Ул, беренчеләрдән булып, 1884 елда Бакчасарайның «Кайтаз ага» мәктәбендә яңа ысул белән укыта башлый һәм 1903-1907 елларда, «ысуле җәдид»не пропагандалар өчен, Россия губерналарына җибәрелә. Соңыннан Бекир Әмекдар Кырым укытучыларының югары дәрәҗәсе – «шәйхел-мөгаллим» исеменә лаек була [1, с.116; 2].*

1906 елда Г.Тукайның атаклы кырымтатар лексикографы, публицист һәм тәрҗемәче, Җаектагы «Әл-гасрел-җәдид» журналында үз мәкаләләрен бастырган **Осман Заатов** (1875-1920) белән дә дустанә мөнәсәбәттә булганлыгы мәгълүм [1, с.119].

Кырымтатар шагыйре, әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче **Әшрәф Шемьи-Заде** (1908-1978) мәгълүматына караганда, Г.Тукай 1909-1912 елларда танылган Кырым шәркыятьче-тюркологы, гарәп һәм фарсы телләре белгече **Исмәгыйль Леманов** (1871-1942) һәм яшь шагыйрь **Мемет Нузет** (1888-1934) белән дә очрашкан. М.Нузет 1910 елның 15 апрелендә шагыйрьнең «Шәрык» клубында укыган «Халык әдәбияты» дигән лекциясен тыңлаган [1, с.119].

1913 елда Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗемән» газетасында Г.Тукайның вафат булуы уңаеннан кайгынамә һәм аның иҗатына югары бәя биргән мәкалә басылып чыга. Шул ук саннан шагыйрьнең шигырьләрен дә укырга мөмкин. Г.Тукай иҗаты турындагы мәкаләнең авторы билгеле түгел, әмма без аны кырым татарларының танылган язучысы, публицист һәм мөхәррир **Асан Сабри Айвазов** (1878-1938) яки атаклы әдәбият галиме **Осман Акчокраклы** (1879-1938) язмадымы икән, дип уйлыйбыз. «Тәрҗемән» матәм көннәрендә редакциянең Г.Тукай фондына 100 сум акча салуы турында (бу заманда Россиядә бер тәҗрибәле эшченең хезмәт хакы – 20-25 сум) хәбәр һәм шул ук фонд өчен акча җыярга кирәклеге турында игълан да бастыра [3].

Талантлы кырымтатар шагыйре **Амди Гәрәйбай** (1901-1930) 1920 елда (бу вакытта ул әле 19 яшьлек егет!) «Тукайга» исемле шигырь яза. Әлеге әсәрдә ул бөек татар шагыйре турында: *«Төрек-татар дөньясына нур чәчкән Тукай»*, – ди [4, с.66-67].

---

*Исмәгыйль Хәсән углы Кәрим – филология фәннәре докторы, профессор, Кырым инженер-педагогик университетының кырымтатар телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен фәнни-тикшеренү үзәге директоры, Украина Язучылар берлеге әгъзасы.

Кырым АССРның беренче елларында да кырымтатар язучы-галимнәре Габдулла Тукайның шәхесе һәм иҗатына битараф булмый. Әйтик, тел галиме, филология фәннәре докторы, Кырым университеты профессоры **Бекир Чобан-заде** (1893-1937) дә 1922 елда «Тукайга» исемле шигырь иҗат итә [5]. Б.Чобан-заде бу әсәрендә татар шагыйрен пәйгамбәр белән чагыштыра. Тукайның да үзе исән вакытта кадере булмаган, ә вафатыннан соң халкы яратып, сагынып, кaберендә күз яше түккән. Бекир Чобан-заде: *«Тукайның теле – мәхәббәт булып балкучы алмаз йөрәк, күктән иңгән өмет һәм иман теле»*, – ди. Ул шагыйрь каберенә зиннәтле төрбә куярга кирәклеген һәм барлык төрки мәмләкәтләрдә дә алтыннан һәйкәл коелырга тиешлеген искәртә.

Шул ук елда «Енъи дюнья» исемле газетада танылган кырымтатар язучысы, публицист һәм галим **Абибулла Одабаш** (1891-1937) татар шагыйренә багышлап «Тукай һәм ачлык» дигән мәкалә бастыра. 1922 елда дөньяга таралган бу газета, хәзерге көндә иң сирәк чыганаклардан саналып, бары тик Кырым дәүләт архивында гына бердәнбер нөсхәдә саклана. Мәкалә Кырымдагы коточкыч ачлык вакытында, рәсми мәгълүмат буенча, йөз меңнән артык кеше (шуларның 75 меңе – кырым татары) һәлак булган елда язылган. Одабаш ике төрле – ашказаны һәм фикри ачлык була, ди. Ашказаны ачлыгы һәрвакытта да фикри, гыйльми һәм әхлакый ачлыкның нәтиҗәсе икәнен ассызыклый. Әгәр дә халыкның сәламәт акылы, камил әхлагы һәм ихтыяр көче юк икән, ул ашказанының да ачлыгына дучар. Тукай – үзенең таланты, тирән хис-тойгылары белән үз халкының гасырлардан килгән авыру-чирен яхшы белгән һәм җан авазы белән аңа игътибарны җәлеп иткән талантларның берсе. Ул, туган халкын гына түгел, ә аның телен бик яхшы аңлаган барлык төрки-татар дөньясын да кузгатып җибәргән. Мәкалә авторы Россиядә һәм бөтен төрки-татар дөньясында котырган ачлык даһи Тукайның хис-тойгыларын һәм җан ярасын аңларга янә бер этәргеч булырга тиеш, ди [6].

1927 ел башында Симферопольдәге кырымтатар театрының танылган режиссеры **Җәләл Меинов** (1881-1938) җитәкчелегендә Кырымтатар Язучылар берлеге оеша [7]. Берлектә даими оештырыла торган әдәби кичәләрнең берсен татар шагыйре Габдулла Тукайга багышларга уйлыйлар. Кырым язучысы **Үмер Ипчигә** (1897-1955) «Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге» дигән темага чыгыш әзерләү бурычы куела. Шагыйрь Амди Гәрәйбай «Тукай иҗатының асылы һәм гомумтөрки әдәбияттагы роле» дигән темага доклад язу эшенә алына. Ә талантлы яшьләр бөек әдипнең шигырьләрен күңелдән укырга тиеш була.

Шулай итеп, 1927 елның 24 апрелендә Симферополь шәһәренең тугызъеллык үрнәк татар мәктәбендә Габдулла Тукайга багышлап хәтер көне уза. «Енъи дюнья» газетасында бу турыда хәбәр бастырган автор залның мәшһүр шагыйрь иҗатын яратучылар белән тулы булганлыгы турында яза. Сәхнәгә рәссам И.Җамалетдинов тарафыннан иҗат ителгән «Тукай» портреты куелган. Кичәне Кырымтатар Язучылар берлеге исеменнән «Енъи дюнья» газетасының баш мөхәррире **Мәмүт Недим** (1893-1938) ачып җибәргән. Үмер Ипчи һәм Амди Гәрәйбайларның доклады өч сәгать дәвамында булып, хәбәрче, зал тутырып килгән халык шундый зур кызыксыну белән тыңлады ки, хәтта чыгышлар ике мәртәбә озаграк сузылса да армый утырырлар иде, дип яза. Аннан соң Амди Гәрәйбай тамашачыларга Г.Тукайның мәшһүр әкияте «Шүрәле»не укый, ә Җиһангиров «Тукай маршы»н башкара [8].

Үмер Ипчинең доклады «Илери» журналының 1927 елгы апрель санында басылып та чыга. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә белем алган татар халкының мәшһүр улы Габдулла Тукайның тормыш юлы белән бик яхшы таныш булган әдип менәниләр яза: *«Тукаев – шималь (казан) татарларының иң мәшһүр вә хөрмәтле шагыйрьләреннәндер. Аның әсәрләре үз заманнарында халык тарафыннан сөелеп укылдыгы кеби, бүген дә сөелмәктәдер. Идел буе татарлары Тукаевны хөрмәт белән тәкъдир иттеләр. Тукаев – хакыйкатьтә тәкъдиргә шаян (лаеклы) бер шагыйрьдер. Ул үзенең гомерен дини тәгассыб (фанатизм), муллаларның наданлыгы, хорафат вә мещанлык илә көрәшеп кичерде. Үз дәверендә нашир улынган газета вә журналларның җөмләсенә (барысына) диярлек язды. Аның шигырьләре халык тарафыннан сөелеп укылды. Ул үз шигырьләрендә үз халкын, үз дәверен яшәтте. Әгәр ул заманның схоластик мәдрәсәләре вә шагыйрьнең бу мәдрәсәләрдә тәхсил күргәне (укыганы) күзгә алыныр исә, аның ни дәрәҗә бөек бер шагыйрь улдыгы аңлашылыр. Тукаев үз дәверен үз әсәрләрендә җанландырды, дидек. Бу һич шөбһәсез тугрыдыр. Ул үз халкының авазын, татар хатыннарының хокуксызлыгын, муллаларның халыкны упкынга китергәннәрен, гомумият илә тәгассыб диниядән килгән зарарларын җырлады. Аларны тәнкыйть итте, мещаннарын сүкте. Татар дөньясын бөтен бу пычраклыклардан коткармак өчен тырышты вә көрәште. Ниһаять, үзенең бөтен бу эшләрдә ялгызлыгын, көчсезлеген игътираф итеп (танып): «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш: керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым», – диде»*. Ү.Ипчи, 1913 елда яшь шагыйрьнең вафаты уңаеннан, Төркиядәге «Төрек йорты» журналының да җәмәгать эшлеклесе **Меһмет Фуат Көпрүлү**нең (1890-1966) күләмле мәкаләсе белән махсус саны басылып чыкканлыгы турында искәртә. Г.Тукайның «Печән базары» сатирик поэмасына төпле анализ ясап, әсәрдә тасвирланган хәлләрне Акмәчеттәге (Симферополь) «Толчок базары» белән чагыштыра һәм бик күп уртак якларны ачыклый. Мәкаләдә шагыйрьнең урыс поэзиясе ядкәрләрен тәрҗемә итүе турында да әйтә [9].

1920 еллар азагы-1930 еллар әдәбиятына аерым тукталырга кирәк. Бу елларда СССРның барлык зыялылары, шул исәптән кырым татарлары да репрессиягә дучар ителә. 1928 елның 9 маенда Кырым АССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе **Вәли**

Ибраһимов атып үтерелә һәм аның даирәсендәгеләр, барлык мәртәбәле язучы һәм сәнгать эшлеклеләре репрессияләнә. Тукайны өйрәнгән, революциягә кадәр Казан, татар дөньясы белән элемтәдә торган зыялы әдип-галимнәрнең дә күбесе атыла яки төрмәләрдә һәлак була. Бу елларда иҗат талант җимеше буларак бәяләнми. Әмма, кырым татарлары өчен нинди генә авыр еллар булуга карамастан, Тукай Кырымда элеккечә мәшһүр шагыйрь булып кала. 1936 елда бөек шагыйрьнең иҗаты белән кырымтатар әдәбият белгече һәм фольклорчысы **Кәрим Җаманаклы** (1905-1965) кызыксына. «Тукъайнен сёйлешюв» («Тукай белән әңгәмә») исемле шигырендә ул Кырым халкының Тукайга мәхәббәтен нечкә сәнгати детальләр белән ачып бирә. «Тукай шигырьләре безгә очып килде һәм йорттан йортка күчеп, укучыларыбызның хистойгысын уятты һәм кешеләргә шатлык бирде», – дип яза [10]. Җаманаклы, Тукайга багышланган башка мәкаләсендә шагыйрь иҗатының актуальлегенә тукталып, аны яшь кырымтатар шагыйре, Тукайның замандашы һәм аның белән бер үк елда вафат булган **Хөсәен Шамил Тохтаргазы** (1881-1913) белән чагыштыра. Мәкаләдә Тохтаргазының «Туган тел» белән «Эш беткәч уйнарга ярый» дигән шигырьләрне тәрҗемә иткәне һәм үзе төзегән мәктәп дәреслекләренә дә кертүкәнлеге турында мәгълүмат бар [11].

1930 еллардагы кырымтатар яшьләренең вакытлы матбугаты «Яш къуввет»тә язучы **Рәим Тынчеров**ның (1908-1973) Г.Тукай вафатына 25 ел тулу уңаеннан язган мәкаләсе бар. Бу мәкаләдә дә татар шагыйренең халыкчанлыгына һәм иҗатына югары бәя бирелә [12].

Кырым АССРда Тукай иҗатыннан шигъри юллар иң соңгы мәртәбә 1942 елда күчерелә. «Азат Кырым» газетасының авторы Х.Ташчы, гасырлардан килгән милли традиция һәм гореф-гадәтләргә җиңел генә карый торган тәкәббер яшьләрне тәнкыйтьләп, Г.Тукайның шигыреннән өзек китерә [13].

Кырымда Габдулла Тукайның исеме һәрвакыт мәртәбәле булды. Татар әдибенең күп санлы кырымтатар шагыйрь һәм язучыларына йогынты ясаганы бәхәссез. Моңа кырымтатар телендә сугышка кадәр язылган әдәби һәм фәнни хезмәтләр дәлил. Алга таба бу теманы тагын да җентекләп өйрәнү бөек татар шагыйре һәм аның Кырым, кырым татарлары белән булган мөнәсәбәте турындагы карашыбызны тагын да киңәйтер, дип уйлыйм.

Мәкаләбезгә өстәмә итеп, Кырымның атаклы шагыйре, тарихчы Амди Гәрәйбайның «Тукъайгъа» исемле шигырен кырымтатар телендә тәкъдим итәбез.

Чыганаклар:

1. Шемьи-заде Э. Шаирнинъ эбедийлиги // Йылдыз. – 1986. – №2. – С.115-119.
2. Байбуртлы Я. Шейхульмуаллимин Бекир-эфенди Эмекдаров // Терджиман. – 1909. – 14 авг.; Шунда ук «Мерхум Бекир Халиль-эфенди».
3. Миллет огълу // Терджиман. – 1913. – 10 апр.
4. Гирайбай А. Тукъайгъа // Илери. – 1927. – №4 (12).
5. Чобан-заде Б. Тукъайгъа // Енъи дюнья. – 1922. – №28 (145). – 14 апр.
6. Одабаш Х. Шаир Тукъай ве ачлыкъ // Енъи дюнья. – 1922. – №28 (145). – 14 апр.
7. «Илери» идареси илян эте // Енъи дюнья. – 1927. – 24 март.
8. Хаберджи. Эдебий акъшам // Енъи дюнья. – 1927. – 28 апр.
9. Ипчи У. Абдулла Тукъаев // Илери. – 1927. – №4 (12). – С.67-72.
10. Джаманакълы К. Тукъайнен сёйлешюв // Йылдыз. – 2016. – №2. – С.75.
11. Бекирова З. Дертимиз, арзумызны джырлагъан, айткъан Тукъай // Янъы дюнья. – 2016. – №14 (1344). – 15 апр.
12. Тынчеров Р. Тукъай. Шаирнинъ вефатына 25 йыл толмасы мунасебетиле // Яш къуввет. – 1938. – 16 апр.
13. Ташчы Х. Къырым эснафлары хакъкъында // Азат Къырым. – 1942. – 25 сент.

ТУКЪАЙГЪА

Эй, тюрк-татар дюньясына шавле, нур сачкъан Тукъай,
Къара халкъкъа ана тильмен анъ ёлун ачкъан Тукъай,
Дертимизни, арзумызны джырлагъан, айткъан, Тукъай,
Бек вакъытсыз, гульдай солып, аслына къайткъан Тукъай!

Тукъай, сенинъ къыйметинъни савлыгъынъда бильмедик,
Сен биз ичюн джан талаштынъ, джырладынъ да, сайрадынъ,
Талий сени хорлагъанда, козьяшынъны сильмедик!
Тек башынъа, озь башынъа такъдирге тиш къайрадынъ.

Ничюн, Тукъай, арамызда танъ аткъанджек къалмадынъ?
Ничюн, Тукъай, къалып кене ёлбашчымыз болмадынъ?
Бугунь матем тутамыз биз ишиталмай сёзюнъи,
Ёкълугъынъы пек туямыз, хатырлаймыз озюнъи.

Устадымыз, Чолпанымыз, сен башымызсынъ, Тукъай,
Джол косьтердинъ джашлыкъкъа сен о огъурсыз куньлерде.
Бир чыракъдай корьдик сени биз къаранлыкъ туньлерде,
Бугунь кене оджамызсынъ, ёлдашымызсынъ, Тукъай.

Дертли Тукъай, мунълы Тукъай, омрю къыскъа джаш Тукъай,
Халкъчы эдип, шаирлернинъ ордусына баш Тукъай.
Сенсинъ, Тукъай, къальбимизде халкъ сюйгюси яраткъан,
Сенсинъ, Тукъай, бугунь бизни къара халкъкъа къараткъан.

Инан, Тукъай! Бугунь бу халкъ кучин алды къолына,
Талий чыкъуп токътаталмаз энди сенинъ джолынъы.
Бакъыргъанынъ, чакъыргъанынъ сенинъ нафле кетмеди,
Ах, не языкъ коралмадынъ омринъ вефа этмеди.

Хурьмет сагъа тюрк-татарнынъ сайып-сюйген Тукъайы!
Хакъикъаткъа, Хакъкъа бола джануп-кюйген Тукъайы!
Тарихимиз байрам этсин, козьайдынлар ясасын,
Сендай шаир етиштирди, Тукъайымыз яшасын! [4]

Амди Гирайбай
1920 апрель 13, Акъмесджит. (Симферополь) ■

«МУСУЛЬМАНСКАЯ ГАЗЕТА»ДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ВАФАТЫНА НИСБӘТЛЕ ЯЗМАЛАР

XX йөз башында татар милли әдәбиятының Икенче Яңарыш хәрәкәтен башлап җибәргән классик шагыйрь Габдулла Тукайның вакытсыз үлеме, Ислам дөньясын гына түгел, бөтен Россия империясен тетрәндереп җибәргәндәй була. Татар милли матбугатында гына түгел, рус, төрек, азәрбайҗан һәм башка вакытлы матбугат битләрендә дә бөек шагыйрьнең үлеменә нисбәтле бихисап тәгъзия, кайгынамә басыла, бер-бер артлы шигырьләр дөнья күрә, замандашларының истәлек-хатирәләре киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә. Ни кызганыч, XX йөз башында Россиядә һәм чит илләрдә чыккан милли матбугат битләрендәге татар шагыйренә бәйле материаллар әле һаман да барланып, өйрәнелеп бетмәгән.

Г.Тукайны соңгы юлга озату

1913-1914 елларда дөнья күргән рус телендәге газеталарда, аерым алганда, «Мусульманская газета»да Тукай үлеменә мөнәсәбәтле язмалар еш очрый. 1912-1914 елларда Санкт-Петербург шәһәрендә нәшер ителгән «Мусульманская газета», шагыйрь үлеменнән соң, Сәед Габиев, Гани Абызов, Гайси, Вәккас, М.Куртиев һ.б. авторларның Тукай шәхесенә һәм иҗатына багышланган язмаларын бастыра. Газетаның 1913 елгы апрель ае саннарында Казан редакцияләренә юлланган кайгы уртаклашулар, шагыйрьнең ятимлектә, үксезлектә үткән балачагы, начар шартларда мәдрәсәдә, соңрак кунакханә номерларында узган еллары турында язмалар нәшер ителә. Россия мөселманнарының якты киләчәге якынаюын сиздергән әсәрләре Идел буе, башкорт җирләрендә, Кырым, Кай далаларында, Төркестанда яратып укылган Тукайның вакытсыз үлеменең яңа татар әдәбияты өчен генә түгел, бөтен ил мөселманнары өчен дә зур югалту булуы турында еш искә алына. Шагыйрь-

не зурлап, аңа багышланган русча шигырьләр бер-бер артлы дөнья күрә. Газета Г.Ибраһимов, Г.Исхакый кебек классик әдипләрнең дә Тукайга булган мөнәсәбәтен чагылдырудан читтә калмый, аларның фикерләренә М.Куртиевнең карашы чагылган язма да басыла. Мәкаләләрдә татар шагыйре иҗатының халыкчанлыгына зур игътибар бирелә.

1914 елда, шагыйрь үлеменә бер ел тулу уңае белән, газетада Тукай иҗатын фәнни дәрәҗәдә өйрәнү зарурлыгы турындагы фикерләр яңгырый башлый. Вакытлы матбугатта моңарчы басылып килгән әдипнең тормышына һәм иҗатына гомум күзәтүләр рәвешендәге язмалар белән генә чикләнмичә, әсәрләренең патриотик, халыкчан сыйфатларын яктырткан, яңа милли татар әдәбиятына нигез салынуда әһәмиятле булган иҗади үзенчәлекләрен ачу өстендә эшләү кирәклегенә дә басым ясала.

Биредә тәкъдим ителгән шигырь һәм язмалар Россия милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлегеннән алынды. Җөмлә төзелешендә стилистик хаталар булса да, шул чор рухы тулаем саклансын, дигән нияттән чыгып, текстлар газетада басылганча (ягъни русча) бирелә.

ПАМЯТИ ПОЭТА А.ТУКАЕВА[1]

Замолкли безвременно вещие струны
Саза Бояна Волги-реки;
Стихли поэта тяжкие стоны,
Уснули навеки песни тоски.

Да, чуяло сердце ашуга родного,
Что рано замолкнет лира его;
Чуяло бедное... Не воскресишь былого.
Не видеть нам боль его.

С.-Петербург, 24 апреля 1913 г.

***

2 апреля вечером, после продолжительной болезни, в Казани скончался поэт А.Тукаев.

Эта печальная весть не могла не поразить нас подобно грому. Как нежданные заморозки в весенние дни, как град, бич хлебов летней порой, так унесла безжалостная смерть в безвременную могилу молодого певца нашего А.Тукаева. Стоит ли говорить о том, какую незаменимую утрату понесла, в лице покойного, как мусульманская интеллигенция России, так и нарождающаяся молодая татарская литература. Навряд ли найдется мусульманин, которого не охватила бы скорбь при этой печальной вести. Умер поэт; умерла молодая татарская муза А.Тукаева; замолк его рыдающий тихострунный саз. Что же, казалось бы, тут особенного. Смерть как смерть. Умрем и мы все. Но нет!

Эта – не простая смерть, это – безжалостный выхват из нашей сферы лучшего, чистейшего того, чьи душевные струны своими звуками будили в нас веру в себя, в свои силы.

Еще недавно покойный пугливо выходил на дорогу в сумерках; не было еще радостной зари пробуждения мусульман России, а лира его уже звучала. То замирая, то раздаваясь звучней, она разносилась по Башкирии, всему татарскому Поволжью,

[1] Мусульманская газета. – 1913. – 8 апреля.

залетая и в Крым, и в Кайские степи, и в Туркестан. Ее звукам внимали и уже в этом внимании чуялась близость светлых дней мусульманской России.

Уже один за другим появлялись барды народные, поющие радость и горе его, прошлое и настоящее.

Юная семейка татарской пишущей братии росла...

Вспомните, сколько умерло за последние пять-шесть лет и значение нынешней утраты встанет во весь рост. Утрата за утратой. Это тем более больно нам, мусульманам России, с нашим полным безлюдьем на общественной арене; это тем больнее для нас потому, что музы наших поэтов не успевают дозреть, дорасти, налиться формами. Сказать о том, что покойный ашуг держался какого-либо определенного направления – нельзя, ибо той дифференциации мыслей, которую можно назвать направлением у нас, мусульман России, еще нет.

Мы находимся еще как бы «накануне», мы выявляемся и проявляемся.

Но так или иначе, стоны покойного Бояна звали только к жизни, к простору культуры. Да и умер-то он, охваченный тоскою по этой новой жизни. Мрак, царящий над родным миром, так щемил бедную музу поэта, что лира его не выдержала и разбилась. Но звуки ее еще долго будут жить в сердцах идущих вслед поколений татарской массы. Невольно припоминаются тут слова девственника поэта Надсона:

«Не говорите мне – он умер; он живет.
Пусть жертвенник разбит, огонь еще пылает;
Пусть роза сорвана – она еще цветет;
Пусть арфа сломана – аккорд еще рыдает».

Мир праху твоему, безвременно погибший поэт. Пусть эти искренние слезинки искреннего поэта животворно оросят свежий холм твоей холодной могилы; пусть они скажут тебе, что ты еще живешь среди нас. Над твоей еще не заросшей могилой мы еще раз клянемся до конца дней своих служить народу, служить дорогим идеалам, передавая лучшие заветы и идущим во след поколениям.

Вечная память тебе.

***Саид Габиев*[2]**

КАЗАНЬ
В РЕДАКЦИЮ «КОЯШ»

Безвременная смерть Тукаева – тяжелая утрата небольшой семьи мусульманской интеллигенции; страница скорби прибавилась к истории молодой татарской литературы. Сочувствуем горю, скорбим.

«Мусульманская газета».

НА ИМЯ РЕДАКТОРА ГАЗЕТЫ «КОЯШ»

По случаю смерти поэта Тукаева, студентами-татарами послана следующая телеграмма: «Пораженные вестью о безвременной кончине одного из первых и лучших поэтов татарского мира А.Тукаева, с грустью вспоминаем пророческое его предчувствие: «И мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз? Син сынасың, мин сүнәмен. Аерылабыз, ахрысы» и говорим: «Да, порваны струны моңлы саза, но велика наша вера, что звуки его песен еще долго будут в сердцах грядущих поколений».

Группа студенток и студентов-татар

[2]Сәед Ибраһим улы Габиев (1882-1963) – лак язучысы, лак әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Лак һәм рус телләрендә язган.

УСНУЛИ ПЕСНИ [3]

Замолкли безвременно вещие струны
Саза Бояна – Волги реки;
Стихли поэта тяжкие стоны,
Уснули навеки песни тоски.

Саид Габиев

Умер поэт... Умер и унес в могилу свой самобытный талант и чарующую прелесть своих стихов. Нет больше поэта...

Ушел он в вечность с печальной песней в устах... Он ушел и нам придется, может быть, еще долго ждать другого Тукая, другого «татарского Пушкина», который смог бы петь так хорошо и так искренно про любовь, печаль, мученья, страданья и про мученье саза своего народа, как пел уснувший на веки поэт-народник.

Безвременно угас он, не успев излить в своих песнях даже сотую долю того, чем томилась душа его; что рвало и терзало его грудь на части.

С.-Петербургъ. Понедѣльникъ 8-го Апрѣля 1913 г. Цѣна 7 коп.

МУСУЛЬМАНСКАЯ ГАЗЕТА

№ 16-й

Письма и подписныя деньги адресуйте: С.-Петербургъ, Пушкинская улица, д. № 15, кв. 18. Редакція „Мусульманской газеты".

Еженедѣльная общественно-политическая и литературная газета.

Редакторъ принимаетъ: отъ 12 часовъ утра до 1 дня.
Контора открыта: отъ 12 до 1 часу.
По праздникамъ пріема нѣтъ.

Книгоиздательствомъ „ВОСТОКЪ" въ Москвѣ, Каретный рядъ, д. 14, кв. 12. ВЫПУЩЕНА НЕДАВНО КНИГА Ах. Цаликова: „Кавказъ и Поволжье". Цѣна 1 р. 50 коп.

Редакція проситъ присылать статьи и сообщенія, нисколько не стѣсняясь слогомъ и почеркомъ.

Редакція ищетъ агентовъ по продажѣ и распространенію газеты въ провинціи.

Памяти поэта А. Тукаева.

Замолкли безвременно вѣщія струны
Саза Баяна Волги рѣки;
Стихли поэта тяжкіе стоны,
Уснули на вѣки пѣсни тоски.

Да, чуяло сердце ашуга родного,
Что рано замолкнетъ лира его;
Чуяло бѣдное... Не воскресишь былого
Не видѣть намъ болѣ его.

С.-Петербургъ, 24 апрѣля 1913 г.

На имя редактора газеты «Кояшъ»

КАЗАНЬ

Въ редакцію „КОЯШЪ"

Нѣсколько словъ о горской интеллигенціи

Въ гостяхъ у сосѣдей.

Дагестанецъ.

Горецъ Терской области.

***

Да, Тукаев был настоящий народник-поэт. Рожденный и выросший среди народа, испытавший с самого детства горе, печаль и невзгоды жизни, он искренно и грустно пел о них и его стихи, могучей волной вырываясь наружу, полные стона, носились по простору, печальными отзвуками отдаваясь в душе народных масс. И народ внимал им, понимал и воспринимал их. Да и нельзя было не понимать Тукая, ведь его стихи были стихами самого народа; они звучали в унисон с народными песнями; в них, как в зеркале отражались народные думы, мысли, переживания, почему они так глубоко затрагивали его душевные струны, что невольно он с жадностью внимал им, любил и заучивал их.

В них отражался своеобразный талант поэта. В них он сочетал с искренностью и теплотой своих личных душевных мотивов еще и не менее искреннюю гражданскую скорбь; свои душевные мелодии он слил воедино с мотивами практического служения народу.

***

Но, А.Тукаев умер... Он угас, не успев дать даже половины обещанного. Безжалостная смерть рано выхватила его из нашей среды. Лишь как метеор ярко сверкнул он на темном фоне серой и бедной татарской жизни. Затихли его песни. Но и за то, что он успел сделать за свою короткую жизнь; за те заслуги, которые он сказал родной литературе, мы его никогда не забудем и пока народ татарский будет жить; пока он не забудет своего родного языка, и не потеряет своего национального облика до тех пор, будет бессмертно и имя Тукаева и в истории татарской литературы он несомненно займет одно из первых мест.

Гани Абызов[4]

Ахыры киләсе санда

*Текстларны журнал өчен **Алия Мөбарәкшина** әзерләде.* ■

[3] Мусульманская газета. – 1913. – 25 мая.

[4] Гани Шаһвәли улы Абызов 1890 елда туа.1937 елның 14 декабрендә һәм 1948 елның 16 декабрендә (кабат) кулга алына. 1955 елның 10 октябрендә аклана.

Вахит Галиев (уңда) Суслонгерда вакытта хезмәттәше белән

БЕЗНЕҢ ЗАМАН КАҺАРМАНЫ

Рабит Батулла

СУСЛОНГЕР

Сугыш елы сабые һәйкәлен
Манар идем чиста алтынга.
Вахит Галиев

Яп-яшь, униҗиде яшьлек үсмер Вахит Галиев Суслонгер лагерена килеп эләгә. Мари урманнары уртасындагы хәрби лагерь була ул. Ачлык, ялангачлык, бүрәнә ташу, командный составның солдатлар белән рәхимсез кылануын, ачтан үлгән солдатларның әрдәнә-әрдәнә мәетләрен күрде ул. Тәртип юк. Кечкенә генә бер гаеп өчен дә кыйнап, гауптвахтага утырта сержант кисәге, алты ай эчендә 40 көн гауптвахтада утыртып чыгаралар Галиевне Суслонгерда.

Ашханәдә солдатларга еш кына аш җитми иде. Бер татар солдатына аш җитмәде, ул, буш кашыгын тотып, ач калды. Бер хохол үз алдына килгән ашны ашап утыра, аның кырында ач калган татар. Кәеф юк, ач татарның да күңеле төшенке. Хохол ач калган татарга:

– Эй ты, татарин, хорошо тебе голодать? – диде.

Татар егете бер сүз дә әйтмәде. Макарон белән сало кисәге китергәч, татар егете хохолның алдыннан «икенче» ашны тартып алды да:

– Син дә ачыгып кара әле, аннан аңларсың: татарга ачыгу әйбәтме, юкмы икәнен?! – дип, ашны ашый башлады.

Тотындылар сугышырга, хохол бушаган тәлинкәсе белән татарның маңгаена сылады, татар аңа каршы тимер чиләк күтәрде. Вахит аш бүлә торган озын саплы чуен чүмечне алды да... – хохолны яшен сукты. Ул бөгелеп төште. Нәкъ шулвакыт ишектән каравыл нәчәлниге килеп керде. Татар малае – бер якта, хохол икенче якта егылып ята. Галиевнең каешын, погоннарын салдырып алып киттеләр. Капитан хохолны да, татарны да Галиев кыйнаган, дип уйлады, ахрысы.

Берничә көннән аны тоткынлыктан азат иттеләр. Тикшерделәр. Карар чыгардылар: «Әгәр дә Галиев хохолның башына чүмеч белән сукмаган булса, татар егете хохолны тимер чиләк белән бәреп үтергән булыр иде, самооборона, предотвращение увечья, фәлән-фәсмәтән», – дип, Галиевне акладылар.

Сержант аеруча Вахитка каныга иде. Вахит балта белән агач юнып маташа иде, сержант Вахитны иңөсте белән этеп җибәрде, тегесе егылып китә язды. Акырып көлә-көлә, сержант Вахитны үрти башлады:

– Татарин-барин, жуёт маргарин!

Кара баганалы Комазан егете түзмәде, кулындагы балтасын сержант ягына томырды, сержант башын иеп калды, балта казарма коймасына барып кадалды. Агарынды сержант, күгәренде серажант, ләкин бер сүз дә әйтмәде. Әмма Вахит әйтте:

– Ыслушай, сержант! Икенчесендә мин бит не промахнусь! – диде.

Шуннан соң ул сержант кисәге татар егетләренә кагылмас булды.

Бер-ике көннән соң, Вахит Галиевне Суслонгердан башка хәрби частька, һава десанты мәктәбенә күчерделәр. Ул анда кече сержант дәрәҗәсендә взвод командиры ярдәмчесе булып хезмәт итте.

ӨЙЛӘНҮ

Сәер булыр микән, йөзне үтеп,
Туры килсә парлап йөрергә.

Вахит Галиев

Вахит Галиев бик каты авырып китеп, аны Мәскәүдәге хәрбиләр хастаханәсенә салалар. Озак кына ятканнан соң, өендә дәваланасын, дип, аны Комазанга кыска вакытлы ялга кайтарып җибәрәләр.

Өйгә кайтса, атасы Миңлевәли вафат булган. Анасы каты авыру, урын өстендә. Олы апасы кияүдә. Җыен бала-чага калган өйдә. Тәвәккәл Вахит тота да сөеклесе Наиләне шахтадан чакырта.

Уникенче сентябрь көнне Вахит белән Наиләнең никахы була. Никах була булуын да, яңадан хәрби частька китәргә туры килә Вахит-солдатка. Сембердә «Курсы усовершенствования офицерского состава Приволжского военного округа» бар иде. Шуннан сержант Галиевне штабка экспедитор итеп алалар.

Экспедитор сержант Галиевне бик тиз штабка чакырталар.

– Отвезешь вот этот секретный пакет в особый отдел, сержант Галиев! – диләр. – Вручишь лично в руки генералу Петрову! Понял, Галиев?

– Так точно, товарищ полковник! – ди Вахит.

Галиев, әмерне үтәп, генерал Петровның хәрби частен эзләп таба, дежурный старшинага әйтә:

– Миңа срочно генерал Петров кирәк! – ди.

– Генерал икенче катта, 202 нче бүлмә! – диде старшина.

Ишекне шакып, Галиев генерал бүлмәсенә уза.

– Сезнең нәрсә анда, сержант? – ди ул.

– Секретный пакет, товарищ генерал!

– Бирегез! – ди генерал.

– Товарищ генерал, Вы извините меня, – ди сержант. – Там написано: вручить в руки лично генералу Петрову. А я Вас лично не знаю, можно ли посмотреть на Ваше личное удостоверение?

Генерал ачу белән сержантка карый да, аты-юлы белән сүгенә:

– Твою мать, ты ещё смеешь требовать у меня документы, сержантишка! – дип кычкыра.

– Виноват, товарищ генерал! – дип, сержант Галиев, во-фронт басып һәм алып килгән секретный пакетны култык астына кыстырып, кисәк борылып, бүлмәдән чыгып китә.

Аның артыннан ук ишектә генерал күренә. Гафу үтенә. Генерал Петров үзенең кем икәнлеген раслаучы таныкнамәсен теләр-теләмәс кенә сержантка күрсәтә дә документны алганлыкка кул куя.

Вахит Галиевнең кәефе китә, матур килеп чыкмады бит инде бу вакыйга. Борчылмаслыкмыни, дорфалыгы өчен бу хезмәтеннән алсалар? Эше бик чиста, абруйлы, яхшы хезмәт бит. Йөрү – иркен, казарма саклап ятасы юк.

Эшләнгән эше турында исәп-хисап тотарга дип штабка килүгә, штаб начальнигы – полковник аны шаркылдап көлеп каршы ала. Баксаң, генерал Петров штаб начальнигына Вахит Галиев турында шылтыраткан икән.

– Син нәкъ уставча эшләгәнсең, сержант Галиев! Генерал Петров иртәгә личный состав алдында сиңа Мактау кәгазе тапшырырга кушты! – ди.

Озак та узмастан, әлеге генерал Петров Вахит Галиевне үз янына хезмәткә алдыра. Бу генерал белән полковникны Вахит Галиев гомере буе онытмый, ул аларның кырыслыгын да, аңа эшләгән игелекләрен дә исеннән чыгармый.

Күршедә генә элемтә училищесы була, генерал аңа:

– Галиев, элемтә училищесына укырга кер! – дип әйтә.

Вахитның керәсе килми, аны өендә йөкле хатыны, гаиләсе көтә. Бу теләге турында Вахит генералга да әйтә. Һичсүзсез, генерал Вахитка гаиләсе янына кайтып, күрешеп килергә рөхсәт итә.

Вахит-сержант Иске Комазанга кайтып керсә, өйдә ашарга бәрәңге юк. Халык ачыга. «Побывка»дан соң Вахит тагын үз частена китә. Аны общевойсковое училищега юллыйлар. Вахит училищедан офицер булып чыга.

– Һава десантлары мәктәбендә мин «әзвир» идем, – дип сөйли туксан яшьлек Вахит ага. – Йөгерү, парашут белән сикерү, пычак-корал белән «дошманны юк итү» һәм бокс буенча мин иң алда барам. Взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелдем.

Вахитның гаиләсе ишле бит инде. Кызы бар, хатыны икенче баласына тагын йөкле була, алар белән аеры-чөере яшәп булмый, Галиев гаиләсен хәрби частька алдыра.

Җиде офицерны Мәскәүгә, Главполитуправлениегә чакырталар. Исәпләре «Совершенно секретно» хәрби частьларда хезмәт итәргә офицерлар әзерләү икән: авыр хезмәт. Берсенең дә бу хезмәткә барасы килми. Поездда барганда ачыктан-ачык сөйләшәләр болар:

– Минекеләр фашистлар оккупациясендә булган, дип әйтсәм, мине «Совершенно секретно»га алмаслар, – ди берсе.

Икенчесе:

– Минекеләр пленда булган, дим...

– Минем гаиләмдә ике кешенең судимосты бар, дип әйтәм, – ди өченчесе.

Вахит ни әйтсен? Аның гаиләсендә пленни дә, оккупациядәгеләр дә юк, хатыны, ике баласы бар, үзе, читтән торып, университетта укый...

Җиде кешенең алтысы «Совершенно секретно» хезмәтенә яраксыз, дип табыла, бер Вахит Галиев соңгы өстәлгә кадәр барып җитә ала, комиссиядән ул берүзе уза. Шулай итеп, Вахит Галиевне «Совершенно секретно» дигән частька, Корея сугышына җибәрергә карар кылалар.

– Җыеныгыз! – ди начальник. – Нинди теләкләрегез бар? – дип сорый.

– Гаиләмне ватаныма кайтарып куярга рөхсәт итегез? – ди Вахит Галиев.

Начальник, юлга акча биреп, билетлар алып, Галиевләр гаиләсен ватанына озатып кала.

Гыйнвар зәмһәрире. Кукмарада ат яллап, Тәкәнешкә кайтып җитәләр, анда төн кунып, Иске Комазанга кайтып егылалар. Шул көнне үк хәрби частьтан телеграмма: «Срочно явиться в распоряжение командования». Ике көн гаиләсе янында кунгач, чыгып китә яшь офицер Галиев, килеп җитә үз частена, генерал янына керә:

– Сезнең фәрманыгызга буйсынып, хәрби хезмәтен дәвам итәр өчен лейтенант Галиев килеп җитте! – ди.

Генерал әйтә:

– Лейтенант Галиев! Сезне Көнчыгышка «Совершенно секретно»га түгел, гаиләгезнең хәленә кереп, Көнбатышка – Польшага җибәрергә булдык, – ди.

Хикмәт нәрсәдә? Тыныч елларда ике балалыларны регуляр армиягә алмыйлар, алган очракта да аларга ташламалар бар икән.

Вахитны «Обшевойсковая автомобильная часть»ка сәяси хезмәткәр итеп куялар.

Ләкин Вахитны хәрби хезмәт канәгатьләндерми иде инде. Гаиләсе аеры-чөере, дигәндәй... Вахит: «Гаиләм ишле булу сәбәпле, мине комиссовать итегез», – дип рапорт артыннан рапорт язарга тотына.

– Чего добиваешься, лейтенант Галиев? – диләр моңа командованиедә.

– Ватаныма кайтырга телим, иптәш генерал! – ди лейтенант Галиев.

Алланың бирмеш көне, Мәскәүдән – Главкомнан: «Лейтенант Галиевне – запаска!» – дигән фәрман килә.

Ләкин әле аны гаиләсе белән Урта Азиягә, Сәмәрканд өлкә комитеты карамагына юллыйлар. Ул анда мәктәптә военрук, пионер лагере мөдире булып эшли. Аннан Вахитны гаиләсе белән җәһәннәм тишегенә, ниндидер «секретный объект» булган шахтага җибәрәләр. Балалары, хатыны белән анда күченгәч, Вахит аңлый: монда аның балаларына мәктәп тә, торыр шартлар да юк – барак кына. Гаиләсен төяп, Вахит ватанына – Иске Комазанга кайтып китәргә мәҗбүр була.

ӘБИ САМАВЫРЫ

Үзе әйткәнчә, Вахит «әби самавыры артына кайтып егыла». Кая барырга, кем булып эшкә урнашырга? Юксыллык чоры. «Илдә чыпчык үлмәс!» – дип, Вахит Галиев урман кисү, такта яру эшенә урнаша. Тора-бара аны өлкән оста итеп билгелиләр. Эшләре яхшы гына бара моның. Колхоз рәисе Зәйнул Шәйхулов килеп, моннан такта сорый.

– Үзеңәме? – ди Вахит.

– Колхозга! – дигән була Зәйнул. – Үзебезнең фермаларга такта кирәк, Вахит Вәлиеч!

Бирмәсә, бергә эшлисе бит, аннан соң Зәйнул райком җитәкчеләре белән бик яхшы мөнәсәбәттә. Яшәргә кирәк бит, бәлки, ярдәме тияр, дип, Вахит Галиев тота да колхоз рәисенә күп итеп такта җибәрә. Шулай да баш хисапчыга әйтеп куя:

– Председатель Шәйхулов бурычка алды ул такталарны! – ди Вахит аңа. – Теркәп куй!

Яхшы, калын нарат-чыршы идән такталарын төяргә трактор алып килгән Зәйнул шушы такталар өчен бер ярты аракы чыгара. Төйиләр такталарны, бер шешә аракының йөз грамын рәис үзе эчә, калганын такта төяүчеләр йотып бетерә.

Икенче көнне Вахит Галиевне райком бюросына чакыртып алалар. Райбашкарма комитеты рәисенә – бюро әгъзасына законны бозып такта сату турында жалу килгән икән. Ул шикаятьтә болай язылган, имеш: өлкән оста Галиев Вахит колхоз рәисе Зәйнул Шәйхуловка бер ярты аракыга бер трактор такта сатып җибәргән.

Бөтен кеше Вахит Галиевкә ябырыла, нинди генә гаепләү сүзләре әйтелми аңа.

– Урманны сатып эчәсең! Карак син! – дип кычкыралар.

Бер сүз дә әйтә алмый Вахит бичара. Райбашкарма комитеты рәисенә аңлатырга тырыша Вахит:

– Габделхак абый! Бер яртыга мин такта сатмадым! Без аны бурычка бирдек! Минем әби самавырыннан башка һич тә малым юк, дүрт балам өйдә ач утыра. Мин ул такталарны бурычка бирдем! Документы – бухгалтериядә. Гаиләм ишле, торыр урыным юк, хатынымның анасы – әби өендә торабыз! – ди.

Колхоз рәисе Зәйнулның бу гамәлен аңлап та, аңлатып та булмый иде. Ихтимал, ул Вахит Галиевне, үз урынына өмет итә, дип уйлагандыр да, Вахитны шулай итеп «яндырырга» маташкандыр, дип кенә аңлатып була бу хәлне. Зәйнулның андый хаинлекләре алда тагын кабатланачак әле.

– Райкомда минем өстән язган яла, нахак сүзләр өелеп тора, – дип сөйли Вахит абый. – Каты авырып, хастаханәдә ятам. Кемдер өскә язган. Имеш, мин алкашлыктан дәваланып ятам икән. Ә мин тәмәке тартмыйм, аракы эчмим.

Колхозда дүрт авыл. Шуларның иң олысында мин бригадир. Авылдан-авылга, басудан басуга эш барышын тикшереп йөрим. Эше күп, акчасы юк. Мин эшли башлаганда беренче җыелыш булды. Иң беренче булып, ферма мөдире – рәиснең куштаны торып басты, мине хурлый башлады. Имеш, мин бригадаларда сирәк булам, фәлән-фәсмәтән. Мин, сикереп тордым да, рәиснең чыраена туры карап:

– Зәйнул Шәйхулов, яныңда шушындый шпионнар, шушындый әләкчеләр булганда, яхшы эш майтарып буламыни? – дидем дә, чыктым да киттем.

Өйдә ятам, эчтә пошаман уты, берничә көннән сон өйгә килгән бу гафу үтенгәндәй итеп. Тагын эшләп киттем, атка атланып бөтен басуларны әйләнеп кайтам, эшлим.

Күрше авылның чабылган борчагы җәелеп ята, безнең борчак та җиргә сузып салынган, чери. Мин өй борынча йөрим, борчакны коткарырга кирәк, ату борчак җир дымыннан үрә башлаячак, чериячәк, әрәм булачак бит. Кешеләрне җыеп, басуга алып чыктым. Райком секретаре Шәүкәт Абдуллович машинасына утырып килгән, халык ду китереп борчак әйләндерә. Шаккатты секретарь.

– Ничә кеше җыйдың, Галиев? – ди.

– Йөз дә унбер кеше! Шәүкәт Абдулович, санап карагыз! – дим.

Елмая секретарь, аркамнан сөя. Эшләрем бара, ихлас эшлим, чөнки менә шуннан соң минем үземне председательлеккә кыса башладылар. Басуда очратып та, райкомга чакыртып та мине үгетли бу:

– Якедәге уңышны җыеп алырга ярдәм ит инде, зинһар! – ди. Йомшак сөйләшә, дуамал җитәкчеләр генә акыра бит ул.

Акыра икән, димәк, ул җитәкче үз эшен белми. Сүгенеп, акырып сөйләшә баш-

ласалар, мин чыгам да китәм яки аларга атап шигырь язам. Мине «шагыйрь» дип тә әйткәлиләр, андый мактауларга исем китми, әмма барыбер «шагыйрь» сүзен ишетүе рәхәт. Мине Такташ белән чагыштырган булалар. Әчтән генә көләм, кая инде ул даһи Такташка җитәргә! Бу кеше яки надан, Такташны белми, яки ул ялагай, ихлас түгел. Минем күңел булсын, дип, Такташ белән чагыштырган була. Шундыйларга мин әйттем: «Син мине Такташка тиңләп, даһины кимсетмә, – дим. – Шигырь, такмак язуым – дивана, дуамаллардан «способ защиты, самооборона ул, понял?» Мин туры кеше, ни уйласам, шуны әйтәм, туры әйтә алмаган чакларда шигырь язам шул дивана турында. Артык сүгенү, артык кырыс булу ул үз эшеңне белмәүдән килә. Кеше эшли инде ул нәчәлник акыргач, аның акыруын ишетмәс өчен генә эшли, сине хөрмәт итеп, куркып түгел, ямьсез тавышын ишетмәс өчен эшли. Җаны белән эшләми бит ул. Андый җитәкчеләр дусларыннан дошман ясый, ә нәчәлникнең максаты – дошманыннан дус ясау булырга тиеш. Присидәтелме син, командирмы, син психолог, дипломат булырга тиеш. Кирәк чакта кырыс та була бел. Җитәкчеләрнең бөтен хатасы да шунда: алар кычкырырга кирәк түгел чакта кычкыралар, кеше күңеленә яра салалар, кырыслык кирәк чакта исә артык төче юмалыйлар. Ә кеше күңелен аңларга бер генә мәктәптә дә, бер генә институтта да өйрәтмиләр. Ул ата-ана тәрбиясеннән, йоладан килә.

Шундый райком секретаре белән рәис Зәйнул икесе бер табактан ашый иде. Борис исемле иде ул авыл хуҗалыгы буенча секретарь, җирне белми, аның ысулы акыру-бакыру, җитмәсә, шушы дивана үзенең ярдәмчесе итеп Харис дигән тагын берәүне үз янына алды. Яхшылык эшлим, дип, ялгыша болар. Шигырь яздым мин болар турында, башкача юл юк, кеше сүзен тыңламыйлар:

Имеш, бездә – Мамадышта,
Кадрларга урын тар.
Мин ышанмыйм, күрмиләрме –
Борис белән Харис бар.

Министр дип атап була
Безнең «олы» Борисны.
Районны күтәрергә, дип,
Сайлап алды Харисны.

Хәл итәсе мәсьәлә күп,
Керәбез без Хариска.
Ул хәл итә: «Киңәш белән
Керегез, – ди, – Бориска!»

Бик күп белә, күрә, сөйли –
Һәм өйрәтә: «Көтегез, – ди, –
Өйрәнгәнен Харисның!»

Хариска да, Бориска да
Файдасы юк керүнең.
Кирәге юк вакытыңны
Әрәм итеп йөрүнең.

Аңладылар олылар да
Кемнең кайда кирәген.
Харис китте «үз урынына»...
Тик аптыраш: кая төртик
Борис – заман имгәген?!

Бу шигырьне бөтен кеше ятлап алып сөйли башлады, ду килде халык, шуннан соң тегеләрнең икесен дә очырдылар.

– Зәйнулла тун сорады, бирдем, – дип искә ала Вахит ага. – Тун тектерергә, дип, тагын илле тире сорап алды, бер тиен түләмәде. Тактасына да түләмәде, ә үзе кешегә нахак яла яга белә.

Райбашкарма комитеты рәисе Габделхак абый, Вахитның хәлен аңлап, өй төзергә утыз биш фесметр агач язып бирә. Армия сафларыннан кайткан «офицер запаса»га өй салырга урман кирәк, дип, тиешле урыннарда аңлаткан. Бер биш мең сум ссуда да бирегез, дигән. Ссуда алырга килсә, Вахитка әйтәләр:

– Ссуданы өеңне салгач кына бирәбез! – диләр.

Дәвамы бар ■

Фикердәшләр-максатташлар: Ислам Әхмәтҗанов һәм Тәүфыйк Сәгыйтов

ХАҖ СӘФӘРЕ

Ислам Әхмәтҗанов

Мөхтәрәм якташым Тәүфыйк Камәретдин улы Сәгыйтов белән бер-беребезне белгәннән бирле китап алмашып яшәдек һәм бүген дә үзебезнең күзгә чалынган акыллы-гыйбрәтле китапларны тәкъдим итешәбез. Очрашуларның берсендә ул Ризаэддин Фәхреддиннең «Ислам дине – нинди дин?» исемле китабын кулыма тоттырып, җитмешенче биттә язылганнарны ныгытып укы әле, дип өстәде. Беравыктан, берәр атнадан тагын сөйләшеп алырбыз, дип куйды. Укыйм: «Хаҗ гамәле – кешенең гомерендә бер генә мәртәбә фарыз кылынган булып, гамәлләрнең зурысыдыр». Зөлхиҗҗә аеның әүвәлге ун көненең күбрәгендә үтәлә. Бер мәртәбәдән арткан Хаҗ – нәфел, ягъни яхшы ният белән кылынган Хаҗ хисапланадыр.

Атна узганын, Тәүфыйк абзыйның шылтыратуын көтәм. Тагын сөйләшеп алырбыз, диде бит. Сүз нәрсә хакында барыр икән? Остазыбыз һәр мөселманга үтәү өчен фарыз булган гамәлгә җыенмыйдыр бит?! Элегрәк тә колак очы белән шушы изге ният белән йөргәнлеге хакында ишеткәләгәнем бар иде.

Шылтыратты Тәүфыйк абзый. Сүзне, һәрвакыттагыча, ерактан башлады. «Тормышта адәм баласының дини һәм дөньяви эшләрне бергә үреп барганлыгын беләбез, – аның беренче сүзләре шул булды. – Дин эшләре – дөнья эшләренә, дөнья эшләре

дин эшләренә һичкайчан тарлык кылмый. Дини эшләрен эшләп, дөньясын да матур алып барган кеше исламият каршында кадерле урын тотадыр».

Әйе, хаҗ – һәр мөселман өчен фарыз гамәл. Аны җиренә җиткереп башкару өчен олы әзерлек, түземлек кирәк. Хаҗ тамаша да, дөнья буйлап сәяхәт тә түгел, Хаҗ – Раббыбызга иман китерү, гөнаһларыбыз өчен ялвару... Тәүфыйк Камәретдин углы – мең рәхмәтләр аңа! – тиешле барча кәгазьләрне юнәтеп, тутырасын – тутырып, табиб белешмәләрен юллап, ай ярым дигәндә Согуд Гарәбстаны Короле кунагы дигән чакыру кәгазен кулыма тоттырды.

Гарәбстанның Җиддә шәһәрендә. 2010 ел

Берничә көннән олы сәфәргә кузгалдык. Җиддә аэропортында каршы алучылар арасында Ислам Конференциясе оешмасы каршындагы Татарстан вәкиллеге хезмәткәре Хәйдәр Мөхәммәтбакый углы Галиев тә булачагын әйткәннәр иде. Табыштык, ихлас күңелдән кочаклашып күрештек. Хәйдәр туган, Мәккә җиренә китереп, «Әл-Хәрәм» мәчетенә терәлеп үк торган без яшисе кунакханәгә урнашырга ярдәм итте.

Кәгъбәтуллаһны тәүге мәртәбә күргәннәрне, аның тирәли тәваф кылуларны, Сафа һәм Мәрва таулары арасын ураганнарны, Мина, Гарәфә тауларына аяк басуларны язарга каләмнең дәрманы да, сүзләр дә җитми.

Ахырда, Хаҗга йомгак ясау өчен, Король кунакларын үз Сараена чәй табынына чакырды. Шушы дәрәҗәле мәҗлестә һәм «түгәрәк өстәл»ләрдә журналистлар арасында фикер алышуларда катнашу бәхете Россиядән килгән барлык мөселманнар арасыннан Тәүфыйк ага белән миңа насыйп булды.

Тәүфыйк абзыйның Хаҗ сәфәре барышында иманга тартылу, милләттәшләребезне исламга якынайту, төрле алама гадәтләрдән арыну хакындагы сүз-фикерләрен күңелемә сеңдереп барырга тырыштым. «Бу дөньяда мәшәкатьсез кеше юктыр, – ди ул. – Хәлле кеше булган малын кайгырта, фәкыйрьнең исә үз борчуы бар. Раббыбызның җибәргән сынауларыннан куркып калырга кирәкмидер. Сынауларны Аллаһы Тәгалә калебебезне чистарту, җаннарыбызны якынайту өчен җибәрә».

Өстәп нәрсә әйтәсең ди моңа?!

«Татарстан» ДТРК рәисе Тәүфыйк Сәгыйтов (уңнан беренче), Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Габделхак Шәмсетдинов һәм Татарстан мәдәният министры Марсель Таишев. 1990 нчы еллар

ИСЛАМ ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ МАТБУГАТТА БАСЫЛГАН КАЙБЕР ФИКЕРЛӘРЕ

Ислам Әхмәтҗановның «ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры урынбасары, «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс»ның генераль директоры булып эшләгән чагы

***

«Иң әүвәл сүз булган. Сүз белән кешеләрне берләштерергә, киресенчә, сүз белән үк аларны бәрелештерергә дә мөмкин. Шул сәбәпледер дә, кайсыдыр акыл иясенең: мылтыклы кешедән түгел, каләмле кешедән курык, дигән сүзләре хәтергә нык уелган. Сүзне бит агуга да, даруга да манып әйтеп-язып була».

***

«Татар журналистикасында хатын-кызларның күплеге хезмәт хакы белән бәйле. Әгәр ир кеше гаиләсен тәэмин итә алмаса, кеше күзенә ул ничек күренсен?! Эш хакы арттырылмаса, киләчәктә журналистларның абруе да булмаячак. Болар барысы да журналист һөнәренә мөнәсәбәткә, һөнәрнең абруена, хезмәт хакына, гонорарларның күләменә бәйле».

***

«Матбугат чараларының тиражлары кими. Икенчедән, кайбер басмаларда гонорар системасы шактый аксый. Каләм ияләре үзләренең хезмәтләре өчен каләм хакы алырга тиеш. Ә безнең кайбер әдәби журналларыбызда, хәтта газеталарда да бу система шактый фәкыйрь дәрәҗәдә, дияр идем. Кадрлар мәсьәләсендә дә уйланырга җирлек бар, чөнки бүгенге көндә журналистика хатын-кызлар һөнәренә әйләнеп бара кебек. Тик ничек кенә булмасын, бу мәсьәләләрнең барысының да уңай якка хәл ителәчәгенә ышанам».

Фикердәшләр-дуслар: Татарстан мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов һәм «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин. 1992-1999 еллар. В.Александров фотосы

***

«Татар матбугатының киләчәге бар һәм булачак. Чөнки Көнбатыш Европада: Франциядә, Германиядә, Швейцариядә, Норвегиядә, иң беренче чиратта, милли матбугатка, хатын-кызлар матбугатына, балалар матбугатына ярдәм итәләр. Без милли матбугатны бетерсәк, фаҗига булыр иде. Татар матбугаты да яшәячәк һәм аның киләчәге матур булыр, дип өметләнәм».

***

«Гомеремнең 42 елы журналистикага багышланган. Шушы вакыт эчендә бик күпне күрергә туры килде. Совет елларында журналистларның әйткән һәрбер сүзне хуплап торуларын да, сүз ирегә килгәч, шушы иреклнең кайберәүләрнең бугазына сөяк булып кадалганын да яхшы хәтерлим. Сатлык журналистларны да күрергә туры килде».

«Гомеремнең илле елдан артык өлеше язу эше, татар матбугаты белән бәйле. Төрле елларда төрле газета-журналларда эшләгәч, байтак җитәкче-түрәләр белән аралашырга туры килде. Бүтән каләм ияләренә ничектер, мин Ислам Галиәхмәт улы Әхмәтҗанов мәгълүмат һәм матбугат министры, соңрак, «Идел-Пресс»ның генераль директоры булып эшләгән елларны сагынам. Ул үз эшенең бөтен нечкәлекләрен белә, әйткән сүзен үти, милләт проблемалары өчен җан ата иде. Берәр мөһим нәрсә кирәк булса, теләсә кайчан аның ишеген тибеп дигәндәй кереп була, борчыган мәсьәләләрне, уртага салып сөйләшеп, хәл итеп була иде. Аның хәзер дә безнең арабызда булуын тою рәхәт миңа».

Равил Фәйзуллин,
Татарстанның халык шагыйре

Ислам Әхмәтҗановның (алда сулдан беренче) «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире булып эшләгән вакыты

Аяз Гыйләҗев, Ислам Әхмәтҗанов, Әхәт Гаффар

Ислам Әхмәтҗанов һәм Илһам Шакиров

ИСЛАМ ӘХМӘТҖАНОВ ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

Ислам Галиәхмәт улы Әхмәтҗанов 1948 елның 15 апрелендә Буа районының Норлат авылында туа. 1972 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмалый. 1986 елда Ленинград югары партия мәктәбендә белем ала.

1978-1982 елларда – «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире.

1992-1999 елларда – Татарстанның мәгълүмат һәм матбугат министры.

2000-2009 елларда – «Идел-Пресс»-ның генераль директоры.

2009-2012 елларда – «ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры урынбасары, «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс»ның генераль директоры.

2009-2014 елларда – ТР Дәүләт Советы депутаты.Тарих фәннәре кандидаты. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1988).

Безнең мирас №4 апрель 2018

Фикердәшләр-якташлар: Буа театры директоры Раил Садриев, Ислам Әхмәтҗанов һәм Тәүфыйк Сәгыйтов. 2016 ел

«Ислам Әхмәтҗанов белән мин разведкага барыр идем. Аннан исән-сау кайтасымны беләм. Ислам – башта сине, аннары гына үзен кайгырта торган затлардан. Бик ышанычлы кеше».

Тәүфыйк Сәгыйтов,

«Татарстан» ДТРК рәисе

Буа театры юбилеенда очрашу. 2016 ел ■

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

ТУГАН ТЕЛЕН ДАНЛАУЧЫ ШАГЫЙРЬ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара.

Мәшһүр төрек шагыйре Фазыл Хөсни Дагларҗа 1914 елның 26 августында Төркиянең Истанбул шәһәрендә туа. Гомеренең унбиш елы хәрби хезмәттә үтә. 1950 елда ул Хезмәт министрлыгында эшли башлый. 1960 елда үзенең шәхси китап кибетен ача.

Беренче әсәре (повесть) 1927 елда дөнья күрә. 1933 елда «Истанбул» журналында басылган «Акрынайтылган тормыш» шигыре исә аңа киң танылу китерә.

«Төрек теле – яңгырый торган байрагым ул минем». Туган теленең үз тормышында тоткан урынын шулай билгели Шагыйрь. Әлеге тел остасы, үзенчәлекле шигырьләр авторы турында күренекле төрек язучысы Азиз Нәсин заманында болай дип язып калдырган: «Бездә көненә кимендә ун шигырь яза торган шагыйрь бар. Шул ун шигырьнең бишесен – шәп, өчесен – искиткеч һәм икесен менә дигән итеп язган ул шагыйрь – Фазыл Хөсни Дагларҗа».

Фазыл Хөсни Дагларҗа 2008 елның 15 октябрендә 94 яшендә Истанбул шәһәрендә вафат була.

Безнең мирас №4 апрель 2018

Фазыл Хөсни Дагларҗа шигырьләре

СОЛДАТ АНАСЫ

Бирделәр егеткә солдат киеме –
Чыдамлы – мәңге тузмаслык.
Бирделәр күн букча – патроннар өчен,
Чыдамлы – мәңге тузмаслык.
Бирделәр өр-яңа мылтык –
Карга канатыдай ялтырый корыч.
Мәңге тузмаслык каска бирделәр...

Гади солдатның кирәк-ярагы
Мең елга чыдарлык.

Әмма иң тәүге алышта,
Иң тәүге залптан –
Үлде ул.

Нинди чыдам булырга тиеш
Ана йөрәге?!

КАРАШ

Баш очында төпсез күк.
Без галәмдә дүртәүбез –
Якты, сөю, үлем, мин.

Агып төште төн пәрдәсе.
Галәмдә калдык өчәү –
Сөю, үлем, мин.

Караңгы йөрәккә укмашты сагыш.
Хәзер галәмдә икәү генә без –
үлем, мин.

ЫШАНЫЧСЫЗ

Гарип аяклары белән,
Куркып кына,
Атлый алга...
Ышанмый җиргә.

МӘЧЕЛӘР

Ишекләрне төнгә бикләгәндә,
Тол хатыннар ишетә хәтта
Ялгыз мәченең
Баскычтан сак кына менүен.

КАТЫП КАЛГАН КАРАҢГЫЛЫК

Төн –
Димәк, очалмыйлар кошлар.
Кошлар оча алмый –
Димәк, төн.

СӨЯ БЕЛГӘННӘР БЕЛӘН

Әгәр
Күкне яратсаң –
Кояш
Туа.

САГЫШ АВАЗЫ

Яки кил
Үзең,
Яки җибәр
Үлем.

ЕРАКЛЫК

Син шундый ерак миннән!
Безнең араны
Үтә алмас хәтта
Аллаһ та.

***Л.Лерон** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



Ангара елгасы. Понтон күпере. 1909 ел

ТОМСК ШӘҺӘРЕННӘН ЮЛГА ЧЫГУ

Томск шәһәрендә өч атналап кунак булганнан соң, дуслар белән саубуллашып, юлга чыгарга карар кылдым. Шул ук көнне дустым Закир әфәнде дә Омскига китәр өчен юлга чыгачак иде. Тайга станциясенә кадәр юлыбыз бергә булганга, бер үк вакытта вокзалга килдек. Биредә безне озатырга килгән дусларыбыз күтә иде. Станциянең буфетына кереп утырып, бераз ял иттек. Ул арада икенче кыңгырау шалтырады һәм без, саубуллашып, вагонга кереп киттек. Безнең купеда бер хатын-кыз да бар икән. Поезд кузгалып китте.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

– И, туганкаем, – диде Закир әфәнде. – Алдагы сәфәрең ерак. Бәхил булышыйк. Бу вагонда да вакытыбыз аз калып бара. Соңгы сөйләшү. Тагын күрешү әллә насыйп була, әллә...

Без Закир әфәнде белән көлешә-көлешә шулай сөйләшкәндә, яныбызда утырган ханым Закир әфәндегә карап болай диде:

– Сезнең телегездә рус сүзләре бик күп, ахрысы. Әле сез сөйләшкәндә игътибар иттем: ике-өч сүзнең берсе, һичшиксез, рус сүзе икәнлеген хис иттем. Моның сәбәбе нәрсә соң? Сезнең телегез бик фәкыйрь булып ихтыяҗ бармы яисә кәеф өченме бу?

– Руслашабыз, – диде, көлүен дәвам итеп, Закир әфәнде. – Югыйсә, бернинди ихтыяҗ да юк.

– Болай булса, – диде ханым, – сезнең киләчәгегез бик үк әйбәт түгел. Бу хәл дәвам итсә, бер көн килеп, сез телегезне югалтачаксыз.

– Ул заманнар үтте, – диде Закир әфәнде. – Моннан 20-30 еллап элек андый көн килү ихтималы, чыннан да, булган. Ләкин ул вакытларда безнең хуҗалар да йокыга талган булганнар. Без алардан иртә уянып, алардан алда юлга чыктык.

– Мондый, карап торышка вак, әһәмиятсез нәрсәләр тора-бара әһәмиятлегә әйләнеп китә, – диде ханым. – Сез, биш-ун русча сүзнең булуында бер зыян да юк, дип уйларсыз, ләкин, бу елгы биш сүз биш елдан соң унбиш сүзгә әйләнер. Менә сез ничә елда бу кадәр рус сүзенең сиздермичә генә телегезгә кереп урнашуын төгәл генә әйтә аласызмы? Сез мине гафу итегез, сезнең белән таныш булмасам да, үземне тотып кала алмадым, сүзгә керештем. Бу – хатын-кыз әдәбенә килешә торган хәл түгел, кабат гафу итүегезне үтенәм.

– Мин, киресенчә, бик шатмын, – диде Закир әфәнде. – Безне гаҗәпкә калдырдыгыз хәтта, Сез кем?

– Йөрәгемдә сезгә карата бер хис бар. Миндә дә татар каны ага. Атам да, анам да Минусия татарлары[1], тик христианлашканнар яки христианлаштырылганнар һәм без христиан җирлегендә дөньяга килгәнбез. Йөрәгемнең бик тирәннәрендә һәрвакыт сызлану тоям. Кан кардәшләремне күрдемме, бу сызлану көчәя һәм мин онытылып китәм. Бераз гына алар белән сөйләшә алсам, җаным шуннан да юаныч таба. Шул сәбәпле, хатын-кыз әдәбенә каршы килеп булса да, сезгә сүз каттым, – дигәч, ханым, миңа ишарәләп: – Бу кешене күргәч, йөрәгемдәге яра кабат ачылгандай булды. Сез русча белмисезме? Мин исә – туган телен оныткан, үз ризалыгыннан башка динен дә югалткан татар кызы... – дип, кулъяулыгы белән күз яшьләрен сөртә башлады.

Закир әфәнде, миңа борылып:

– Бераз юатыгыз инде үзен, – диде.

– Кызым, Сезнең кая китеп барышыгыз? Кемнәрегез бар? – дип сорадым.

– Сухумигә барышым. Ирем шунда. Туберкулёз белән авырганга, дәваланыр өчен киткән иде. Телеграммасы килде, мине чакыра.

– Ата-анагыз исән-саулармы? Ирегез кайсы милләт кешесе? Ничә ел бергә яшисез?

– Атам да, анам да вафат булдылар. Ир туганнарым һәм кыз туганым бар. Ирем – рус кешесе. Өйләнешкәнебезгә биш ел. Монда апам яши, аның янына килгән идем.

– Безнең татар икәнлегебезне ничек белдегез?

– Белмәдем, тик йөрәгемдә нindидер бер хис туды, сезне күрүгә нидер булды. Минусиядә, әле ун яшьләремдә булганмындыр, Ирбә елгасы ярында аучыларны, балыкчыларны күргәндә, әллә ничек җаным җылынып киткәндәй була иде. Иң кече бала булгангамы, анам мине бик ярата иде. Миңа һәрвакыт үзенең

---

[1] Минусия татарлары – Бүген Минусинск шәһәре урнашкан җирләрдә яшәгән төрки халык. Атама Минуса елгасының исеме белән бәйле (тәрҗ. иск.)

татарлар арасында яшәгән елларын искә төшереп сөйли торган иде. Атамны бик кечкенә яшьтә руслар Петербургка алып киткәннәр, анда христианлаштырганнар. Шул рәвешле без дә христиан булып туганбыз. Тик атам калмык шаман динен күбрәк ихтирам итә иде. Ә мин исә, киресенчә, нигә икәнен белмим, мөселманлыкны күбрәк яратам. Югыйсә, үзем исламият хакында берни белмим.

– Кайда укып белем алдыгыз?

– Петербургта Мариинск институтын тәмамладым. Менә шул елларда, яшьлек инде, Петербург тәрбиясе мине рус егетенә кияүгә чыгарга этәрде. Менә шул. Хәзер инде менә ирем дә үлем алдында тора. Балабыз да булмады. Моннан соң инде үз акылым белән һәм үз акылыма хезмәт итәрмен.

– Ирегез кайларда эшләде?

– Тимер юл төзелешендә инженер иде. Ике ел була инде, туберкулёз белән авырый. Инде соңгы чиккә җиткәч, табиблар, һава үзгәртергә кирәк, дип, Сухумигә китәргә киңәш иттеләр. Өч ай шунда яши, – дип җавап бирде ханым.

– Кызым, бик нык гаҗәпкә салдыгыз. Нинди телләр беләсез? Нәрсәләр укып өйрәндегез? Татарларга карата булган хис-тойгыгызның, әлбәттә, бер сәбәбе бардыр, шулай бит? – дип, сораулар яудырдым.

– Мин русчадан башка бер тел дә белмим, – диде. – Себер татарлары хакында Ядринцев хезмәтен, Потанин һәм Фишер[2] хезмәтләрен укыдым. Керлиэльнең диннәр турындагы китабын берничә тапкыр укып чыктым. Татарларга карата хисемә килсәк, мин әле Петербургта укыганда, бер карт белән танышкан идем. Бик кешелекле карт иде ул, ара-тирә минем белән күрешергә килә, үгет-нәсыйхәтләр бирә иде. Ул үзе гади халык арасыннан чыккан кеше иде, шулай дип беләм, ләкин миңа бик матур нәсыйхәтләр бирә, хикәяләр сөйли иде. Ике-өч атнага бер тапкыр һичшиксез килә, кайчакларда бер тартма шоколад та алып килә торган иде. Мин аны атамны яраткан кебек яраттым. Ул картның йогынтысы да булгандыр, мөгаен. Тик ул гына да түгел, татарларны күрсәм, үземдә ниндидер бер хис тоям, бу инде кан тарту галәмәтедер, дип уйлыйм. Татарларның хәлләре, яшәешләре турында һәрвакыт уйланам. Русларның татарларны кимсетүләренә һич түзеп тора алмыйм. Ирем белән дә бу мәсьәләдә килешә алмый идек. Вакыт-вакыт берберебезгә каты бәрелгән, авыр сүзләр әйтешкән чакларыбыз да булды.

– Сез безгә дә үзегезне яраттырдыгыз, инде һич өмет итмәгән җирдә Сезнең кебек бер кардәшебезне очратуыбызга никадәр генә шөкер итсәк тә аз булыр. Мин Омск шәһәренә барам. Юлда тагын берничә тапкыр Сезнең белән очрашачагыма ышанам. Тайга станциясеннән соң Сез, ихтимал, хатын-кызлар вагонына утырырсыз. Шулай булса да, станцияләргә тукталганда күрешербез, дип уйлыйм. Тик атабыз *(Габдерәшит Ибраһимов турында әйтүе. –* **А.Р.***)* белән Тайга станциясендә аерылабыз, чөнки ул Ерак Көнчыгышка таба китә. Инде Тайгага килеп тә җитәбез икән. Бүген мин бик бәхетле. Сезгә булган хисемне белдерергә сүзем җитми, ләкин күңелемдә мәңгегә олы хөрмәт урнашканын әйтергә тиешмен. Сезгә бер үтенечем бар: рөхсәт итсәгез, кулыгызны үбәр идем, – дип, Закир әфәнде урыныннан торды. Мин дә торырга мәҗбүр булдым. Күп тә үтмәде, поезд Тайга станциясенә килеп туктады. Биредә бәхилләшеп саубуллаштык.

Инде минем эчемдә хисләр өермәсе, уйлар ташкыны. Әллә кайларда туган, әллә кайларда үскән бер кешенең йөрәгендә нинди тирән хисләр яши! Мон-

[2] Ядринцев Николай Михайлович (1842-1894) – журналист, этнограф, экономист, тарихчы. Аның «Сибирские инородцы их быт и современные положение» (1891) хезмәте күз алдында тотыла булса кирәк. Потанин Григорий Николаевич (1835-1920) – география һәм этнография белгече, фольклорчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Фишер Адам (1889-1943) – милләте буенча поляк, этнограф, Львов университеты профессоры (тәрҗ. иск.).

дый вакыйгаларны күргәч, дөньяны бар иткән Важибуль Вүҗутның (Җәнаб-ы хакның, Хак Тәгаләнең) осталыгы, мәгърифәте алдында шаккатуыңны танымыйча хәлең юк.

Мин Тайга станциясендә Мулланур Могаззи әфәнде җәнапларының өенә киттем. Поездым килгәнгә кадәр, берике сәгать вакытымны анда үткәрдем, газеталар укыдым.

Бу җирләрдән берничә шәһәр һәм авыл карап, Иркутск шәһәренә юл тотачакмын, бу – 1502 чакрым ара. Ноябрьнең 9ы, Тайга станциясеннән кузгалып китеп, биш сәгатьтән соң, Боготол станциясендә поездан төштем һәм Шулдат авылына килдем.

Шулдат – 100ләп хуҗалыктан торган зур булмаган бер авыл, кешеләренең һәммәсе дә мөселман. Болар – кайчандыр Русиянең эчке төбәкләреннән – Казаннан, Нижний Новгородтан һәм башка җирләрдән сөргенгә сөрелгән һәм шушында яшәп калган халык.

Бередә халыкның бары тик үз дини тырышлыгы белән ачылган бер башлангыч мәктәпләре, бер мәчетләре бар. Әлбәттә, мөселман авылында бер мәктәп, бер мәчет булу – искә алып торырлык нәрсә түгел түгелен. Әмма закон бозып җәза алган кешеләрнең гаиләләреннән генә оешкан бу авыл – Себернең җәһәннәм тишегендә. Мәктәпнең бөтен чыгымнарын да үзләре генә күтәрәләр. Шул рәвешле, 50-60лап бала аталары кәсебеннән бөтенләй башка бер юл белән китәргә әзерләнә. Башлангыч белем бирүнең иң әһәмиятле өлеше булган уку-язу биредә дин нигезләрен өйрәтү белән бергә алып барыла. Бу яктан караганда, әлеге авылның хәле мактауга һәм хуплауга лаек булуында шигем юк.

Мәктәпләренә бардым, укучыларның белемен тикшереп карадым, мәчетләрендә һәр бишвакыт намазда вәгазь сөйләдем, нәсыйхәт бирдем. Ислам диненә булган мәхәббәтләрен аңлап, чын-чынлап канәгать калдым. Һәр көн халык белән күрешеп сөйләштем.

Беркөн бер кешедә кунакта идем, мәхәлләнең имамы Хәсән әфәнде йорт хуҗасы белән таныштырганда: «Бу кеше рус-япон сугышында катнашты, японнарга әсир төшкән иде, бер ел әсирлектә калды, японнарның дусты», – диде. Мин, танышуыма канәгать булып: «Сугыш вакытында кайларда булдыгыз? Кайда әсир төштегез?» – дип сорадым. «Мукденда идек, шуннан әсир төштем. Без Мукденнан 10000 кеше әсир киттек, шуның 750се мөселман кешесе иде. Әсир итеп алгач та, безне шунда ук туп-туры Япониягә җибәрделәр. Анда безнең армияне Авасаки шәһәренә билгеләделәр. Авасакигә килеп җиткәч, диннәребезгә күрә аерып, аерым казармаларга урнаштырдылар. Шул көннән соң, аш-суыбыз да, киемсалым да гел аерым бирелә иде.

Башта бездән: «Арагызда галимгуләмә бармы? Укый-яза белгән кешеләр бармы?» – дип сорадылар, боларны күрсәтүебезне үтенделәр.

Унбишләп укымышлы кешене аерып алганнан соң: «Аларның берсен – имам, икенчесен мәзин итеп сайлагыз, калганнары укытучы булачак. Динегез кушканча укыту, өйрәтү белән шөгыльләнәчәксез. Ашыйсы ашларыгызны да динегез кушканча әзерләү өчен биш кеше сайлагыз», – диделәр. Аларны да үзебез сайладык. Намаз кылу өчен бер урын күрсәттеләр. Мәктәп өчен дә аерым урын билгеләделәр. Китаплар бастыру өчен китап басу машинасы бирделәр һәм: «Бүгенге көннән алып, сез – безнең кунакларыбыз, тик көн дә биш сәгать уку-язу эшенә өйрәнәчәксез», – диделәр. Ризыгыбыз гаять яхшы, бик сыйлыйлар иде, бигрәк тә без – мөселманнарга хөрмәт зур иде. Бик күбебез надан киткән идек, уку-язу өйрәнеп кайттык. Мин Сезгә шуннан да артык мәгълүмат бирә алмаячакмын. Ләкин анда безнең бер укытучыбыз язган һәм шунда ук язу машинасы белән бастырылган кечкенә генә бер китапчыкны Сезгә биреп тора алам, тик монда ук укып, кире бирү шарты белән...».

Әйе, шулай дип, бу кеше миңа бер

китап бирде. Мин китапны алып карап чыктым. Бу, бик яхшы Порт-Артур тарихы иде, дисәм дә дөреслеккә туры килер. Бәлки әле тарих та түгел, Порт-Артурда торган, сугыш вакытында шунда көннәрен үткәргән бер кешенең «Көндәлек дәфтәре», дисәм дә урынлы булыр иде, тик китапчык рәвешендә бастырылган, 2000ләп әсиргә истәлек итеп таратыр өчен нәшер ителгән.

Бу дәфтәрне кулыма төшерүгә, шунда ук имам Хәсән әфәнденең өенә кайтып, 22 сәгать буе урынымнан да кузгалмыйча, аны укып чыктым. Бу дәфтәр тиздән аерым бер китапчык булып бастырып чыгарылачак. Шул сәбәпле, биредә дәфтәрдән өзекләр китерүгә хаҗәт юк дип саныйм.

14 нче ноябрь. Җомга намазын укыганнан соң, Шулдаттан Ачинск шәһәренә ат белән китәргә карар кылдым. Бу ике шәһәр арасы 60 чакрым. Шулдаттан кузгалып киткәндә, мине озатырга авылның олысыкечесе чыккан иде, авыл башында йөзгә якын кеше җыелган, кайсы елый, кайсы дога укый. Шул рәвешле 13 чакрым буе озата бардылар. Мине өендә кунак иткән Хәсән әфәнде, мәхәллә аксакалларының берсе – Фәхретдин әфәнде алтмыш чакрым ераклыктагы Ачинск шәһәренә кадәр озата барырга булдылар.

Без Шулдаттан 13 чакрым ераклыктагы Карабилник[3] авылында Шулдат кешеләре белән саубуллашып аерылыштык. Ярым сәгать вакыт үтүгә, бик көчле буран башланды, бераздан һава суытты, 35 градус салкын иде. Юл да тора-бара начарая, төн дә бик караңгы, ай да юк. Тагын 20 чакрымлап юл үткәч, бер рус авылы аша үттек. Фәхретдин карт: «Төнне биредә үткәрик», – диде. Әмин әфәнде: «Юк, китәбез», – дигәч, юлны дәвам иттек. Берни күренми иде. Буран шулкадәр көчәйде, хәтта бер-беребезне дә күрми идек. Әмин әфәнде атларны куа, арттарак калган Хәсән әфәнде белән Фәхретдин әфәнде кычкыра башладылар. Әмин атларны туктатты, көтә башладык. Килделәр. Фәхретдин карт: «Болай китсәк, ярты сәгатьтән юлны югалтачакбыз, артта калган авылны да таба алмаячакбыз, бала-чагабызны да ятим итәчәкбез. Ни булса да булыр, шул авылга кире кайтыйк», – диде.

Бераз бәхәсләшкәннән соң, авылга кире кайтырга булдык, ләкин хәзер инде юлны югалттык. Авылның кай тарафта икәнен дә белмибез. Юл да юк. Берни күренми дә. Әмин төрле якка йөгереп барып карады, ниһаять, менә бу якка барырга кирәк дип әйтеп, атларна шул якка таба куа башлады. Тик берни билгеле түгел, авылны таба алмыйбыз. Ике сәгать адашып йөргәннән соң, бер кеше очрады. Ул да нәкъ безнең кебек адашкан булып чыкты.

Әмин әфәнде бу кеше белән сөйләште: кич ул да авылда булуын, адашуын, инде авылны таба алмавын әйткән. Безнең Әмин тагын атларны әле уңга, әле сулга чаптыра. Ниһаять, авыл табылды, ләкин бу бары тик хайваннарның көче белән генә булды.

Инде бу авылда төнне үткәрер өчен бер рус өенә кердек. Кечкенә генә өй. Үзләре унбишләп кеше, без – дүртәү: булдымы 20 кеше. Берничә бозау, берничә дуңгыз баласы, ике песи, бер эт – барчасы 25 җан бер кечкенә бүлмә эчендә калдык. Әллә нинди кар бураны астында калу рәхәтрәк булыр иде дә бит. Тик менә Фәхретдин карт: «Балалар үксез кала яздылар, йә Ходаем», – дип, төне буе шөкерләр укыды. Өйнең эче сасы ис белән тулган. Минем дә һич кенә дә йоклар исәбем юк, таң атканчы, чарасыз, шунда вакыт үткәрергә мәҗбүр булдык.

Иртән иртүк без торып чыкканда һава ачылган иде. Бик ашыгыч рәвештә юлга чыктык. Җомга иртәсе сәгать 9да Ачинск шәһәренә килеп җиттек һәм дустыбыз Мөхәммәт Бакир әфәнденең йортына килдек.

---

[3] Бүгенге Красноярск өлкәсендәге Боготол районының Коробейниково авылы турында сүз бара (тәрҗ. иск.).

Безнең мирас №4 апрель 2018



Иркутск вокзалы

Ачинск кечкенә генә бер шәһәр икән. Мөселманнар нибарысы 40-50 йорт исәпләнә. Бер мәктәп һәм бер мәдрәсәләре бар. Искә алып әйтерлек башка берни дә юк. Тик шунысына да шөкер итәргә кирәк: Себердә йөз йортлык ничәмә-ничә рус авылыннан үттем, күбесендә ни мәктәпләре, ни чиркәүләре булсын. Мөселманнарның исә, 20-30 йортлык кечкенә генә авылында да һич булмаса бер мәктәп, бер укытучы бар. Күбесендә мәчет бар, ир укытучы да, хатын укытучы да бар. Менә шуңа күрә, искә алып үтәргә лаек, дип саныйм.

Мин Ачинскидан Красный Яр аша Иркутск шәһәренә юнәлдем. Арада – 1176 чакрым юл. Мондый озын юллардан көне-төне бару кешене бик ялыктыра. Себер тимер юлы бик төзек, вагоннары да яңа система буенча төзелгән, шулай булуга да карамастан, төрмәдә утырган кеше кебек кечкенә бүлмә эчендә вакыт үткәрү ансат түгел, бигрәк тә «куян»нар да күп булса, әле тагын ул «куян»нар арасында сәрхушләр дә булса, Алла сакласын, адәм баласына һәртөрле куркыныч янавы мөмкин: йокы да күрмәячәк, станцияләрдә ашарга да барып килә алмаячак. Себер тимер юлында поездлар эчпошыргыч дәрәҗәдә акрын йөриләр, бер сәгатьтә егерме чакрым юл үтәләр: бик кыен.

20 нче ноябрь. Иртән иртүк Иркутск шәһәренә килеп җиттем. Күптәнге дустым Шәйхулла әфәнде һәм башка кайбер дуслар, укытучылар станциядә каршы алдылар. Күрешеп, бераз сөйләшеп торганнан соң, Ангара елгасы аркылы салынган күпердән чыгып, Шәйхулла әфәнденең өенә юнәлдек. Һава шулкадәр салкын: соңгы вакытларда бу кадәр салкынны күргәнем булмады. Ләкин Ангара елгасы әле дә боз белән капланмаган иде. 35 градус суык булып та, елга өстенә боз катмаган булса, әлбәттә, аптырарсың. Безнең Көнбатыш Себердә, 12-14 градус суык булуга, елга өстеннән юл салына, атлар белән үтеп йөрерлек була.

Шәйхулла әфәнде: «Бу әле чын салкыннар түгел», – ди, мин исә, шулкадәр нык суык булуга гаҗәпләнүемдә дәвам итәм. Иркутск халкы өчен 30 градус суыклык берни түгел икән.

Ул көнне кичкә кадәр Шәйхулла әфәнденең өендә кунак булдым. Кич җиткәч, Шәйхулла әфәнде миңа Диков кунакханәсендә номер әзерләткән икән, шунда киттем. Бик күп җирләрдән хатлар килгән иде. Аларны карап чыкканнан соң, тиешлеләренә җавап та яздым.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

Тукай белән Дусай арасы

Мөҗәһит Әхмәтҗанов

Артта басып торалар: Зәйтүнә, Кадыйр (язучы Атилла Расихның әтисе һәм әнисе); утырганнар: уңнан – Галия апаның әтисе Мөгънетдин һәм әнисе Рәбига (балаларның берсе – Галия). Уртада – Галия апаның әбисе. 1915-1916 нчы еллардагы фото Мөслим районының Яңа Карамалы авылындагы Хавис абыйның апасы Нәкыя апада сакланган.

Мөслим районының Дусай авылында яшәүче Хавис абыйның әнисе Галия апа – Тукай мәхәббәте Зәйтүнәнең туганнан-туган сеңлесе. Зәйтүнәнең улы – язучы һәм галим Атилла Расих, туганнарын эзләп, 1960 нчы елларда энекәше Хавис абый янына килеп чыга. Алар шактый еллар үзара тыгыз элемтәдә тора.

Галия апа

Ахунҗан абый

Атилланы искә төшердемме,
Якынаям кебек Тукайга.
Кайберәүләр гаҗәпләнәдер дә –
Ничек бәйле соң ул Дусайга?

Атилла бит – Зәйтүнәнең улы,
Энекәше Хавис – Дусайда.
Дусай урамнарын таптаган ул,
Кунак булып кына булса да...

...Көтмәгәндә Тукай китеп барган,
Ә Зәйтүнә калган ялгызы;
Төне буе хәсрәт чигеп чыккан,
Күзләреннән яшен агызып.

Атиллабыз, нәрсә дисәң дә бит,
Тукай мәхәббәте баласы.
Шулай булгач, бик тә якын инде
Тукай белән Дусай арасы.

Тукай-Зәйтүнә, Галия һәм Хавис

(Хавис абый Ахунов[1] белән әңгәмә)

– Хавис абый, синең әниең Галия апа белән Габдулла Тукайның беренче мәхәббәте Зәйтүнә бертуган икән, дип сөйлиләр. Дөреслеккә туры киләме бу?

– Зәйтүнә белән минем әнкәй – бертуган түгел, туганнан-туган балалар. Әнкәйнең әтисен – Чистай мулласын «кулак» дип игълан иткәннән соң, ул, үз теләге беләнме, әллә башка сәбәп беләнме, гаиләсе белән Мөслим районының Үрнәк авылына килеп урнаша. Әткәй әнкәй белән ничек танышкандыр, анысын хәтерләмим. Өйләнешкәндә әткәйгә – 26, әнкәйгә 16 яшь була. Әткәй аны – мулла кызы Галияне Үрнәк авылыннан урлап, шушы Дусай авылына алып кайта.

– Сез Зәйтүнәнең улы, күренекле татар язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Атилла Расих белән беренче мәртәбә кайчан һәм кайда таныштыгыз?

– Минем әткәй (Ахунҗан) Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмады. Без – дүрт бала ятимлек ачысын тоеп үстек. Әнкәйнең бертуганы Суфия апа гаиләсе Кыргыз-

[1] Әхмәтхавис Ахунҗан улы Ахунҗанов 1936 елда Мөслим районының Дусай авылында туган. Әтисе – авылның хәлле кешесе Ахунҗан. Әнисе – Чистай мулласы Мөгънетдин кызы Галия. Алар биш бала үстерә: Нәкыя, Кәшиф, Хавис, Хавил, Хөррия. Галия апа улы Хавис һәм килене Вәсилә тәрбиясендә яшәде. Хавис абый колхозда төрле эшләр башкарды. Колхоз умарталыгында эшләгән елларында районда гына түгел, республика күләмендә алдынгы умартачы була. Ул 2017 елның февралендә бакыйлыкка күчте. Апасы Нәкыя Мөслим районының Яңа Карамалы авылында яши. *(Мөҗ.Әхмәтҗанов иск.)*

Безнең мирас №4 апрель 2018

Ахунҗан абый улы Әхмәтхавис белән

Хавис белән Вәсилә

станда – Фрунзе шәһәре янында яши иде. Алар мине 1953 елда, ятим бала буларак, уллыкка да алырга теләгән. Кулыма паспорт эләккәч, абый янына Үзбәкстанга шахтага акча эшләргә киттем. Атилла абый белән танышлык шул Суфия апа аркылы башланды. 1960 елда Казан янында умартачылык һөнәренә укып ятканда, Атилла абыйларга бардым. Аларда кунак булып, Казан шәһәре белән танышып та йөрдем әле.

– Атилла Расих Дусайда ничә мәртәбә булды?

– Безнең «Урал» колхозы белән ул вакытта Мирза Гаттаров җитәкчелек итә иде. Атилла абый, терлекчелек буенча өлкә комитеты вәкиле буларак, Мөслим якларына беренче мәртәбә 1959 елда килеп чыккан. Ул чакта Атилла абый Казан ветеринария институтында да укыта иде. Мин эшләгән умартачылыкта да булды әле ул. Икенче тапкыр килүе 1963 нче елларда булса кирәк. Ул үзенең нәсел шәҗәрәсен барлап йөрде кебек.

*Әңгәмәне **Мөҗәһит Әхмәтҗанов** оештырды.*

Галия апа балалары Нәкыя, Хавис һәм Хавил белән. 1951 ел

Әниебез матур гөлләр үстерә

Әтиебез Әхмәтхавис Ахунҗан улы Ахунҗанов 1936 елда Мөслим районының Дусай авылында, әниебез Вәсилә Мирзаһит кызы Ахунҗанова 1937 елда Мөслим районының Яңа Сәфәр авылында туа. Алар 1959 елда өйләнешә. Әтием колхозда төрле эштә эшли. Соңрак умартачылык белән шөгыльләнә башлый. Лаеклы ялга чыкканчы, шул яраткан эшен ташламады. Әниебез гомер буе колхозда алдынгы сыер савучы булып эшләде. Безне – дүрт баланы җил-яңгыр тидермичә тәрбияләп үстерделәр. Абыебыз Радиф гаиләсе белән Себердә яши. Ике кыз үстерделәр, ике оныклары бар. Апабыз Нәсимә гаиләсе белән Туймазы шәһәрендә гомер итә. Бер улы, бер кызы, өч оныгы бар. Мин – Рәсимә – гаиләм белән Мөслимдә торам. Ике кызыбыз бар. Сеңлебез Рузилә гаиләсе белән Үрәзмәттә яши. Ике кызлары, бер оныклары бар.

Ни кызганыч, әтиебез Әхмәтхавис, 81 яше дә тулмаган килеш, бакыйлыкка күчте. Әниебезгә быел 80 яшь тулды. Ул матур гөлләр үстерә. Без – балалары, әниебез янына кайтып, аңа булышып, хәлен белеп торабыз. Аңа сәламәтлек, тыныч тормыш телибез.

Рәсимә Ахунҗанова ■

Безнең мирас №4 апрель 2018



БЕЗНЕҢ ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ

Рауль Мирхәйдәров

Чыңгыз Айтматов... Соңгы елларда әдәбият белән кызыксыну сүрелсә дә, әлеге исем барыбер һәрдаим телгә алына, һаман колакка ятыш әле. Шулай булмый, аның иҗаты уртак ватаныбызның берничә буын халкын тәрбияләп үстерде ләбаса. СССР калдыкларыннан гыйбарәт җирләрдәге миллион китап киштәләрендә бүген дә әдипнең бихисап әсәрләре саклана. Алай гына да түгел, бу исем бөтен дөньяга таныш. Әйе, Советлар Союзы үзенең мәдәният өлкәсендәге уңыш-табышларын күрә дә, күрсәтә дә белә иде.

Әдипне ил кадәр ил данлауга, мактауга һәм яратуга карамастан, аны аерым бер төбәкләрдә – Кыргызстанда, Казакъстанда, Татарстанда барыбер күп мәртәбә якынрак күрәләр иде. Ни өченме? Кыргызстан турында аңлатып торуның хаҗәте юктыр, мөгаен. Казакъстанга исә беркадәр тукталып узарга кирәк булыр. Бу республика әдипне чын әдип итәр өчен шактый зур көч куя. Эш шунда ки, Чыңгыз әкә беренче хикәяләре белән матбугатта күренә башлауга, әле узган гасырның егерменче елларында ук, аны күренекле казакъ язучысы, философ, «Абай юлы» исемле данлыклы эпопеясы аша үз халкының мәдәниятен, сәнгатен җиһанга таныткан Мохтар Әүезов үз канаты астына ала. (Җөмләдән, узган гасырның илленче елларында бу китап турыдан-туры татар теленә дә аударылып нәшер ителә.)

Мохтар әкә СССР Язучылар берлегендә гаять зур абруйга ия кеше булып, яшь язучыда искиткеч талант чалымнарын күреп, Чыңгыз Айтматовны беренче адымыннан ук хуплап, аңа кулыннан килгәнчә ярдәм итеп яши. Айтматов тормышында авыр чорлар да булмый түгел. Мондый вакытта, Мохтар әкә ярдәме белән, ул Казакъстанда фәкать әдәби иҗат белән генә шөгыльләнеп, лаеклы яшәү һәм эшләү мөмкинлегенә ирешә.

Татар халкы һәм Татарстан өчен әдипнең кем булуын шулай ук аңлатып тору кирәкме икән? Бу исемне үтә җылы ярату белән кабатлаган һәр татар кешесе әдипне үзенең милләттәше, туганы итеп тоя: Нәгыймә абыстайның (Чыңгыз Айтматовның әнисе) чыгышы белән Кукмара районының Мәчкәрә авылыннан булуы мең кат кабатланган һәм расланган инде.

Чыңгыз Айтматов, узган гасырның алтмышынчы елларыннан башлап, Казанга еш килә, аның, мәгълүм ки, соңгы сәяхәте дә анасының туган җиренә, татар башкаласына ясала.

Җитмешенче еллар башында мин дә, ул чордагы бик күп яшь каләм ияләре кебек, тәүге иҗат җимешләремне Чыңгыз Айтматовка юллап, аның киңәш-табышын алып «үстем». Безнең шәхси танышуыбыз да шул елларда, «Мәскәү» кунакханәсендә булды. Бу эштә миңа үзгә бер күренекле әдип, әдәбият классигы Мостай Кәрим булышлык итте. Айтматов сиксәненче елларда «көчле куч» буларак танылган язучылар төркеменә «керә» иде, болар: Кайсын Кулиев, Рәсүл Гамзатов, Давыд Кугелтдинов, Мостай Кәрим. Араларыннан иң әүвәл Кайсын Кулиев китте, иң ахырдан – Чыңгыз Айтматов.



Чыңгыз Айтматов. 1980–1990 нчы еллар

«Ата-Бәйит» мемориаль комплексында Чыңгыз Айтматов кабере. Чон-Таш авылы

Түрәкол Айтматовның (Чыңгыз әкәнең әтисе) 1938 елда атылганы билгеле. Зур язучы, депутат, илче булып танылгач, Чыңгыз Айтматов әтисенең каберен эзләргә тотына. Ләкин туксанынчы еллар башында гына морадына ирешә.

Бу уңайдан халык арасында йөри торган бер вакыйгага игътибарга лаек.

1992 елда, Кыргызстан дәүләт бәйсезлеге алганнан соң, тау арасындагы бер авылда үлем белән якалашкан карчык үзен гомер буе изалаган серне кызына ача.

Әле үсмер генә чакта ул, көзге көннәрнең берсендә гөлҗимеш җыеп йөргәндә, адаша һәм авылдан шактый ерак урнашкан бер ерымга килеп чыга. Озакламый арбасы ябылган машина пәйда була. Аннан күзе-кулы бәйләнгән унбишләп кешене төшерәләр дә, берәмтекләп атып үтергәч, өсләрен тиз-тиз генә таш белән каплап, күздән югалалар. Калтырана-чаба өенә кайтканда кыз тагын шундый ук егермеләп каберлеккә юлыга һәм бу кешеләрнең кем булуын тәмам аңлап өлгерә: бишенче сыйныфта гына укыса да, мәктәптә аларга «халык дошманнары» дигән «кабахәт» кешеләр турында бик күп сөйләгән булалар инде. Кыз бу хакта әти-әнисенә дә, укытучыларына да хәбәр итәргә базмый. Шушы коточкыч серне җанына яшереп саклый һәм... соңгы мизгелдә генә күңелендәгесен ачып сала.

Аның кызы, Бишкәк шәһәренең казые (судьясы) бу мәсьәләгә җәмәгатьчелек игътибарын юнәлтә. Озакламый карчык әйткән урында бихисап каберлекләр табыла, җаны кыелганнарның байтагын исемләп исәпләп чыгаралар, араларында кыргызлар да, татарлар да, урыслар да, казакълар да, үзбәкләр дә, әрмәннәр дә, башкалар да... шул исәптән, Түрәкол Айтматов та була.

Репрессия корбаннары истәлегенә бередә «Ата-Бәйит» («Аталар зираты») мемориалы корыла, ак мәрмәр ташларга Сталин режимы корбаннарының исемнәре теркәлә.

Чыңгыз Айтматов шул рәвешле әтисенең каберен таба, ә үзен аның янынарак җирләргә васыять итә. Һәм, әйтергә кирәк, аның васыяте җиренә җиткерелеп үтәлә.

Мин исә, бүген, бердәм дәүләт юкка чыгып, чикләр, таможнялар барлыкка килгән һәм, өстәвенә, халыкның «ындыр артыннан» ары китәргә матди мөмкинлеге булмаган көндә (кая ул Кыргызстанга бару!), һич югы, шушы мәкалә аша кадерле язучыбызны, безнең Чыңгыз Айтматовны яд итәргә кирәк санадым.

***Миләүшә Талипова** тәрҗемәсе.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

«БИШЕКТӘН ҮК ИРТӘ ТӨШКӘННӘР...»

Илгизәр Фазлуллин

Күренекле татар-совет шагыйре Гали Хуҗи – көз аенда дөньяга килеп, көз аенда вафат булган әдип. Ул озак еллар дәвамында Ленин районындагы (хәзерге Авиатөзелеш районы) әдәбият-иҗат берләшмәсенә җитәкчелек итте.

Гали Хуҗи

Исән булса, бүген аның турында әллә нихәтле матур сүзләр әйтелер иде. Ләкин шулкадәрлесен дә мин бик яхшы беләм: мактау-олылаулар башланса, сәхнәдән үк төшеп китәр иде ул. Чөнки шагыйрь буларак та, шәхес буларак та, Гали Хуҗи үзен бик тә тыйнак, әдәпле тота иде.

...Хәтеремдә, 1966 елның яз ае. Авиация заводы редакциясендә телефон шалтырады (мин редакциядә эшли идем). Гали абый Соцгородтан шалтырата икән.

– Эшең күпме? – дип кызыксынды ул.

– Беләсез инде, Гали абый, күптиражлы газетадагы эшне, кем әйтмешли, тавык та чүпләп бетерерлек түгел, – дип көлемсерәп җавап бирдем мин.

– Беләм, беләм... Шулай да син хәзер үк Соцгород паркына кил әле.

Гали абый парктан ерак түгел генә тора иде. Шунда ашыктым. Ул инде килеп тә җиткән, өстендә – көзге драп пәлтә, башында – эшләпә, аякларында – «прощайка»лар...

Килеп җитүемә, ерактан начар күрә торган күзләрен кыса төшеп, серле генә елмаю белән миңа текәлеп карап тора. Икебез дә сүзсез.

– Күрәсем килде, – дип башлады ул сүзен. – Бераз гына эчемне дә бушатып алыйм әле, дидем. – Аннан сүзен ишетелер-ишетелмәс кенә итеп дәвам итте: – Беләсеңме, табиблар миңа хастаханәгә ятарга кушалар. Барасым килми. Профессор да, дәваланырга кирәк, ди. Ничек инде авырып ятарга кирәк әле бу яшьтә. Алда – тау кадәрле эшләр, ничаклы планнар. Әлмәттә дә яшь әдипләр көтеп яталар...

Ул тагын тынып кала. Ә минем аның саен йөрәгем «жу» итеп куя, чөнки бу минутларда мин аның нинди дер бер йөрәк серен ачарга җыенуын сизеп-чамалап торам...

– Күңелемдә бер борчуым кала: Тукайлар, Сибгатләр кебек шагыйрь булып булмады бит, – ди ул.

Мин, бу сүзләрне ишетеп, ни әйтергә дә белмичә, сүзсез калдым, берничә минут узгач кына Гали абыйны юатырга-тынычландырырга керештем. Шулчак фронтовик-шагыйрьнең күзләрендә тәүге тапкыр яшь бөртекләре күрдем...

Әйе, шагыйрь чишмәсенең халык күңеленнән башлануын Гали абый яхшы белә иде шул. Шагыйрь Сибгат Хәкимгә багышланган «Чишмә» исемле шигырендә ул моны бик матур итеп әйтеп биргән иде:

«Кибәр, бәлки, Фазыл чишмәсе,
Ни буласын алда кем белгән.
Гомер кипмәс шагыйрь чишмәсе –
Башлана ул халык күңеленнән».

Шәхси китапханәмдә Гали Хуҗиның төрле елларда үзенең култамгасы белән җылы сүзләр язып биргән шигырь җыентыклары кадерләп саклана.

Аның һәр сүзеннән кешеләргә карата гаять игътибарлылык, җылылык һәм кайгыртучанлык рухы бөркелеп тора иде. Чын йөрәктән әйтелгән булулары, табигыйлекләре белән укыган саен дулкынландыра, уйландыра алар.

Гали абый Хуҗи озак еллар дәвамында Казан авиация заводындагы әдәби иҗат берләшмәсе (мин аның бюро рәисе идем) әгъзаларының һәркайсы белән дә дусларча элемтәдә яшәде. Ул безнең янга иң хөрмәтле әдибебез булып килеп йөрде, вакыты-чамасы, саулыгы-сәламәтлеге белән һич кенә дә исәпләшеп тормастан, һәркайсыбызга да ярдәм-булышлык күрсәтергә, иҗади илһам, омтылыш һәм дәрт биреп торырга тырышты.

Ел артыннан ел уза торды. Мин: «Нигә әле шулай бик тә үз күрде, яратты икән Гали абый завод яшьләрен?» – дип, үз-үземә сорау бирә һәм шуңа җавап эзли торган идем. Моның сәбәпләре болай, минемчә. Апас районының Карамасар авылында тимерче гаиләсендә туып үскән Гали абый Хуҗи соңгы сулышына чаклы авиация заводыннан ерак булмаган Соцгородта яшәде.

Авыз тутырып әйтә алам: Гали абыйга, үзе кебек үк, эшче халыкның тыйнак, дуслыкта хилафсыз, тугрылыклы булуы, гадилеге ошый иде. Менә аның «Таныш миңа завод егетләре» дигән шигыре. Анда мондый юллар бар:

«Таныш миңа завод егетләре,
Бишектән үк иртә төшкәннәр.
Бик күпләре сугыш михнәтләрен
Буразнада татып үскәннәр.

Буразнадан – завод цехларына,
Яхшы түгел юлда соңлавы.
Колакларда йөргән башак шавын
Алыштырган металл чыңнары.

Кичке мәктәп, соңра кичке вузлар
Үзләренә дәшкән күпләрне.
Кайсылары инде – инженерлар,
Үтәгәннәр заман көткәнне.

Шулай атлый алар иртәгәгә,
Таптану юк бер үк урында;
Бергә килсәк, кызык бәхәс китә
Замана һәм шигырь турында.

Дөреслек күп алар каршында –
Чын җыр белән гаҗәеп дус алар;
Чыгар, бәлки, алар арасыннан
Яңа Тукташ, яңа Мусалар.

Яшьләр күңеле шундый – хис-тойгыдан
Беркайчан да тормый бушанып.
Киләчәкне мондый алмашларга
Тапшырырга була ышанып...»

Әдәби иҗат түгәрәгенә 1934 елда ук иң беренче җитәкче итеп Хәсән Туфан билгеләнгән бу заводның эшче-яшьләре, иҗади яшь көчләре белән дуслыкны, аларга, профессиональ шагыйрь буларак, бернинди дә түләүсез-нисез эчкерсез ярдәм-булышлык күрсәтүне солдат, гражданин, шагыйрь Гали Хуҗи үзенең зур горурлыгы

һәм вөҗдан эше итеп санады. Үзендәге шундый горурлык хисләре белән һәм, әлбәттә, эшче авторлар, аларның иҗатлары белән якыннан таныштыру, аларга файдалы киңәшләр ишеттерү өчен ул әдәби-иҗат түгәрәге утырышларына үзе белән Хәсән Туфан, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Гази Кашшаф, Шәрәф Мөдәррис, Нәби Дәүли, Зәки Нури, Әхмәт Исхак, Габдрахман Минский, Мөхәммәт Садри, Илдар Юзеев, Сафа Сабиров, Барлас Камалов, Шәүкәт Галиев һәм башка бик күп күренекле әдип-шагыйрьләрне алып килде, алар белән якыннан танышу, озаклап сөйләшү-фикерләшү бәхетенә ирештерде.

Шушы түгәрәктә (соңрак берләшмә) беренче чыныгу алган Тәүфыйк Камалиев, Нурислам Хәсәнов, Заһид Фәйзи, Борһан Садретдинов һәм башкаларның шигырьләрен, хикәя һәм повестьларын укучылар яратып кабул итте.

Гали абый үз чорындагы бөтен әдипләр белән дә дус-тату гомер кичерде, аның исемен һәркем хөрмәтләп, якын-үз итеп телгә ала иде.

Бөек Җиңүнең 50 еллыгы алдыннан фронтовик-шагыйрь Мөхәммәт Садри да үзенең «Без хәрби журналист идек» дип исемләнгән язмасында «Ватан намусы өчен» дигән фронт газетасында (мөхәррире – Риза Ишморат) Гали Хуҗин белән бергә эшләүләрен бик җылы итеп тасвирлады: «...Мине, кая юл тотуымны сораштыргач, бер агач йортка алып керделәр. Монда фронт политик идарәсенең бер бүлеге урнашкан икән. Пакетымны яшь подполковникка бирдем. Ул, аны ачып... язмалары белән танышты да, шунда ук озата чыкты:

– Сезнең иптәшләр ерак түгел, шушы Лясовка авылы читендәге өйдә, – диде.

Итегем тузган иде. Берсенең табаны төшә язды. Аны бау белән бәйләдем дә, юлымда булдым. Тиз-тиз атлап, әлеге өйнең тәрәзәсе янына туктадым. Ул томаланган, ә өй эчендә бер тавыш та юк иде. Ишеккә барып, сак кына кактым. Көчлерәк итеп тагын бер каккач, татарча сөйләшкәнне ишеткәч, туңган аягыма җылы йөгергәндәй булды.

– Кто там?!

– Мин – Мөхәммәт Садри.

– Кем дисең, кем?

Исемемне тагын әйттем.

– Шикләнмә, Гали, ач! – дигән тавышка ишек ачылу белән, ап-ак күлмәк-ыштан кигән Гали Хуҗины кочаклап алдым.

– Кайдан килеп чыктың безгә, Садри? Ничек таптың?

– Хак Тәгалә, ни тели, шуңа хаклы. Миңа да канат куярга җай тапты! – дидем Тукайчарак итеп.

– Сезгә эшкә килдем. Дошманга каршы сезнең сафта, сезнең белән бергә көрәшергә җибәрелдем, – дидем.

Риза абый Ишморатны да тиз таныдым. Ул да җылы кулы белән күрешеп, мине кочагына алды...»

1942 елда үз теләге белән сугышка киткән, Бөек җиңү көненә кадәр Беренче Украина фронтында «Ватан намусы өчен» гәҗитенең җаваплы сәркатибе булып эшләгән, сугышчан батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнгән шагыйрь Гали Хуҗиның сугыштан соң иҗат ителгән «Зоя Космодемьянская», «Россия», «Гражданин солдат, шагыйрь», «Яу күрке», «Дуслык хикәясе» кебек поэмалары поэзиябезнең матур үрнәкләреннән берсе дип саналырга хаклы.

Аяныч ки, Гали аганың гомере кыска булды – 1966 елда бакыйлыкка күчте. Ләкин ул иҗат кешесенең халык алдындагы зур җаваплылыгын бөтен тулылыгы белән тоеп яшәде. ■

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

«ЯҢГЫР ҖИЛЕ» – ШИФАЛЫ ҖИЛ

Эльмира Шәрифуллина

Эльмира Шәрифуллинаның якташы, каләмдәше Ләбиб Леронга биргән култамгалы китабы

Бүгенге көндәге эш кәгазенең киләчәк өчен әлләни әһәмияте булыр кебек тоелмаса да, кайберләренең кирәге чыга һәм, вакытлар үтү белән, шактый кыйммәтле ядкәргә әверелә икән.

Архивым сәхифәләрен актарып утырганда, «Яңгыр җиле» исемле лирик шигырьләр китабымны басмага әзерләү һәм китапның дөньяга чыгу тарихы турында сөйләүче беркетмә-карарлар, бәяләмәләр, Язучылар берлегенә тәкъдим иткән җыелышның беркетмәсе игътибарымны кабат җәлеп итте. Китабымның басылуы да, Язучылар берлегенә тәкъдим ителүем дә, үз тәртибендә, билгеле бер эзлеклелек белән барган. Башта, 1982 елның 19 июнендә, Татарстан Язучылар берлеге каршындагы шагыйрьләр секциясе утырышында «Яшь шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның кульязма җыентыгы турында фикер алышу» дигән мәсьәлә көн тәртибенә куелып, җыелыш үткәрелгән. Анда Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Илдар Юзеев, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Мингалимов, Әхмәт Рәшитов, Харрас Әюпов, Рифкать Закиров, Фәридә Хәсәнова, Рашат Низамиев, Госман Садә, Зөлфәт, Асия Минһаҗева, Нәбирә Гыйматдинова, Рәшит Әхмәтҗанов, Наис Гамбәров, Илдус Якупов, Мөхәммәт Муллануров, Фәннур Сафин, Мөдәррис Әгъләмов, Хәйдәр, Газинур Моратов катнашкан. Җыелышта:

Гөлшат Зәйнашева



Рәшит Әхмәтҗанов

Ләбибә Ихсанова

«Яшь шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның кульязма җыентыгын китап итеп бастыру өчен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә», – дигән карар чыгарылган. Карарны шагыйрьләр секциясенең бюро рәисе Рәдиф Гатауллин һәм сәркатибе Харрас Әюповлар имзалый. Мин исә, 1982 елның 28 нче июнендә, кульязма җыентыгыма «Яңгыр җиле» дигән исем куеп, Татарстан китап нәшриятына илтәм. Аңа Әхсән Баян, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиевләр әчке рецензия яза.

Мәшһүребез Зөлфәтнең ихластан яратып язылган кереш сүзе белән басылып чыккан «Яңгыр җиле»н җәмәгатьчелек бик җылы кабул итте. Мөдәррис Әгъләмов, Фәнис Яруллин, Әмир Мәхмүдов, Әзһәр Габидиләр, китап дөнья күрүгә, «Идел» альманахы, «Татарстан яшьләре», «Коммунизм таңы» (Минзәлә), «Игенче даны» (Актаныш), «Авыл утлары» (Мөслим) кебек газета-журналларда яхшы бәяләмәләрен бастырды.

Шуннан соң, ягъни 1984 елның 28 сентябрендә тагын шагыйрьләр (шигърият) секциясе җыелды.

Утырышның көн тәртибендә: «Эльмира Шәрифуллинаның иҗатын тикшерү һәм аның иҗатындагы бүгенге көн герое турында сөйләшү» мәсьәләсе куелган иде.

ӨЗЕМТӘ

Татарстан Язучылар союзының шигърият секциясе утырышы (24 сентябрь, 1984 ел) беркетмәсеннән

Катнашалар: Рәшит Әхмәтҗанов, Рашат Низамиев, Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Разил Вәлиев, Мансур Вәлиев, Аяз Гыйләҗев, Харрас Әюпов, Әхмәт Рәшитов, Индус Сирматов, Мөдәррис Әгъләмов, Рөстәм Мингалим, Әхмәт Гадел, Ркаил Зәйдуллин, Газинур Моратов, Солтан Шәмси, Ләис Зөлкарнәев, Фәннур Сафин, Рифкать Закиров, Госман Садә, Равил Кукушкин, Хәлим Җәләлов, Фәиз Зөлкарнәев, Ләбиб Леронов, Ринат Мөхәммәдиев, Ләбибә Ихсанова, Гөлшат Зәйнашева, Наил Таиров, Эльмира Шәрифуллина.

Көн тәртибе: Эльмира Шәрифуллинаның иҗатын тикшерү (Э.Шәрифуллина иҗатында замандаш образы).

Рәис: *Х.Әюпов*
Сәркатип: *Г.Садә*

Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ:

– Эльмира Шәрифуллина иҗаты белән күптән кызыксынып киләм. Аның «Яңгыр җиле» – бик көчле китап.

Әлеге китапны укып чыканнан соң, күңелдә якты кичерешләр пәйда була. Миңа калса, китап җирдә тормыш кирәклеген, кешенең кайгы-сагышларын, авырлыкларны җиңә алуын тагы бер мәртәбә ассызыклый. Шигырьдәге нәфислек, матурлык күңелне шундый уйларга этәрә. Шунысы куанычлы – шагыйрә саф, халыкчан тел белән яза. Шагыйрә буларак, ул соңгы елларда бик үсте, зур ыргылыш ясады, дип әйтәсе килә.

Аның шигырьләре хис вулканын хәтерләтә. Алар бик табигый яңгырашлы. Шагыйрә Эльмира Шәрифуллина иҗаты бүтән бер шагыйрьнекенә дә охшамаган, аның үз поэтик йөзе, үзенә генә хас темасы бар. Аның шигырьләрен өзлексез мактарга була. Әмма шундый сорау туарга мөмкин: шагыйрь буларак үсәме ул? Әйе, хәзерге вакытта аны өлгереп җиткән шагыйрь, дип әйтергә мөмкин. Мисал итеп, аның «Сөю яктысы» дигән шигырен китерергә була. Әлеге шигырьдәге моң халык җырларын хәтерләтә. Киләчәктә шагыйрә поэма жанрында да эшләр әле, дигән өметтә калам. Аның иҗатын тикшерүне бик вакытлы һәм урынлы дип саныйм.

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА:

– Рәшит Әхмәтҗанов Эльмира Шәрифуллинага бик дөрес бәя бирде. Ул – бик җитди шагыйрә. Бу хакта аның шигырь китабы сөйли. Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова, Нурия Измайлова традицияләрен дәвам иттерә. Төгәл итеп әйтү – аның шигырьләренең төп үзенчәлеге. Тематикасы киңәя, алга таба да шулай дәвам итсә, болар аның шигъриятен бизәячәк кенә. Китапта ул Ана булып гәүдәләнә, шигърияте куәтле, кызыклы.

Мәхәббәт турындагы шигырьләре мине аеруча куандыра. Алар киң планлы, тирән эчтәлекле. Мин аның күп иҗат итүен телим. Эльмира Шәрифуллинаның әдәбиятка килүен хуплыйм.

Ләбибә ИХСАНОВА:

– Мин Эльмира Шәрифуллинаның иҗатын даими күзәтеп киләм, шигырьләрен яхшы беләм.

Алда сөйләгән иптәшләргә кушылам. Эльмирага: «Афәрин!» – диясе килә. Аның иҗаты Саҗидә Сөләймановыныкына якын тора.

Эльмираның осталыгы күзгә күренеп үсте. Өстәвенә, ул бит проза да яза әле. Аның язганнарын төзәтергә кирәкми, алар – җитлеккән әсәрләр. Шагыйрә буларак, Ана образын бик көчле тасвирлый. Шагыйрә – рәссам. Мин аңа зур өметләр баглыйм. Аның шигырьләре кыю язылган. Шагыйрәне СССР Язучылар союзына әгъза итеп тәкъдим итәм.

Әхмәт РӘШИТОВ:

– Эльмира Шәрифуллина шигырьләре миңа бик ошады. Шигърияткә ул кыю адымнар белән килде. Эльмира Шәрифуллина шигырьләре елак түгел, киресенчә, алар кыю, көчле язылган. Шагыйрә тормышка оптимистларча карый. Эльмира Шәрифуллинаны СССР Язучылар союзына әгъза итеп алырга кирәк. Союз әгъзасы булу зур җаваплылык өсти, тагы да күбрәк иҗат итәр өчен бер стимул булып тора.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ:

– Эльмираның иҗаты – җитлеккән иҗат. Мин аны прозаик һәм очерк язучы буларак яхшы беләм. Ул проза өлкәсендә дә зур уңышларга ирешер әле, дип уйлыйм. Әсәрләренең теле бай, телне яхшы тоя. Фигыльләрне бик кызык кулланып яза. Кайбер ир-ат язучыларыбыз аның кебек яза алмый. Кыскасы, Эльмира Шәрифуллинаны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим итәм.



Харрас Әюпов

Илдар Юзеев



Мөдәррис Әгъләмов

Нурихан ФӘТТАХ:

– Безнең әдәбиятта шагыйрәләр бихисап. Эльмира Шәрифуллинага килсәк, аның шигырьләре мине үтә ихласлыгы белән җәлеп итте.

Мәхәббәт турындагы шигырьләре төгәл, максатлы язылган. Укучыларның хәл-халәтен аңлап, тоеп яза. Шагыйрә халык телен яхшы белә. СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим итәм.

Фәннур САФИН:

– Эльмира Шәрифуллина шигырьләре – өлгергән әсәрләр. Җитлеккән шигырьләр. Алда сөйләгән иптәшләргә кушылып, мин дә Эльмира Шәрифуллинаны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим итәм.

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ:

– Эльмира Шәрифуллинаның иҗатын барыбыз да яхшы белә, ул СССР Язучылар союзы әгъзасы булырга лаек.

Мансур ВӘЛИЕВ:

– Эльмира шигырьләре хисләргә төрелеп язылган. Хәзер аңа фикер тирәнлегенә ирешеп язарга кирәк. Аны СССР Язучылар берлегенә тәкъдим итәм.

Илдар ЮЗЕЕВ:

– Эльмира Шәрифуллина иҗатына ихласлык хас. Шигърияткә килгән шагыйрь үзенә зур җаваплылык ала. Киләчәктә Эльмира үзен чын мәгънәсендә шагыйрә итеп танытыр, дип уйлыйм.

Харрас ӘЮПОВ:

– Йомгаклап шуны әйтәсе килә, барлык чыгыш ясаучылар да шагыйрә иҗатына уңай бәя бирде. Эльмира Шәрифуллинаны СССР Язучылар берлегенә тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйм.

КАРАР: Эльмира Шәрифуллинаны СССР Язучылар берлегенә тәкъдим итәргә (бертавыштан).

Рәис: *Харрас Әюпов*
Сәркатип: *Госман Садә*

Бертавыштан кабул ителгән карар нигезендә, шагыйрь Зөлфәт, прозаиклар Аяз Гыйләҗев һәм Ләбибә Ихсанова тәкъдимнамә бирде. Зур өметләр баглап, иҗатымның башында ук югары бәя биреп ясалган чыгышлар, язылган юлламалар миндә бүген дә горурлык һәм рәхмәт хисләре уята. Аларны да укучылар хөкеменә тәкъдим итәм.

Тәкъдимнамәләрнең берсе – Аяз Гыйләҗевнеке – татарча, икесе – Зөлфәт белән Ләбибә Ихсанованыкы русча язылган. Без аларны ничек бар шулай сезнең хөкемгә тапшырырга булдык.

Редакция

БЕРЕНЧЕ ТӘКЪДИМНАМӘ

Читая и перечитывая настоящие стихи, перед тобой невольно возникает образ самого автора, человека, изобразившего изумительные порывы человеческой души посредством вроде бы знакомых, обыкновенных слов.

Многие именно таковы. Ее сборник стихов «Яңгыр җиле» – «Преддождивой ветер» (в выходных данных – «К дождю») действительно напоминает состояние человека перед порывом таинственного, беспокойного, поразительно загадочного дождевого ветра. Боли и радости женщины, матери, гражданки своей страны вошли в ритмический строй стихов поэтессы. К понятиям Судьба, Родина, Человек, Мир она приходит через личное. В стихах Эльмиры Шарифуллиной очень много личного. Ее собственная судьба отчетливо отражается в ее стихах.

Две повести, написанные ею в последнее время говорят о приходе к литературу интересного, самобытного прозаика.

Я знаю ее и как ведущего журналиста-публициста. Она часто выступает в периодической печати на темы морали, коммунистического воспитания детей и юношества.

Работая в республиканской пионерской газете «Яшь ленинчы», Эльмира Шарифуллина держит постоянную связь с детворой, хорошо знает пионерскую и школьную жизнь, что благотворно отражается в ее творчестве.

Ее произведения отличаются свежим, сочным языком. Образы и метафоры в ее речи возникают только тогда, когда они необходимы, когда они к месту.

Одно пожелание: поэтессе надо расширить тематику.

Рекомендуя Эльмиру Шарифуллину в СП СССР, остаюсь уверенным, что поэтесса напишет много волнующих строк на радость любителям литературы.

Дульфат Маликов (Зульфат),
член СП СССР с 1973 года, № членского билета 03977.
29 октября 1984 г.

ИКЕНЧЕ ТӘКЪДИМНАМӘ

Эльмира Шәрифуллинаны Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итәм. Талантлы шагыйрә, сәләтле прозаик. Үзенчәлекле характер. Иң мөһиме – татар телен әдип өчен кирәгенчә белә. Аның замандашлары телебезнең нечкәлеген, ләззәтен, сафлыгын онытып барганда ул саф татарча иҗат итә ала. Тел – корал. Эльмира Шәрифуллина хаклык-турылык, бәхет өчен көрәшкә коралланган хәлдә чыга ала. Шагыйрә үз кайгы-шатлыгын Ил кайгысы, Халык шатлыгы дәрәҗәсенә күтәрә алса, ил-көннең кайгы-шатлыгын тулаем үзенеке итә ала. «Яңгыр җиле» исемле китап – моның шаһиты. Зөлфәт белеп, яратып, шагыйрәнең киләчәгенә өмет баглап якты кереш сүз язган. Аның белән килешмичә мөмкин түгел. Хисләр чын икән, аларга исем табып була. Эльмирада исемсез хисләр юк, алар һәммәсе дә кешегә, кешелеккә төгәл адрес белән төбәләләр. «Җир-ана» шигырен генә алыйк. Уй, мәгънә, күңелне кузгатырлык хисләргә үрелеп, өзелмәс тоташып бара. «Хыялымда кайтып килдем» шигырендә халыкның «утырып уйлар уйладым» дигән җан авазы яңа булып, шагыйрәнең үз сүзе булып яңгырый алган. Беренче карашка үтә интим булып күренгән шигырьләрдә дә дөнья гаме ярылып ята. Ялгыз кешенең кайгысы, әгәр ул кайгы чын икән, берчакта да илдән аерылып калырга тиеш түгел. Һәр күңелнең кайгы-моңы, безнең уртак эшебез. Шагыйрьләр ил өчен

җаваплы булган кебек, ялгыз кешенең язмышы өчен дә кешеләр җаваплы. Шагыйрә беренче китабыннан ук моны тоеп яза.

Эльмира кызыклы прозаик та. Мин аның ике повестен укып чыктым. Монда да сыгылмалы, җанлы, тулы сулышлы татар теле. Монда да колак төбендә чыңлап моң тора. Ил моңы, кеше моңы, кешелек моңы. Моң – җан ул. Җанны күрергә теләсәң, моңга колак сал. Эльмира – моңлы бала.

Дөрес, әле авторга тема киңлеге, колачның ныклыгы җитеп бетми. Әмма олы юлга чыгу өчен һәммәсе дә бар: талант та, теләк тә, мөмкинлек тә. Шагыйрәне үз арабызга алырга кирәк. Союз аңа киңлек бирер, ышанычын арттырыр, адымнарын ныгытыр. Алда юллар күп, Эльмира үз юлын табып килә, аңа бу юнәлештә ярдәм итәргә дә кирәк.

Мин аның алдагы көненә ышанам.

Аяз Гыйләҗев,
29 октябрь, 1984 ел, Казан.

ӨЧЕНЧЕ ТӘКЪДИМНАМӘ

Я, Лябиба Ихсанова, с 1958 года являюсь членом Союза писателей СССР.

С большим интересом слежу за творчеством Эльмиры Шарифуллиной.

Начинала она робко. В детской печати все чаще начали встречаться ее стихи, материалы написанные для детей. Но даже эти стихи, статьи пробуждали, в какой-то степени, веру в будущей поэтессе. Такое ощущение, будто Эльмира свое становлене утвердила не на страницах печати, а за своим творческом столом. И вот она, как забивший родник, спускающийся с высоких гор, запевший во всю свою мощь, красивым, чистым голосом. Может причиной этому было то горькое, что она испытала в жизни.

Поэтесса пишет о сильных переживаниях. Но ее стихи не об отдельных интимных чувствах, а они превращаются в переживания всего человечества. Эти стихи – горе матерей, потерявших в Великой Отечественной своих сыновей и мужей. Эти стихи – обращение к своим современницам, призыв быть всегда красивой и чистой...

Стихи Эльмиры Шарифуллиной богаты образными действиями. Она проникла в самые тонкости татарского языка. Чувства настоящие, в них верится.

У нее есть тема, которую знает и чувствует только она. Это – мир матери и ребенка, сердце матери и ребенка. И она открывает нам этот мир теми чувствами, словами, которые доступны только женщине. С этим случаем я хочу ей пожелать: пусть вынесет в будущем этот великий образ в большой мир, свяжет его с народом. У Эльмиры на это хватит и таланта, и знания, и старания.

Я ее знаю уже как поэтессу, нашедшую свою дорогу, своего читателя, поэтому считаю ее достойной быть членом Союза писателей СССР и даю свою рекомендацию.

Лябиба Ихсанова.

Биредә, төзәтмә кертеп, бер генә фикер әйтәсем килә. Татарстан китап нәшриятында басылган «Яңгыр җиле» – минем икенче китабым. Кайбер урыннарда китапның беренче дип аталуында җыентык ахырына язылган аннотациядәге «Моңарчы шагыйрәнең әсәрләре вакытлы матбугат битләрендә күренә килде. Бу – аның беренче китабы...» – дигән сүзләр сәбәпче булгандыр, дип уйлыйм. Минем инде Татарстан китап нәшриятында 1976 елда ук, киләчәктә тагын өч мәртәбә кабатлап бастырылачак, тиражы ярты миллион (550000) данәгә җитәчәк «Безнең зоопарк» исемле беренче китабым чыккан иде.

Кыскасы, олпатларыбызның чын күңелдән язылган менә шушындый фатыйхалары белән Язучылар берлегенә кабул ителдем һәм «Шәрифуллина Эльмира Мөхәммәт кызы 1985 елның 14 февраленнән СССР Язучылар берлеге әгъзасы» дигән 05217 номерлы билет алдым. ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

Гаяз Исхакый
(1878-1954)

Гаяз Исхакый. 1900-1910 нчы еллар

Тууына февраль аенда 140 ел тулуга карамастан, милләтебезнең олуг хадиме, дөньякүләм танылган әдип, журналист, нашир, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның юбилей чаралары җөмһүриятебездә шактый тыйнак, «кеше белмәсә ярар иде» дәрәҗәсендә генә узды. Гәрчә бөтен гомерен халкының әдәбияты, сәнгате, мәгърифәте, алар аша – алгарышы һәм, һичшиксез, бәйсезлеге, азатлыгы өчен фида иткән бу бөек зат аерым олылауга, киң колачлы игътибарга лаек иде.

Заманнар үзгәрә тора. Әле унбиш ел элек, ни дисәң дә, барыбер ышанычлы төсмердә яңгыраган «мөстәкыйльлек» сүзен биш ел элек әрнеп һәм яшь аралаш көлемсерәп кабатлауга күчсәк, бүген аны, гомумән, сөйләмебездән төшереп калдырдык инде. Сыңар халыктан, сыңар телдән, сыңар диннән торган бердәм вә бүленмәс империя торгызу мәйданында үзен җиң сызганып эшләгән намуслы прораб итеп күрергә һәм күренергә омтылган Татарстан бүген Гаяз Исхакый кебек үзгә идеология, үзгә кыйбла вә үзгә иман тарафдарын читсенә кебек...

Мондый вазгыятьтә милләтебезнең йөзек кашын күренекле шәхесләребезнең үлем-китеменә багышланган «Очты дөнья читлегеннән...» сәхифәсендә искә алу да үзенә күрә бер эчке мәгънәгә ия түгелме икән?

Әдипнең ашказаны чире белән тартыша-тартыша фани дөньяда соңгы сәгатьләрен уздырган һәм җир куенына тапшырылган чагы замандашлары тарафыннан шактый тулы, төгәл рәвештә кәгазьгә төшерелгән. Аларның һәммәсен Гаяз Исхакый әсәрләренең 15 нче томында табарга мөмкин. Истәлекләр буенча шул борчулы һәм гаять күңелсез көннәрне күз алдыннан кичерик.

«Гаяз Исхакый – Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы» исемле мәкаләсендә күренекле татар, төрек, алман әдибе һәм сәясәт эшлеклесе **Гали Акыш** болай дип яза: «Г.Исхакый Икенче дөнья сугышында алманнар белән берлектә урысларның да җиңеләчәкләренә инанган иде. Әгәр америкалылар һәм японнар зур тарихи хаталар ясамаган булса, Икенче дөнья сугышы без теләгән рәвештә тәмамланачак иде. Аңа да карамастан, дөньяда һичбер самодержавие режимының мәңгелек булмавы хакындагы чынбарлыкны онытмаган Исхакый, үзеннән соң килгән буынга васыять итеп, үлеменә өч көн калгач, шушы юлларны язучыга *(ягъни Гали Акышка. –* **Р.М.***)* әйтеп торып, Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәгән мәрхүм имам Хәбибрахман Шакирга (Болгари) бер хат яздырды. Ул хатның эчтәлеге белән биредә сезне дә таныштырабыз.

1954, 19 июль,
Анкара

ХӨРМӘТЛЕ ХӘБИБРАХМАН ХӘЗРӘТ!

Мин 26 майдан бирле Анкарада. Бераз вакыт хастаханәдә яттым. Инде кызымда яшим. Аллага мең шөкерләр булсын, кызым һәм киявем мине бик яхшы карыйлар. Алардан бик ризамын. Минем хәлем бер дә яхшы түгел. Аягымның шешләре үземне идарә итәргә комачау итә. Шуңа күрә минем саулыгымның яхшы булуы турындагы хәбәрләргә ышанмагыз. Бер могҗиза булмаса, сулар сулышым бу айда, бәлки дә, бу атнада киселәчәк. Мин дә гөнаһлы башымны Алла рәхмәтенә соначакмын. Мин мөселман ата-анадан тудым һәм мөселманча тәрбия алдым. Кануни караштан мин төркимен, һичбер төрки кавемгә дошманлык эшләмичә, бөтен гомерем буе үземнең халкым – төрки-татар халкының уңышы һәм бәхете өчен хезмәт иттем. Бу эшләрне эшләгәндә һичбер төрки кавемгә зарар китермәдем. Әгәр минем хаталарым булган икән, кардәшләрем мине гафу итсеннәр, хакларыны хәләл итсеннәр. Үз арабыздагы татарлык, башкортлык, мишәрлек һәм нугайлык юлларына кермәдем. Кулымнан килгәнчә, тар кабиләчелектән качтым. Минем фикеремчә, Татарстан белән Башкортстанны бер-берләреннән аеру да һәммәсен җыеп берләштерәчәк Идел-Урал Милли Идарәсен юк итү өчен уйлап чыгарылган Совет шайтанлыгыннан башка бернәрсә дә түгел. Минем ышануымча, Совет буйсындыруы астында изаланган кырык миллион төркинең киләчәктә сәяси конфедерация шәкелендә берләшүе, ул да булмаса, уртак мәдәни берлекне югалтмыйча, ягъни уртак мәдәниятка ия буларак, Аурупа берлегенә тигез хокукта керүе, Аурупа берлеге гаиләсендә дәрәҗәле урын алуы иң дөрес юл булачак. Тәңре сезләргә барлыклы тормыш итүне һәм Ватаныбыз Идел-Уралның азат булуын күрүне насыйп итсен, дигән догада калам. Мәхәлләнең бөтен кешеләренә дә, аермыйча, соңгы сәламнәремне җибәрәм.

Ихтирам белән, Гаяз Исхакый

Өстәмә. Бу хатны Галиулла Акыш исемле миллиятче яшь егет язды, чөнки үземдә хат язарлык көч юк. Язылганнарны минем фикерем итеп кабул итегез. Гали Акыш – минем иң ышанычлы ярдәмчем.

Сәламнәр белән, Г.Исхакый

«Бу хат язылып өч көн үткәннән соң, Гаяз Исхакый мәңгелек дөньяга күчте» [1:143 – 144].

Әдипне тәрбияләп-карап бакыйлыкка озатучы **Сәгадәт Чагатай**ның «Әтием Гаяз Исхакыйның соңгы көннәре» исемле хатирәсе үзенең тирәнлеге, детальләргә бай булуы, нәтиҗәдә – гаять төгәллеге белән аерылып тора: «Айның *(июльнең.* – **Р.М.***)* 19 нчы көнендә ул үзенең атропин дигән даруын эчмәде, иртәнге ашын да ашый алмады. Муниципаль хастаханәгә барып, бәвел кудыра торган укол ясауларын үтеним дип китәргә җыенган идем, әти туктатты, дөресрәге, хастаханәгә җибәрмәде. Көндез тагын икәү кара-каршы утырдык. Ул «бу күлмәгемне – теге кешегә, монысын бу кешегә бирерсең», дип әйтә башлагач, «әти, җаным, әле үзең киярсең» дигән сүзләргә «юк, юк», дип җавап кайтарды. Мин түзә алмадым, күз яшьләренә буылып, бүлмәдән чыгып киттем.

Бераздан керсәм, әти ашарга дип торган. Без аны сөяп утырттык, бераз сыр белән карбыз ашады, кофе эчте. Кызганычка каршы, күңеле болгана башлады. Төштән соң ул гадәттәгечә йоклап алды. Торгач, бергәләшеп чәй эчтек. Үзем генә булгач, аны залга алып чыга алмадым. Карават кырыенда гына утырдык. Кичкә таба Алиулла Акыш килде. Әти тагын утырмакчы булды, бераз капкалады. Кичке сәгать унга кадәр күңелле генә утырдык, сөйләштек. <...>

Сәгать уннан соң әтинең хәле яхшырып киткәндәй булды, урынга яткырдык. Сишәмбе көнне, 20 июньдә[1], иртәнге сәгать дүртләрдә торып өстенә яптым, ә сәгать җиделәрдә ул уянды. Урында утырган килеш кенә юындырдык. Соңгы дүрт-биш көндә иртән аны мин киендердем. Ашханәгә ул чиста күлмәк киеп, чәчләрен тарап, соңгы ике атнага кадәр үзе кырынып чыга торган иде. Иртәнге аштан соң бер-ике сәгать йоклап алды. «Күп йоклыйм бугай», – дип борчылып та куйды. «Аппетитың начар булгач, аз ашыйсың, шуңа күрә хәл җыяр өчен йокларга кирәк», – дип аңлаттык. Ул моның белән килеште. Төш вакытында тагын торды, икәү генә калгач, миңа тагын: «Син әле әниеңне дә күрерсең, аны рәнҗеткән булсам, гафу итсен», – диде. Күз яшьләремне күрсәтмәс өчен, бүлмәдән чыгып киттем. Мин кергәндә, тагын йоклап киткән иде.

Дүртенче унбиш минутка кадәр йоклады. Төштән соң шактый кунак килде. Шәфкать туташы килеп, ике сәгатьтән артык кан салу белән шөгыльләнде. Кан тамырларына тамчылап кына кан салу ялыктыргыч булып тоелды. Әтигә хәрәкәтсез ятарга туры килде. Шәфкать туташы киткәч, әти залга чыгып утырды. «Бик арыдың, ятып тор», – дигән сүзләрне кире какты. Бераз ашап-эчте. Соңгы вакытта бик аз ашады.

Чәршәмбе көнне, 21 июньдә[2], бөтенләй хәлсезләнде. Беренче тапкыр иртән күлмәк киюдән дә баш тартты. Пижама өстеннән халат кына киде. Даруны да эчмәскә иде исәбе, «ашый алмассың, хәлең булмас, шуңа күрә эчәргә кирәк» дип кенә күндердек. Иртәнге ашка утыртканда, әтинең башы калтырый башлады. Шулай да гәүдәсен төз тотты. Аягын урындыкка сузып утырды да бераз ризыкланып алды.

«Доктор Токайның баласы туган, минем хәлем әйбәт, барып күреп кайт», – дип, мине озатып калды. Кичке бишкә кадәр йоклады. Аннары залга алып чыктык, бал кабып чәй эчте. Кунаклар белән аралашты. Алар киткәч, утырган урынында йоклап китте. Уятырга кызганып, шунда гына мендәрләр куеп, урынын уңайладык. Ул үзе күтәрелә алмады. Кичке якта, сәгать сигезләрдә, Билал бәй белән Нәҗати Люгал бәй килделәр. Ул күзләрен ачты, ләкин хәрәкәтләнә дә, тора да алмады. Таһир аны күтәреп урынына салды. Яткан килеш Билал бәйләр белән сәгатькә якын сөйләшеп ятты. Сәгать тугызларда бик хәлсезләнеп китте. Миннән бераз карбыз һәм сыр сорап алды.

[1] Китапта яисә истәлекнең үзендә үк хата киткәнгә охшый: 1954 елның 20 июне якшәмбегә туры килә, 20 июль исә – сишәмбегә; мәкаләнең исеме дә июль вакыйгаларын яктырту бурычын ала.
[2] Июль булырга тиеш.

Әдип кызы Сәгадәт һәм кияве Таһир белән. Берлин. 1933 ел

Яңадан аның янына килгәндә: «Мин үз караватымдамы?» – дип сорады да гырлап йокыга китте. Бу аның соңгы сүзләре булды.

Төнлә ирем Таһир аңа бер-ике тапкыр су биргән, йомышларын үтәргә булышкан. Мин бик талчыккан идем, иртән сәгать җидедә генә уяндым. Бу 1954 елның 22 июле иде. Янына кердем, күзләре яртылаш ачык, куллары суына башлаган. Үземне кулга ала алмыйча, күз яшьләремә буылып, яныннан чыгып киттем. Телефон аша Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә бәйгә, Кәмал Локман бәйгә хәбәр иттем, Билал бәйне чакырып кеше җибәрдем.

Рәхмәт аларга, шунда ук килеп җиттеләр. Доктор чакырттык. Көндезге уникеләр тирәсендә генә килеп җитте. Шулвакыттан гырлавы көчәйде.

«Туңмыймы ул, каты авырту тоймыймы, укол ясап карасак, аңына килмәсме?» – дигән сорауларыма доктор: «Аның йөрәге туктый, берни дә сизми», – дип җавап кайтарды. «Теләсәгез, укол ясыйбыз», – диде. Таһир даруханәгә йөгерде. Тик ул кайтканчы эти гырлаудан туктады.

Унике сәгать ун минутта эти үзенең бөек җанын Аллаһка тапшырды» [1:198 – 200].

Күренекле азәрбайҗан дәүләт, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, журналист, драматург Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә истәлегендә Гаяз Исхакыйның соңгы сүзләре үзгәрәк рәвештә тәкъдим ителә: «Күзләрен соңгы тапкыр ачып караганда да, мәрхүм үзе алдында яраткан вә хөрмәт иткән кызы профессор Сәгадәт Чагатайны күреп: «Мин үз өемдәме?» – дип сораган һәм: «Әйе», – дигән җаваптан соң, бер сүз дә әйтәлмәстән, мәңгелек йортка киткән» [1:148].

«Азәрбайҗан» журналының 1954 елгы 4-5 саннарында имзасыз басылган «Мәрхүм Гаяз Исхакыйның җеназа мәрасиме» мәкаләсе әдипнең 76 ел Күк һәм Кояш хозурында булу тарихына нокта куя: «22 июльдә дөньядан кичкән Гаяз Исхакыйның җеназасы,

Мөһаҗирлеккә дучар булган ике бөек татар улы: Гаяз Исхакый белән Йосыф Акчура. (Аларның каберләре дә янәшә...) Истанбул. 1931 ел

үзенең васыяте буенча Истанбулга күчерелеп[3], Әдернәкапы шәһитлегендә газиз иптәше һәм бөек якташы Йосыф Акчура кабере янында җирләнде.

Аннан элек Анкара тимер юл станциясендә язучының дуслары һәм якын көрәштәшләре катнашы белән мәрхүмне искә алу мәрасиме булды. Соңра җеназа поезд белән Истанбулга китерелде. Идел-уралылылар, төркестанлылар, төньяк кавказлылар һәм азәрбайҗанлылар аны, күтәреп, Баязит җамигъ мәчетенә илттеләр. Анда җеназа намазы укылды, шуннан соң дуслары һәм мәдәният җәмгыятьләре тарафыннан китерелгән чәчәк бәйләмнәре белән бизәлгән машинада мәет Әдернәкапы шәһитлеге зиратына хәрәкәт итте. Чәчәк бәйләмнәре арасында Анкара һәм Истанбул «Төрек учаклары»[4] җибәргән икесе аерылып тордылар. Мәрхүмнең кабере башында беренче сүзне алтмыш еллык иптәше профессор Садри Максуди Арсал алды. Үксеп елаган тавышлар

[3] Истанбулда яшәгән Г.Исхакый, хәле начарая башлагач, 1954 елның 26 маенда кызы Сәгадәт янына Анкарага күчеп килә. Үлеменнән соң җәсәде Истанбулга китерелә һәм шунда җирләнә.
[4] «Төрек учаклары» – 1912 елда Төркиядә мәдәни максатларны күздә тотып оештырылган җәмгыять. 1931 елда Мостафа Кәмал паша әмере буенча ул Җөмһүрият-халык партиясе белән берләштерелә. 1949 елда җәмгыять яңадан тергезелә.

фонында мөхтәрәм Садри Максуди мәрхүм белән тәүге тапкыр танышуы, аның саф һәм идеаль гаилә мохите, бергәләшеп Идел-Урал төрекләренең милли уянуы һәм азатлыгы өчен эшләүләре, Гаяз Исхакыйның югары әдәби мәртәбәсе, зур осталык белән язылган әсәрләре һәм шулай ук бөек сәяси хезмәте турында сөйләде.

Бу нотыктан соң Көнбатыш Төркестаннан Б.Наим (Нәгыйм) һәм Көнчыгыш Төркестаннан Б.Иса (Гайсә) мәрхүмнең сәяси эшчәнлеге хакында сөйләделәр. Алардан соң сүз алган А.Ваһап Йортсәвәр[5], җөмләдән, түбәндәгеләрне әйтте: «Мәрхүм Гаяз Исхакый фәкать искиткеч әдип буларак тәкъдиргә лаек сансыз әсәрләр язып кына калмаган, ул бер үк вакытта күп санлы төрек-татар гаммәсенең көрәше һәм милли азатлыгы юлын сызган һәм азатлык өчен көрәш идарәсен үз өстенә йөкләгән идеолог һәм сәяси юлбашчы булган.

Гаяз Исхакый кабере. Анкара

Идел-Урал милли азатлыгы сугышы дигәч, хәтергә иң әүвәл фикер иясе, эшсөяр һәм эшлекле язучы һәм сәясәтче Гаяз Исхакый килә. Дуслары вә дошманнары аны шушы сыйфатлары белән белгәннәр һәм шушы сыйфатлары белән ул тарихка керде.

Гаяз Исхакый, бакый ял итү урынына сәфәр итсә дә, әле һаман да тормышка ашмаган бөек дәгъваны – Идел-Урал азатлыгы дәгъвасын – яшь буынга изге әманәт итеп калдырды. Яшьләр мәрхүмнең кабере янында бу изге әманәтне кабул итәргә тиешләр» [1:128 – 129].

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.* ■

Кулланылган әдәбият:

1. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 т. / Гаяз Исхакый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998 – 2014. 15 т.: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында истәлекләр һәм мәкаләләр/ [томны төз., текст., иск. һәм аңлат. әзерл. Г.Ханнанова, Р.Кадыйров; кереш сүз авт. Р.Кадыйров]. – 2014. – 527 б.

[5] Габделваһап Йортсәвәр – азәри язучысы һәм шагыйре, Төркиядә яшәгән.

Безнең мирас №4 апрель 2018

Макс Гатау шигырьләре *

УРАЛ МӘХӘББӘТЕ

Менә алмадык без бу тауларга,
Эчә алмадык чишмә суларын,
Канатсызлар булып яшәдек без
Төрмәсендә авыр елларның.

Йөрәкләрне ул чак яндырдылар,
Көйдерделәр газап утында,
Яктылыкны бездән яшерделәр,
Гомер иттек шулай тоткында.

Мин хәтерлим Урал даласында
Яңгыраган курай моңнарын.
Истә әле – күз яшьләрен түгеп
Ташлар ваткан эшче уллары...

Әрнетсә дә безнең йөрәкләрне
Авырлыгы үткән елларның.
Без шат хәзер: яңа тормыш белән
Матурланды Урал буйлары.

Ни генә юк Урал күкрәгендә:
Руда, металл, күмер, алтын да,
Мул бодайлар үсә дулкынланып
Күз күремең җитмәс кырында.

Җил улаган магнит кырларында
Гөрли хәзер биек домналар;
Чорыбызның батыр кешеләре
Җырлый-җырлый металл коялар.



М.Гатауның үзе исән вакытта басылып чыккан бердәнбер китабы

* Шагыйрь Макс Гатау (1913-1941) һәм аның туган җире – Курган өлкәсенең Әлмән районындагы Тозау авылы турында журналыбызның киләсе саныннан укырга мөмкин булачак. Ә хәзергә шагыйрьнең үзе исән вакытта басылып чыккан бердәнбер китабы «Урал мәхәббәте»ннән (1939) кайбер әсәрләре белән таныша торыйк.

Тракторлар эшли басуларда,
Яңгыратып урман буйларын,
Шат тойгылар биреп күңелләргә,
Ашлыкларны җыя комбайн.

Шаулап тора Урал заводлары,
Бөек төзү уты яндырып;
Энҗеләрен сибә ал йолдызлар,
Бар илләрне таңда калдырып.

Мин Уралда тудым, шунда үстем,
Елгасыннан барып су эчтем,
Бакчасыннан җимешләрен өздем,
Сандугачлар тавышын ишеттем.

Анам кебек якын миңа Урал,
Туган илем җире булганга,
Туган илем бакчасында Урал
Җимешле гөл булып торганга.

Ни генә юк аның күкрәгендә:
Руда, металл, күмер, алтын да,
Мул бодайлар үсә дулкынланып
Күз күремең җитмәс кырында.

1937 ел

АВЫЛЫМА

Мин хәтерлим, авылым,
синдә торганымны,
Күккә үрелеп үскән куе урманыңны,
Гөлчәчәктәй синең матур кызларыңны
Ник онытыйм, шулар тарта уйларымны.

Сине сагынып мин кунакка кайттым,
авылым,
Шундый гүзәл синең хәзер һәрбер ягың.
Колхозчылар гармун тартып җырлап уза,
Яңгырап тора синең якты урамнарың.

Һәр урында кайный бөек хезмәт даның,
Арыш, бодай белән тулган амбарларың.
Машиналар капитаны – кыз-уллары,
Мәктәпләрдә тырышып укый
йолдызларың.

1937 ел ■

Тозау авылындагы элеккеге мәчет бинасы. XIX гасыр. 2017 елгы фото

Безнең мирас №4 апрель 2018

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ!

ШАГЫЙРЬ МӨНИР МАЗУНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Мөнир Хәсән улы Мазунов 1918 елның 1 апрелендә хәзерге Пенза өлкәсенең Лопатин районындагы Иске Карлыган авылында туа.

М.Мазуновның шагыйрь буларак иҗади йөзе күбрәк нәниләр өчен язган шигырьләрендә – «Син дә белергә тиеш» (1955), «Энесенә ул апа» (1960), «Нәни төзүчеләр» (1967), «Уйнагыз, балалар!» (1985) һ.б. шигъри җыентыклар һәм бигрәк тә җырларында чагыла. Аның «Гасырлар кешесе» (Б.Мулюков музыкасы), «Туган як» (М.Мозаффаров музыкасы), «Язгы хисләр» (Р.Яхин музыкасы), «Яшьләр җыры» (Ә.Бакиров музыкасы), лирик характердагы «Әниемнең җылы кочагы» (Ә.Бакиров музыкасы) кебек җырлары халык арасында популярлык казана. Ул 1987 елның 31 мартында Казанда вафат була.

«Студент чакларымда миңа Мөнир Мазунов җитәкләгән «Татарстан кооператоры» гәзите редакциясендә эшләп алырга туры килде. Мөнир абый инде байтак китап чыгарган күренекле шагыйрь, тәҗрибәле журналист иде. Матбага эшенә, тәрҗемә күнекмәләренә беренче практик дәресләрне аннан алдым, диясем килә».

Флүс Латыйфи. *«Мөнир Мазуновның туууына 80 ел».*
(«Казан утлары», №4, 1998 ел)

НӘФИС СҮЗ ОСТАСЫ АЙРАТ АРСЛАНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Нәфис сүз остасы, артист һәм диктор, Татарстанның атказанган артисты (1957), Татарстанның халык артисты (1974), РСФСРның халык артисты (1981), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Гәрәй улы Арсланов 1928 елның 10 апрелендә Башкортстанның Бүздәк районындагы Ахун авылында туа.

А.Арсланов 2010 елның 23 апрелендә Казанда вафат була һәм Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнә.

«Айрат Арслан...
Әнә ул безнең тәрәзә каршысыннан үтеп бара – без алар белән күршедә яшибез. Өстендә кара-кучкыл төстәге озын плащ, башында (таушала төшсә дә) затлылыгын югалтмаган киез эшләпә, җилкәсендә шыплап тутырылган авыр букча. Алга иелә төшеп, салмак кына атлый бирә; ул әйтерсең лә ярты дөнья йөген иңенә салган да, җай гына тирбәлеп, киләчәгенә китеп бара...»

Наис Гамбәр. *«Сүз гаме».*
(«Мәдәни җомга», 3 апрель, 1998 ел)

КОМПОЗИТОР БАТУ МӨЛЕКОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1977), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984) Бату Гатаулла улы Мөлеков (Мулюков)1928 елның 17 апрелендә туа. Бабасы – Каргалы (Оренбург) мәчетенең мәзине, атасы математика укытучысы була. Бату башта гармунда уйнарга өйрәнә, соңрак мандолина, скрипка, рояль кебек уен коралларын үз итә. Төп әсәрләре: опералар – «Кара йөзләр» (1981), «Сөембикә» (1999), ораторияләр – «Казан» (1977), «Тукай» (1985), «Гасырлар һәм минутлар» (1987).

Б.Мөлеков 1999 елның 25 октябрендә (кайбер чыганакларда «23 октябрь» датасы күрсәтелгән) Казанда вафат була.

«Бүген композиторның иҗаты киңкырлы булырга тиеш. Ул җитди музыка да, опера, оратория, симфония дә һәм шул ук вакытта балаларга, үзешчәннәргә эстрада музыкасы да иҗат итәргә, бүгенге музыканың төрле өлкәсендә үзен сынап карарга тиеш дип саныйм. Бер сүз белән әйткәндә, барсын да булдырырга тиеш ул. Әмма бер генә таләп: барысының да югары биеклектә башкарылуы шарт».

Бату Мулюков*. 1995*

ДРАМАТУРГ СӘЕТ КАЛЬМЕТОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Драматург Сәет Гани улы Кальметов 1918 елның 20 апрелендә хәзерге Башкортстан Республикасының Яңавыл эшчеләр бистәсендә хезмәткәр гаиләсендә туа.

Сугыш бетеп, армиядән кайткач, С.Кальметов 1958 елга кадәр Ютазы, Буа колхоз-совхоз театрларында сәхнә рәссамы, актер, режиссер булып эшли. Буа театрында эшләгәндә, 1947 елда үзенең беренче сәхнә әсәрен – «Безнең кияү» исемле бер пәрдәле комедиясен яза. Пьеса Буа һәм Мамадыш театрларында куела. Драматургның икенче әсәре – «Тын алан шаулый» пьесасы (1951), Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. Шул ук театр сәхнәсендә драматургның 1953 елда «Нуриянең дуслары» исемле комедиясе куела. Шуннан соң ул Әлмәт драма театры белән иҗади хезмәттәшлектә 1954-1960 елларда «Соңгы очрашу», «Йолдызлар балкый», «Ышанычлы юлдаш», «Уйланырсың, кодагый», «Зәкия», «Сөенеч һәм көенеч» исемле пьесалар иҗат итә.

1992 елның 4 маенда Әлмәт шәһәрендә вафат була.

ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Ахунов Г. Усал телле драматург // Казан утлары. – 1968. – №5. – 143 б.
Әминов Ю. Тормыш белән күзгә-күз // Соц. Татарстан. – 1978. – 20 апр.
С.Кальметовның тууына 80 ел // Казан утлары. – 1998. – №4. – 190 б. ■

РАВИЛ ШӘРӘФИГӘ 80 ЯШЬ!

Равил Шәрәфине беләбезме?

Юныс Сафиуллин

– Артист Равил Шәрәфине беләсеңме? – дигән сорауга татар тамашачысының йөз кешедән кимендә туксан тугызы кычкырып көлеп җибәрер иде. Ягъни «Беләбез генәме соң, без әле аны яратабыз да!» диюне аңлатыр иде аларның бу эчкерсез көлүләре. Әйе, шушы матур апрель аенда үзенең 80 яшьлек юбилеен уздырып йөрүче, татар сәхнәсендә үлемсез образлар тудыра алган бу соклангыч артистны ничек инде белмәскә мөмкин? Ә менә сорауның: «Язучы Равил Шәрәфине беләсеңме?» – дигәненә бик санаулы кешеләр генә: «Әйе-әйе, каләме дә бар аның, кайбер язмалары бик ошаган иде», – дияргә мөмкиннәр.

Марсель Сәлимҗанов, галим Фоат Галимуллин белән әңгәмә корып утырганда, татар үз тарихын үзе язарга тиеш, дигән иде. Мин моны үземә күрсәтмә итеп алып, артистларга да кагыла бу, дип, алар арасында шушы юнәлештә эш итә башладым. Әле бит күптән түгел генә хәтта артист иҗатына багышлап эшләнгән радиотапшыруларда да артист турында сөйләргә билгеләнгән дежур иптәш гел бертөрле трафарет мәгънәләрдән торган, тормыштан

бик-бик ерак булган сүзләрне сөйләр иде. Шөкер, ул чорлар артта калды. Радионың алтын фондында талантларыбызның үзләре турында үзләре сөйләгән бик күп тапшырулары саклана хәзер.

«Безнең мирас» журналында яңалыкны кочак җәеп каршылаучы мөхәррирләр утыруын белгәнгә, Равил Шәрәфи янына килдем дә:

– Равил абый, кайчан әле тагы шундый форсат чыгар, үзең турында үзең җәелеп китеп, иркенләп, бернинди цензура-фәләннәрдән шикләнми генә үткен каләмеңне (әйе, аны тутыктыру гөнаһ) кабат эшкә җигеп, шул каләм очыңнан тама барган истәлекләреңне «Безнең мирас» укучыларына җиткереп барсаңчы? – дидем.

– Иркенләп, дигәнең ничә бит була инде? – диде Равил абый, күзләрен кыса төшеп.

– Иркенләп дигәнне дәвамлы дип аңларга кирәк, Сезне дөньяга биргән апрель ае журналында гына түгел, чираттагы саннарында да Сезнең каләм очыннан чыккан хатирәләр басыла барыр. Тәвәккәллисеңме?

– Тәвәккәл Тәгалләллаһ!

ӘЗ-МӘЗ ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Равил Шәрәфи

Әнинең әйтүенә караганда, мин 1938 елның язгы ташу вакытында дөньяга килгәнмен. Әгәр метрикага теркәгәннәре дөрес булып, мин чынлап та 5 апрель көнендә туган булсам, яз бик иртә килгән булып чыга бит ул елны! Туганымны хәтерләмәсәм дә, мөгаен, башка балалардан калышмаска тырышып, мин дә елап җибәргәнмендер, дип фаразлый алам. Ничек инде еламаска, мин бит репрессия дигән афәтнең нәкъ котырынган чагында, юлында очраган бер адәм баласын шашынып юк итеп йөргән чакларында туганмын. Шул чорда һәлак ителгән гөнаһсызлардан бик яраткан драматургым Кәрим Тинчуринны гына искә төшерсәк тә, репрессиянең халкыбызга, сәхнәбезгә нинди коточкыч бәлаләр китергәнлеге аңлашылыр.

«Американ» (К.Тинчурин). Равил Шәрәфи Искәндәр ролендә

Әтисе Шиһабетдин Шәрәфетдинов

Әнисе Шәмсезоха

Инде бик истә калган бер мизгел. Почмак бүлмәбез ишегеннән түр якка карыйм. Анда миңа поддуфкага (авылыбызда зур мичкә өстәп салынган мичне поддуфка (подтопка, дип йөртәләр иде) сөялеп басып торган ике метрлы әтием һәм аның каршында сәке тирәли утырышып чәй эчүче биш-алты кеше күренә. Әти аларга шыпырт кына нидер сөйли. Әллә ишетеп бетермәгәнлектәнме, әллә аңламагангамы, сүз ни турында барганлыгын хәтерли алмыйм. Бу кадерле күренештән артыгы куе томаннар артында калган: өч яшен тутырып дүртенчесе белән барган бала хәтере җитди нәрсәне үзенә сыйдыра алмагангадыр инде бу. Бик җитди кыяфәткә кергән әтиемнең биш-алты авылдашын авызына каратып сөйләп торган бу мизгеле 1941 елның җәй башларында, ягъни сугыш башланыр алдыннан булган булса кирәк.

Икенче истәлек олы абыем Шәйхетдин белән бәйле. Ул, сугышка китәсе яшьтәшләре белән җыелышып, һәр чакырулы өйгә, шул исәптән безнең өйгә дә кереп, җырлашып, саубуллашып йөрде. Алар китеп бер ай вакыт та үтмәгәндер, безгә кереп җырлап утырган авылдашыбыз Харис абыйның үлгәнлегенә хәбәр килеп ирешә. Кеше хәтере тишек иләк, дигәндәй, күп нәрсәне үзендә саклый алмый, ә менә Харис абыйның үкенечле үлеме әлегәчә хәтер түремнән аның кыяфәтен дә, исемен дә җуеп ташларга ирек бирми.

1945 елның май аендагы Җиңү бәйрәменә кадәрге арада, аеруча кыш көннәрендә өйдә бозау һәм сарык бәрәннәренә күз-колак булып утырып, урамда ниләр эшләнгәнен белә алмый интеккәннәрем дә искә килеп төшә. Абый белән апам – мәктәптә, әнием исә мал фермасында маллар карый. Ә мин бик ялгыз. Балачакта ялгызлыктан да күңелсезрәк нәрсә юктыр. Тәрәзәдәге бозларны тыным белән җылытып эреткәләп урамны күрергә тырышсам да, алар шундук кабат бозланып, берни дә күренмәслек хәлгә килә иде.

«Назлы кияү» (К.Тинчурин).
Равил Шәрәфи (уртада) Рәшит ролендә

Равил Шәрәфи Мәрҗани ролендә. («Каюм Насыйри». Х.Уразиков, М.Гали)

Николай Хоченков рәсеме

Кушканны эшләү белән бергә, үзлегемнән генә файдалы эшкә алынуым да шушы эчпошыргыч бер вакытта булды. Әни көне буе эшләп кичен генә арып-талып кайтып керер иде дә, беренче эше итеп мичне кабызып җибәрергә чыра әзерли башлар иде. Аның чыра пычагы алып нарат бүкәнен ничек итеп өй бусагасына терәп чыра телүләрен күп тапкырлар карап торганга, үземнең дә шуны эшләп карыйсым килдеме икән, әллә бәлкем әнине көтеп утырганда өзелеп ашыйсы килүләр искә төшкәндер дә әни эшен алдан ук үзем эшләп куясы иткәнмендер, кыскасы, әни кайткан төшкә байтак чыра телеп ташлаганмын. Шунда әнинең сөенә-сөенә: «Ай, улым, мулужис!» – дип үсендереп җибәрүе дә күңел түремне җылытып тора.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

Тарихи мизгелләрне мәңгеләштерүчеләр

Шаһинур Мостафин

...«Курай» радиосы мәркәзебез Казаннан даими алып бара торган «Хәтер яктысы» дигән тапшыруларга кызыклы шәхесләр еш чакырыла. Чираттагы әңгәмәбездә катнашу өчен студиягә Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, җөмһүриятебез журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, «Бәллүр каләм» иҗади бәйгесендә беренче булып төп призны яулаган тынгысыз эзтабар Нургали Хөсәен улы Булатовны дәштек. Хезмәттәш дусларның: «Аның төгәллегенә карап, хәтта сәгатьне дә дөресләргә була!» – дип әйтүләре хак икән. Өлкән каләмдәшебез-остазыбыз нәкъ билгеләнгән вакытка студиягә килеп тә җитте. Кулында – «Ватаным Татарстан» газетасының Хәтер һәм Кайгы көненә (22 июнь) багышланган саны. Анда Нургали абыйның «Изге ядкарьләр» дигән күләмле язмасы да басылган икән...

– Әтием турында язган идем әле, – диде ул. – Һаман да төшләремә керә. Акбүз атка атланган килеш керә, рухы шаттыр, мөгаен!.. – Аннары Нургали абый күңелендә кайнаган кайбер уй-фикерләре белән уртаклашты: – ...Әтисез үсүнең ни дәрәҗәдә кыенлыгын моны үз җилкәсендә, үз язмышында татыганнар гына белә. Шуңа күрә сугыш дигән афәтнең күпме кешенең башына җиткәнлеген, никадәр авырлыклар китергәнлеген һәрдаим сөйләп, искәртеп торасым килә. Юкса, хәтер саега, күңелләр коргаксый бара. Яу кырында һәлак булганнарга, шул мәхшәрдән исән кайтканнарга, тылдагы «шинельсез солдатлар»га – тол хатыннарга, сугыш чоры балаларына карата битараф булуны, гаделсезлекне һич кенә дә күтәрә алмыйм!..

Бу сүзләрдә Нургали абыйның тоткан кыйбласы, рухи ныклыгы, ихласлыгы бик ачык чагыла. Әйе, бихисап билгесез каһарманнарны, аларның якты исемнәрен, кылган батырлыкларын газета-журналлар, радио-телевидение тапшырулары аша халкыбызның күңел түренә җиткерүдә армый-талмый, үзенә генә хас үҗәтлек белән фидакарьләрчә эшләүче, республикабыз күләмендә киң билгеле, үткен каләмле, туры сүзле, якты күңелле, көчле шәхесләребезнең берсе ул.

Россия Федерациясенең Хәрби фәннәр академиясе президенты, армия генералы, академик Мәхмүт Гәрәев Казандагы якын дусты – эзтабар-публицист, танылган журналист, «Бәллүр каләм» иясе Нургали Булатов белән

Бу юлы да Нургали абый «Хәтер яктысы» тапшыруында сугыш һәм тыл батырлары, яшьтәш-чордашлары турында сөйләде. Бер уңайдан ул тыңлаучыларны газиз әтисенең Мари Илендәге Суслонгер урманнарыннан – Резерв фронтының әзерлек лагереннан, Ленинград өлкәсендәге Синявино сазлыкларыннан җибәргән кош теледәй хатлары белән дә таныштырып үтте. Шәмәхә карандаш белән язылган өчпочмаклы ул хатлар Нургали абыйның әнисенә – явыз дошманны тизрәк җиңү хакына тылда ат урынына җигелеп эшләүче Нәгыймә апага адресланган. Сугышка кадәр Теләче районының Алан авылында «Марс-2» күмәк хуҗалыгы рәисе булып эшләгән һәм броне була торып та фронтка үзе теләп китеп барган Хөсәен абый Булатов, яу кырында авыр яраланып, госпитальгә эләгә. Аягында гангрена башлангач, хәләл җефетенә соңгы хатын юллый: «Нәгыймәм! Аякны, өченче тапкыр, төптән үк кисеп карыйбыз, диләр. Исән калмасам, бәхил булыгыз...»

Күңеле дөрес сизенгән икән: Хөсәен абый 1943 елның июлендә Ленинград өлкәсенең Пикалево шәһәре госпиталендә вафат була...

Әтиләре дигәннән, Нургали абый әтисе каберен Бөек Җиңүнең 20 еллыгын билгеләп үткән истәлекле көннәрдә эзләп таба. Дөресрәге, аңа бу эштә Ленинград өлкәсенең Бокситогорск районындагы Новая урта мәктәбе эзтабарлары булыша. Алар, үзләренең туган җирләрен дошманнан азат итү өчен барган изге көрәштә кайнар канын түккән, газиз гомерен биргән Хөсәен Булат улы Булатовны – татар халкының гайрәтле, батыр улын тирәнтен хөрмәтләп, аның гаиләсен үзләренә кунакка чакыра. Әмма ерактагы ул җиргә – йөрәккә бик тә якын урынга! – һәркем дә бара алмый шул. Юллар озын-катлаулы, өстәвенә, күпме акча чыгымнары кирәк... Шуннан соң, гаиләдәгеләр, үзара киңәшләшеп, әтиләре җирләнгән төбәккә Нургали абыйны җибәрә.

Новая авылындагы Туганнар каберлегендә булганда, Нургали абыйның нинди хисләр кичергәнлеген бер Аллаһы Тәгалә белән ул үзе генә белгәндер. Мәһабәт обелисктагы «Рядовой Булатов Х.Б.» дигән юлларны укыганнан соң, Нургали абый аның алдында тезләнеп, әнисе өйрәткән догаларны укый һәм шул каберлектәге изге туфракны йөрәк турысындагы кесәсенә кадерләп салып, әтисе каршында ант бирә:

– Синең данлы исемеңне, фамилияңне моңарчы һәр җирдә горур йөрттек, Әтиебез!

Тыныч бул. Киләчәктә дә шулай булыр, Аллаһы боерса! Нәселебезгә тап төшерерлек, йөзебезне кызартырлык бер кыңгыр эш тә башкармабыз. Оныкларыңа да, бабагызның изге әманәте шул, диярмен...

Чыннан да, Хөсәен абый белән Нәгыймә апаның һәр баласы тормышта үз урынын тапкан. Нәсимәләре авылның уңган колхозчысы булса, Тимершәехләре тырыш игенчеләрдән саналды. Тикмәгә генә аңа «Татарстан Республикасының атказанган механизаторы» дигән мактаулы исем бирелмәде. Икесе дә туып үскән җирләрендә кешеләрне сокландырып, сөендереп яшиләр. Шанлы нәсел агачын тагын да нурландырып, күзләрне-күңелләрне иркәләп, бер-бер артлы оныклар да үсеп килә...

Нургали абыйның да әтисе алдында йөзе ак, намусы пакь. Нинди генә авырлыклар килсә дә, ул үзенең солдат Хөсәен Булатов улы икәнлеген беркайчан да хәтереннән чыгармады һәм тормыш сынауларын да җиңеп чыкты. Һәр эшне күңел биреп башкару сәләте, кешеләр йөрәгенә юл таба алу, хезмәтне оештыра белү осталыгы, мөгаен, күбрәк әтисеннән күчкәндер.

Нечкә күңелле, кешелекле бу шәхес – гомере буе барча тереклеккә, җан ияләренә, адәм балаларына гел изгелек-игелек кылып кына яшәүче сирәк затларның берсе. Туган авылында китапханә мөдире булып эшләгәндә дә, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда да, 15 ел буе «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй» журналы) газетасында һәм соңгы 25 ел дәвамында «Ватаным Татарстан», аннары «Мәдәни җомга» газетасында җаваплы вазыйфалар башкарганда да, кыйбласын үзгәртмичә, шул күркәм сыйфатларына тугры булып кала белде ул.

Нургали абый соңгы елларда татар генераллары һәм адмиралларына кагылышлы дистәләрчә очерклар язып бастырды. Аларга багышлап 2000 елда «Идел-Пресс» нәшриятында «Йолдызлы йолдызлар» дигән китап та чыгарды. Халкыбызның горурлыгы булган шул затлы шәхесләр турында үзе туплаган бай мәгълүматларны Татар энциклопедиясе институтына әзерләп тапшырды. Мәскәүдә, Россия Федерациясенең Кораллы көчләре Генераль штабында да аны яхшы беләләр. Россия Федерациясенең Хәрби фәннәр академиясе президенты, РФ Табигать фәннәре академиясе әгъзасы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, армия генералы, хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы Мәхмүт Әхмәтдин улы Гәрәев, генерал-полковник Рәсим Сөләйман улы Акчурин, хатыны Эльмираның бертуган абыйсы – генерал-майор, хәрби инженер, техник фәннәр докторы, профессор Рафаэль Мидхәт улы Юсупов, вице-адмирал, хәрби фәннәр докторы Марс Җамал улы Искәндәров һәм башка бик күпләр белән дустанә тыгыз элемтәдә тора ул. 1993 елның 19-21 феврале көннәрендә Мәскәүдә үткән татар генераллары һәм адмираллары җыенына да Татарстан журналистлары арасыннан иң беренче булып Нургали Булатов һәм аның якташы Рашат Низамиев чакырулы иде. Шуннан ике арада элемтәләр тагын да җанлана-ныгый төште...

* * *

Сүзебез яңадан Нургали абыйның әтисе җирләнгән Туганнар каберлегенә әйләнеп кайтты. Ул анда кат-кат булган икән инде...

–...Әтиемне югалту ачысының түзеп булмаслык дәрәҗәдә үзәгемне өзгәнен әнә шул каберлек янында аеруча ачык тоям-сизәм мин. Меңләгән-миллионлаган күзәнәгем белән... Сагыш һәм Кайгы кайчысы йөрәгемне-бәгыремне кат-кат телгәли шул мизгелләрдә... Сугыш утын кабызучыларга карата сурәтләп биргесез көчле нәфрәтем вулкан булып кайный күңелемдә! Миллионлаган җаннарны кыйган шул зилзилә-тайфун исән калганнарны да аямады бит. Аның зәхмәтле шаукымы әле һаман да үзен нык сиздереп тора...

Шулай да, Гаделлек тантана итәр көннәр дә бар икән әле дөньяда! Күп миллионлаган кешеләрне чиксез шатландырып, Халыкара хәрби трибунал фашист илбасарларга, япон

башкисәрләренә тиешле җәзаларын бирде. Нюрнберг, Токио процесслары турында әйтүем...

Нургали абый белән безнең әңгәмәбез турыдан-туры әнә шул чорда җиһанны тетрәткән тарихи вакыйгаларга барып тоташты...

***

Нюрнберг процессының барышы турында туган илгә телеграф аша мәгълүматлар җибәреп торучы сирәк кешеләр арасында якташыбыз да булганлыгын әле күпләр белми торгандыр. Ул – Кукмара районының Чишмәбаш авылында туып-үскән Нургали Нуриәхмәтов. 17 яшьлек егет 1943 елда Кызыл Армия сафларына алынып, башта автоматчы, аннары элемтәче була. Фашистларны эзәрлекләп, Берлинга кадәр барып җитә, аларны үз өннәрендә тукмый.

–...Берлин өчен барган сугышлар вакытында, – дип искә ала Нургали абый, – без, 260 нчы аерым элемтә батальоны составында, гаскәрләр арасында элемтәнең нормаль эшләвен тәэмин иттек. 1945 елның 1 маенда Берлин урамнарында идек инде. Шуннан соң да даими элемтә линияләрен төзәтүдә, ауган баганаларны утыртуда, өзек чыбыкларны ялгауда, Эльба аша яңа линия үткәрүдә эшләдем. Аннан соң мине, «Бодо» дигән телеграф аппаратында эшләргә өйрәнү өчен, Германияне оккупацияләгән совет гаскәрләре төркеме штабы карамагындагы аерым элемтә полкына укырга җибәрделәр. Укып чыккач, шушы штабта телеграфчы-бодист сыйфатында эшли башладым (безгә кадәр монда хатын-кызлар эшләгән, аларны демобилизацияләделәр). Без армияләр, корпуслар һәм Мәскәү белән элемтә тоттык. Нюрнбергта фашистларны хөкем итү башлангач, суд процессы материалларын турыдан-туры Мәскәүгә хәбәр итеп торуда катнаштым. Армиядәге бу көннәремне үзем өчен гаять истәлекле, бәхетле көннәр дип саныйм... Чөнки безгә Җиңү тантанасын күрергә дә, дөньяны яулап алып, күпләгән халыкларны кол итәргә теләгән фашистлар өстеннән гадел суд барганын Туган илгә шатлана-шатлана хәбәр итәргә дә насыйп булды...

Совет Армиясе сафларында барлыгы 7 ел хезмәт итеп, өлкән телеграфчы-сержант Нургали Нуриәхмәтов 1950 елда туган якларына кайтып төшә, авылда укытучы булып эшли башлый. Читтән торып Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Гомеренең дүрт дистә елдан артык өлешен балалар белән эшләүгә багышлый ветеран. Хезмәттәге фидакарьлеге өчен төрле елларда хөкүмәтебез бүләкләренә дә лаек була.

***

...Мөмкинлектән файдаланып, без, «Хәтер яктысы» тапшыруы аша, тыңлаучыларыбызны Нюрнберг процессында катнашкан атаклы якташыбыз Виктор Тёмин һәм аңа турыдан-туры бәйле гаҗәеп вакыйгалар белән дә якынрак таныштырып үттек. Чыннан да, исән чакта ук легендар шәхес булган Минзәлә егете Виктор Антонович! Алдына нинди генә максат куйса да, аны ахыргача үтәмичә торып, беркайчан да тынычланмаган. Гомумән, тынгысызлык, искиткеч дәрәҗәдә җитезлек-оперативлык, төп вакыйгаларның нәкъ үзәгендә кайнарга омтылу – аның өчен тормыш-яшәү кагыйдәсе булып әверелгән.

Шул уңайдан бер мисал. Безнең гаскәрләр Берлин урамнарына бәреп кереп, инде Рейхстаг янында көчле сугышлар алып баралар. Озак та үтми, Рейхстаг гөмбәзендә Җиңү байрагы җилферди башлый! Шушы тарихи мизгелне мәңгеләштереп калдыру өчен, В.Тёмин, кичекмәстән хәрби очкычка утырып, Берлин күгенә күтәрелә. Дошманның өзлексез уты, снарядлар шартлавы астында, ул, үтә салкын канлылык күрсәтеп, байтак объектларны, шул исәптән җиңелгән-җимерелгән Рейхстагны да фотога кат-кат төшерә. Аннары, снаряд ярчыклары очкычларының фюзеляжын берничә урыннан тишеп

Виктор Тёмин турында Советлар Союзы Маршалы Г.К.Жуков: «Бар җиргә дә өлгерә торган корреспондент!» – дип язып калдырган

үткәч, алар җиргә төшәргә мәҗбүр булалар. Виктор Антонович, күктә башкарган эше белән генә канәгатьләнеп калмыйча, шәһәрне штурмлаучы танкларның берсенә утырып, яңадан Рейхстаг янына китә. Совет сугышчылары элгән Җиңү байрагы фашизм өнендә әнә ничек горур җилферди! Җирдән, танк янәшәсеннән төшереп алынган шул фоторәсем арада иң уңышлысы була. Һәм аны тиз арада «Правда» газетасында бастыру өчен фоторепортер Тёмин Советлар Союзы Маршалы Жуковка мөрәҗәгать итә. Фронт командующие аңа Варшавага кадәр бару өчен шәхси очкычын биреп тора. «Аннан исә башка самолет белән Мәскәүгә очарсыз!» – ди Георгий Константинович. Әмма Виктор Антонович, булганы белән генә канәгатьләнмичә, әлеге очкычны башкалага кадәр үк алып китә. Мондый башбаштаклыкның ахыры бик күңелсез төгәлләнәчәген бөтен күзәнәкләре белән сизсә дә, Тёмин, үз карьерасын вә гомерен корбан итү бәрабәренә булса да, Рейхстаг өстендә Җиңү байрагы балкыганын беренче булып «Правда» газетасы аша бөтен дөньяга күрсәтәсе килә! Һәм Виктор Антонович шул изге теләгенә ирешә дә! Икенче көнне иртән иртүк Маршал Жуков очкычында Берлинга «Правда» газетасының өр-яңа санын (600 данәдә!) алып кайта ул. Шулчакта гына Георгий Константинович, әлеге «әрсез» фотохәбәрчене иң каты җәзага тарту уеннан кире кайтып, аны... тәвәккәллеге һәм оперативлыгы өчен, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкли!..

1946 елның октябрендә Нюрнбергта фашистларны хөкем иткән вакытта да, Виктор Антонович үзенең элекке гадәтләренә тугры булып кала. Биредә дә иң уңышлы кадрларны ул төшерә. Кеше ышанмаслык эшләр башкарырга сәләтле бу фоторепортер еш кына «үткен кылыч йөзе өстендә бии». Әйтик, аның үлемгә хөкем ителгән хәрби җинаятьчеләрнең соңгы минутларын – гәрчә югары җитәкчелек тарафыннан катгый кисәтелсә дә! – оста яшерелгән фотоаппараты ярдәмендә, башкаларга сиздерми генә төшереп алуы үзе генә дә ни тора?! Дөрес, әлеге фотоларны ул чорда тиз генә дөньяга чыгару мөмкинлеге булмый – нык тыела. Әмма Виктор Антонович өметен өзми. Гомер кояшы баер алдыннан гына ул шул тарихи фоторәсемнәрне үзенең китабында да файдалану җаен тапты. Һәм, шулай итеп, сугыштан соң туган төрле буын вәкилләренә моннан дистәләрчә еллар чамасы элек хәрби җинаятьчеләргә карата башкарылган гадел хөкем карарының ничек үтәлешен бөтен тулылыгы, чын дөреслеге белән күрсәтә алды...

«Тёмин феномены» озак еллар дәвамында бик күпләрне кызыксындырыр әле. Виктор Антоновичның тәрҗемәи хәле һәркемне сокландырырлык. Минзәләдәге «Туган як тарихы» музеенда төбәк эзтабарлары, аның шәхесен зурлап, искиткеч бай материал туплаганнар.

Алар арасында танылган журналист Әскәр Сабировның «Республика Татарстан» газетасының 2010 елгы 15 июль санында басылган «Рейхстаг с высоты репортерского полета» дигән, тулы бер битне иңләп торган күләмле язмасы да бар. Үз һөнәренең

Хәрби хәбәрче, Татарстанның халык рәссамы Мәхмүт Усманов (уртада) язучылар Гариф Ахунов, Фоат Галимуллин, Мәгъсүм Насыйбуллин, Рифә Рахман белән

ювелирдай чын остасы булган Виктор Антонович Тёмин (1908-1987) турындагы мәгълүматларга аеруча бай ул. Якташыбыз хезмәт юлын «Красная Татария» (хәзерге «Республика Татарстан») газетасында фотохәбәрче булып эшләүдән башлый. 1934 елда Виктор Антоновичны илебезнең шулчактагы үзәк газетасы «Правда»га эшкә чакырып алалар. Әлеге басманың төп фотохәбәрчесе буларак, аңа ил, дөнья күләмендәге үтә мөһим вакыйгаларны иң беренче булып яктырту бәхете елмая. Виктор Антонович Төньяк полюска оештырылган беренче совет экспедициясе, челюскинчыларны коткару эпопеясы барышын; Чкалов, Байдуков һәм Беляковларның рекордлы очышларын; Арктиканы буйсындырган «Таймыр», «Мурманск», «Ермак», «Садко» бозваткычларындагы көчле рухлы шәхесләрне – фоторәсемнәре һәм язмалары аша – киң җәмәгатьчелек игътибарына җиткерә. Аның Хәсән күле, Халхин-Гол елгасы буендагы, шулай ук «Маннергейм линиясе»н өзү, Берлинны алу өчен барган искитмәле сугышчан операцияләрне киң һәм тулы чагылдырган фоторәсемнәре дә үткәндәге тарихыбыз белән кызыксынучыларның күңелләрен тирәнтен дулкынландыра.

Сугыштан соңгы елларда Виктор Антонович «Известия», «Красная звезда» газеталары, «Огонек» журналы һәм ТАСС белән хезмәттәшлек итә. Гомеренең ахыргы көннәренә кадәр кулларыннан фотоаппаратын төшерми ул...

* * *

–...Хәзер безнең республикада Виктор Антоновичка охшаган кызыклы шәхесләр бармы? – дигән сорау бирде тапшыруыбызны алып баручы «Курай» радиосы хезмәткәре Сәрия ханым Тукаева.

– Ходайга мең шөкер, андый олуг затлар күңелебез күгендә һаман да балкып яши әле, – дидем мин дә үз чиратымда. – Үзебезнең милләттәшләребез арасыннан иң беренче булып элеккеге хәрби журналист, хәзерге вакытта Татарстанның халык рәссамы буларак киң билгеле Мәхмүт ага Усмановны зурлап телгә аласым килә!..

Татарстанның Кукмара районы Адай авылы егете, 3 нче Армия газетасы фотохәбәрчесе һәм рәссамы буларак, һәрвакыт иң кайнар урыннарга – алгы сызыкка ашкына, сугышчан иптәшләре белән Берлинга кадәр барып җитә. Алай гынамы әле?! Мәхмүт Усман улы фашистларның өнен – Рейхстагны штурмлауда да турыдан-туры

Донбасста туган милләттәшебез – Советлар Союзы Герое Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршин (1914-1947)

катнаша. Һәм аның түбәсенә-гөмбәзенә менеп, җимерелгән Берлинның аянычмескен халәтен, безнең каһарманнарның үлемсез батырлыкларын эскизрәсемнәрендә чагылдырып калдырырга омтыла. Шулчакта аның кулын дошман ядрәсе яралый – әмма рәссам-офицер үзенең яраткан шөгылен дәвам итә!..

Бәхеткә, Мәхмүт аганың әлеге чорда ясаган рәсемнәренең бер өлеше үзендә (калганнары – төрле музейларда) сакланып калган икән. Фоторәсемнәре дә... Соңгыларын рәссам, чит-ят күзләргә күрсәтмичә, үз остаханәсендә дистәләрчә еллар «тозлап» яткырган *(аларның шактый зур өлешен без «Казан» журналының Мәхмүт ага Усмановның күпьяклы иҗатына багышлаган махсус кушма санында (№ 1-2, 1996 ел) бастырып та чыгардык. –* **Ш.М.***)*. Ни генә әйтсәң дә, ул фоторәсемнәрдә – сугышның шомлы сурәте. Аларның һәркайсыннан явыз үлем ыржаеп карап тора кебек. Германиянең җимерелгән шәһәр һәм авылларын, завод һәм фабрикаларын, юлларын һәм күперләрен, дошманның тар-мар ителгән, ташлап калдырылган бихисап техникасын һәм башка сугыш коралларын, үлекләрен күреп, тирән тетрәнү хисләре кичердем мин. Моның үзенә күрә тагын бер сәбәбе бар: 1972-1973 елларда мин дә, алман җирендәге «Советская Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе буларак, Мәхмүт ага Усманов йөргән эзләрдән үткәнмен икән ләбаса! Хәзер инде ул урыннар искиткеч матурланган, төзекләндерелгән, гөлчәчәккә, яшеллеккә күмелгән... Сугыш чоры рәсемнәре белән хәзергеләрен чагыштырып карагач, Тынычлыкның никадәр кадерлетансык икәнлеген ачык тоясың. Шуңа күрә дә дөньяның төрле төбәкләрендә барган мәгънәсез сугышларга – канкоешка, үзара үтерешкә карата чиксез нәфрәт, ризасызлык хисләре күңелләрдә мартен мичендәге чуендай кайный да инде!..

«Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә!» – Мәхмүт ага үзенең картиналары, фоторәсемнәре аша кешеләргә әнә шул изге хакыйкатьне төшендерергә омтылды. Гомумән, сугыш һәм тынычлык темасы – аның күпьеллык иҗатының төп кыйбласы иде. Җиңү таңы атканнан соң, 1946 елда Казанга кайткач, гомеренең соңгы көннәренә кадәр һәр чын кеше күңелендәге рухи балкышны данлап, янәшә-тирәбездәге искиткеч гүзәл-сихри табигатебезне тирәнтен аңлап, илһамланып яшәде ул. Рейхстагны «яулаган» тәвәккәл егет сәнгать үрләренә дә ышанычлы төстә, кыю күтәрелде, мәшһүр рәссамга әверелде. Мөхтәрәм Мәхмүт ага Усмановның әсәрләрен Татарстан, Россия һәм элекке СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче халыклар гына түгел, Америка, Германия, Италия, Финляндия, Франция, Швеция, Япония кебек чит мәмләкәтләрнең сәнгать сөючеләре дә яхшы беләләр, аның олуг таланты алдында баш ияләр...

***

...Күренекле зыялыбыз – ару-талуны белми торган эзтабар әдибебез Шамил ага Рәкыйпов та Виктор Тёмин токымыннан! Мөхтәрәм Шамил Җиһанша улы, эзтабарлык эше белән дистәләрчә еллар дәвамында аеруча нәтиҗәле шөгыльләнеп, моңарчы

билгесез булган бик күп каһарманнарыбызга мәңгелек яшәү – Үлемсезлек бүләк итте. Очучы хатын-кызларыбыздан беренчеләрдән булып Советлар Союзы Герое дигән данлы исемгә лаек булган милләттәшләребез Мәгубә Сыртланова белән Ләйлә (Ольга) Санфирова, Алтын Йолдызлы партизаннардан Иван Кабушкин белән Гатаулла Минаев (Сергей Орлов), Рейхстаг гөмбәзенә беренче булып Җиңү байрагын кадаган татар егете Гази Заһитов һәм башка бик күпләр турында хәтерләрдән мәңге җуелмаслык тарихи-документаль әсәрләр тудырды, батырларыбызга иң асыл сүзләрдән мәһабәт һәйкәл койды ул...

*Мөхтәрәм авторыбыз – танылган язучы һәм журналист, мөхәррир, игелекле шәхес **Шаһинур МОСТАФИН** февраль аенда гомер бәйрәмен – 70 яшен билгеләп үтте. Шаһинур абыйны күркәм юбилее белән ихластан котлап, аңа саулык-сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез!*

***

«Хәтер яктысы» радиотапшыруы ахырында без Шамил ага Рәкыйповның «Таңнар һаман матурмы?» дигән әдәби-документаль әсәреннән милләттәшләребез арасында иң беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршин монологын да укып күрсәттек. (Мәгълүм булганча ул үзенең якын дусты – Советлар Союзы Герое Иван Чернопятко белән Токио процессында катнаша. Аннан кайтканда, ни кызганыч, аларның очкычы Тын океан өстендә авиаһәлакәткә очрый): «Әйтегезче, әйтегезче миңа: алсу таңнар һаман шундый матурмы? Тук башаклы басулар өстендә элеккегечә җилкенеп тургайлар сайрыймы, бакчаларда җимешләр кызарып пешәме, көн-төн гөрләп-гөрләп торган шахталар, завод-фабрикалар яныннан ыжгырып поездлар үтәме, кызлар элеккегечә үк сөйкемле һәм тырыш киленнәр уңганмы, егетләр хәзер дә батыр, ирләр хәзер дә гайрәтлеме?

Шулайдыр, шулай булмаска мөмкин түгел!

Ашаган ризыкның чын тәмен, чиста пакь өй эченең ямен, мәхәббәтнең гүзәллеген, дуслыкның эчкерсезлеген, бирелгән антның какшамаслыгын – тормышның чиксез матурлыгын өстән-өстән генә аңлаучылар булса, андыйларга минем хакта сөйләгез, мин җырлый алмый калган җырны җырлагыз!..»

***

Әнә шундый рухта, каһарманнарыбызга мәдхия җырлап, бихисап җаннарны уятып, күңелләрне кузгатып төгәлләнде «Хәтер яктысы» радиотапшыруының чираттагысы. Аның барышында без һәммәбез дә шул вакыйгалар эчендә кайнагандай булдык, кадерле кешеләребезне янәдән искә төшердек...

Әйе, Кояш кебек Хәтер утын, Хәтер яктысын берни дә сүндерә алмый. Җыр-моң белән дә шулай – барлык киртәләрне, каршылыкларны җимереп, дөньяга көчле ташкындай ургылып чыга ул!..

Хәтер һәм Моң – игезәк туганнар кебек! Дөньяны мәңгелек Мәхәббәт, үлмәс Моң, иманлы Хак сүз һәм Хәтер яктысы яшәтә... ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТОЕК *иск.* – каламбур, сүз уйнату. Сүзнең икенче, яшерен мәгънәсен тою. Нәкый Исәнбәт, төрек сүзе кулланып, «*гизле* [яшерен] мәгънәсен сиздерү» һәм «тоек» сүзе шигъри алым буларак әдәбиятыбызда искедән кулланылып килгән», дип яза, аннары моңа Кандалыйдан мисал китерә:

«Бу нидән булды чи генә,
Эшем дә җитте чигенә,
Сахибем кире чигенә,
Җавап бирсәңче, җанкайлә».

ТӨРКИ ТЕЛЛӘР – төрки телләрдә барлыгы 100 миллион чамасы кеше сөйләшә. Шулардан төрекләр – 65 миллион; үзбәк – 19,5 млн; азәрбайҗан – 8; татар – 7; казакъ – 6; уйгыр – 5; төрекмән – 3; кыргыз – 2; чуаш – 1,5; башкорт – 1,2; кашкай, афшар һәм Ирандагы башка төрки кабиләләр – 1; каракалпак – 0,4; якут – 0,3; кумык – 0,2; карачай-балкар – 0,15; тува – 0,15; кырым – 0,15; гагауз – 0,15; нугай – 0,1; алтай – 0,05; хакас – 0,05 миллион кеше. (Бу саннарның бераз искергәнлеген әйтергә кирәк.)

Төрки телләр төркемен берничә

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Мәшһүр Фирдәүсигә һәйкәл. Иран

төркемчәгә (подгруппа, субгруппа) бүлеп тикшерәләр. Мондый бүленеш (классификация) гадәттә географик урынлашуга нигезләнгән була. Татар һәм башкорт телләре, караим, кумык, каракалпак, нугай һәм казакъ телләре белән бергә, төрки телләрнең төньяк-көнбатыш төркемчәсенә *(кыпчак төркемчәсе)* керә. Чуаш телен исә *болгар-чуаш төркемчәсе* дип аерып та йөртәләр. Борынгы болгар һәм хәзәр телләре шушы төркемчәгә карый, ләкин бу үле телләр турында мәгълүмат бик аз.

Әлеге классификация буенча, төньяк-көнчыгыш төркемчәгә якут, тува, шор, хакас һәм борынгы уйгыр телләре керә, дип саныйлар.

Үзбәк теле төрки телләрнең көньяк-көнчыгыш төркемчәсенә карый.

Төрекмән, азәрбайҗан, гагауз һәм төрек телләре көньяк-көнбатыш төркемчәгә *(огуз яки төрекмән төркемчәсе)* кертелә.

Төрки телләр бүгенгә кадәр бербересенә якынлыкларын саклый алган, бу исә аларның кардәшлек мөнәсәбәтләрен өйрәнүне шактый җиңеләйтә.

//Юлына бер алтын биреп, Фирдәүси кеби даһилардан, фарсы әсатыйрларыннан зур поэмалар яздыручы Мәхмүд Газнәвиләребез, фән вә милли татарга хидмәт итеп бөтен гомерләрен үткәргән Олугбәк вә Әбелгази Баһадур ханнарыбызның, гарәп мәдәниятенең таҗында алмаз таштай ялтыраган Ибне Сина, Фарабиларыбызның исемнәрен ишеткәндә, әсәрләрен укыганда никадәр шатлансак та, үзебезнең төрек теле, төрек тарихы, иске төрек мәдәниятенә җитәрлек әһәмият биргән кешеләрнең чыкмавына, күбесенең төрек телендә язуны бер кимчелек санауларын күргәч, кайгырмыйча, көенмичә дә китәргә мөмкин түгел. Г.Шәрәф, 1917 //Иске төрек шагыйре Гали Ширнәваи үзе белгән өч телне – һинд, төрек, фарсы телләрен дөньядагы меңнәрчә үзе белмәгән, ишетмәгән телләргә әсас итеп куя. Җ.Вәлиди.

ТӨРЕК – Эпоним – төркиләрнең борынгы легендар бабасы, Нух пәйгамбәрнең оныгы, Яфәснең угланы. Төрекләргә хас булган бәгъзе рәсем (кагыйдә, тәртип-низам) вә гадәтләр шуңардан калган, дип сөйлиләр. Мичле өйне дә беренче ул чыгарган, диләр. Аның дүрт угылы булган: *Тутәк, Чигил, Барсаҗар* һәм *Әмлак*.

Вафаты алдыннан ул үз урынына Түтәкне падишаһ кыла. ■

Безнең мирас №4 апрель 2018

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

ШӘРЫК КУЛЪЯЗМАЛАРЫ ТУПЛАНМАСЫ

Милли китапханәдә шәрык кульязмалары тупланмасы саклана һәм әледән-әле яңа табышлар белән тулылана тора. Шушы юнәлештә 1992 елдан Казан (Идел буе) федераль университетының татар халкы тарихы кафедрасы укытучылары һәм студентлары белән берлектә археографик сәфәрләр оештыруның да нәтиҗәләре куандыра. Хәзер Шәрык кульязмалары тупланмасында төрки-татарча – 2078, гарәпчә – 402, фарсыча 77 берәмлек кульязма истәлек бар.

Урта гасырларда иҗат иткән шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы – Идел буе болгарларының дәүләтле чорыннан килгән әдәби сүзгә һәйкәл булырлык әсәр! Аның кулъязма нөсхәләре чит ил китапханәләрендә дә саклана, татар халкы яшәгән төбәкләрдә аерым күчермәләре һаман да табыла килә. Татарстан Милли китапханәсендә генә дә бу поэманың 28 кулъязма данәсе бар. «Кыйссаи Йосыф»ның китапханәдә сакланган һәм башка нөсхәләрдән үзенең палеографик үзенчәлекләре белән аерылып торган иң борынгы күчермәләренең исән калган кайбер өзекләре XVII гасырга карый. Алар 1993 елда Казанның «Болгар» мәчетендә табылды.

Болар арасында тагын 1852 елда типография ысулы белән басылган нөсхә бар, аның югалган битләре урынына өстәп, XIX гасыр шагыйре Гали Чокрый үз куллары белән язып, поэманы тулыландырган.

Ел саен оештырылган археографик сәфәрләрнең һәрберсендә диярлек бу әсәрнең кулъязма күчермәләре табыла тора.

Кыйммәтле кулъязма табышларыбыздан соңгыларының берсе – урта гасырларның Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» («Күңелләр нуры») поэмасының XVIII гасырда язылган күчермәсе.

Тупланмада иң борынгы саналган кулъязма XIV гасырга карый. Монда мөселман

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

юриспруденциясенә, астрономиягә караган язмалар, шулай ук гарәп тарихчысы Мөхәммәд әт-Табари хезмәтеннән өзекләр тупланган. Боларны күчереп кәгазьгә төшерүче – Дауд бине Мөхәммәд бине Хирыс бине Мөхәммәд бине Җәгъфәр.

Кулъязма китаплар арасында үзенең борынгылыгы һәм үзенчәлеге белән аерылып торучы «Көллияте Зәгыйфи» җыентыгына төрек мәгърифәтчесе Зәгыйфинең әсәрләре тупланган. Биш бүлектән торган җыентыкның беренче бүлегендә госманлы төрек телендә язылган шигъри әсәр урын алган, анда Зәгыйфинең тормыш юлы сурәтләнә. Калган бүлекләргә госманлы төрек телендә язылган прозаик әсәр, кыйммәтле асылташлар турында төрек теленә тәрҗемә ителгән китап, авторның солтанга һәм башка

әһелләргә язылган хатлары, гарәп телендә чәчмә әсәрләр кергән. Җыентык госманлы төрек телендә язылган шигырьләр шәлкеме белән тәмамлана. Бу китапның әһәмияте шунда ки, ул тулаем һәм бөтенләй авторның үз кулы белән язылган. Һәр әсәр соңында авторның үз исемен күрсәтүе моны раслап тора. Җыентыкның соңгы битләре 1557 елның 7 гыйнварында Константиния шәһәрендә (хәзерге Истанбул) язып тәмамланган. Күрсәтелгән датаның дөреслеген Ауропада эшләнгән кәгазьнең 1545-1554 елларда гамәлдә булган су билгеләре раслый.

Сәяхәтнамә жанрында язылган, фәндә билгеле булган кульязма чыганаклар арасында «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе» һәм «Мөхәммәдәмин сәяхәтнамәсе»нең, күренекле әсәрләр буларак, бездәге күчермәләре китапханәнең зур мактанычы булып тора.

XVII гасырга караган бик кечкенә, нәни Коръән – кульязмалар бүлегенең йөзек

кашы. Аны, күрәсең, Госманлы төрек империясендә күчереп язганнар. 428 битле, зурлыгы 7х9 сантиметр. Текст исә битнең тагын да кечерәк мәйданын (3х5 см) били, ул гаҗәеп матур хәрефләр белән каллиграфик камиллектә язылган, һәр бите алтын белән каймаланган.

Тупланмада Мөхәммәдсадыйк Иманколыйның шигырьләр җыентыгы бар. Ул аны 1891-1892 елларда, Бохарада укыганда, үз куллары белән язган. Бизәкләренә, хәрефләрне искиткеч матур бөгелешләр белән сәнгатьле язуына караганда, ул, һичшиксез, рәссам талантына ия булган. Җыентыкта Мәккә һәм Мәдинә шәһәре күренешләре, Нух пәйгамбәр көймәсе, хәрәкәттәге планеталар (астрономиягә нисбәтле сурәт), төрле төсләрдә буяп эшләнгән Азия картасы урын алган.

Кулъязма мирастан тагын татар дөньясының атаклы шәхесләре үз куллары белән язган чыганакларны әйтеп китик: болар – Габдерәхим Утыз-Имәни, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Ризаэддин Фәхреддин, Гали Чокрый, Шәһид Әхмәдиев, Гадел Кутуй һ.б. язмалары.

Тарихчы галим Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Апанаев, сәүдәгәр Үтәмешевләр, Ризаэддин Фәхреддин, Таиб һәм Гыйльман Яхиннар, тел белгече Үзбәк Байчураларның шәхси китапханәсеннән алынган кулъязма китаплар – тупланманың бәһасез байлыгы. Шагыйрь Мәүла Колыйның (XVII гасыр) «Береккәннәр сыйфаты», «Хәләл ризык теләүчеләр сыйфаты» кебек татар әдәбиятының ачышы саналган әдәби әсәр кулъязмалары тупланманың аерым бер мәртәбәле урынында тора. Кулъязмалар һәм кулъязма җыентыклар тупланмасының шактый өлешен татар, төрек һәм шәрык шагыйрьләренең әсәрләре били. Кайберләренең исемнәрен ачыклап китик: Хафиз, Зөхаер, Сәгъди, Бакыргани, Кол Гали, Кол Гобәйди, Кол Шәриф, Өмми Камал, Һәмдәми, Мәүла Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Рәхимкол углы Әбүбәкер, Әбелмәних Каргалый һ.б.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендәге кыйммәтле ядкәрләр арасында татар халкының тарихына багышлап язылганнары – Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» кебек хезмәтләре дә бар.

Шәрык кулъязмалары тупланмасы Милли китапханәдәге документлар фондының йөзек кашы санала. Бу тупланма татар язма мәдәниятен киләчәк дәверләр өчен күз карасы кебек саклауда бәһа биргесез хәзинә булып тора. ■

ТАШКИЧҮДӘ – «МӘРҖАНИ» МУЗЕЕ

Узган елның декабрь аенда зур вакыйга – Арча районының Ташкичү авылында атаклы дин галиме, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанигә һәм татар телендәге беренче тарихи роман авторы, журналист Мәхмүт Галәүгә багышланган мемориаль һәйкәлләр, мәктәпнең аерым бүлмәсендә «Мәрҗани» музеен ачу тантанасы булды. Әлеге чарада катнашкан мөхтәрәм шәхесләребезнең чыгышлары белән сезне дә таныштырырга булдык.

Илшат НУРИЕВ, *Арча муниципаль районы башлыгы:*
«Бер милләт булып яшәргә язсын!»

– Татар язучылары өчен «Мәккә» булган Арча районында, аның да Мәрҗаниләр яшәгән Ташкичү авылында басып торабыз. Без балаларыбызга үзебезнең тарихны җиткерергә, аны үзебез дә белергә тиеш, чөнки үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк, дип саныйм мин. Милли гореф-гадәтләребезне, телебезне саклап киләчәккә барырга, бер милләт булып яшәргә язсын!

Лотфулла ШӘФИГУЛЛИН, *«Таттелеком» АҖ генераль директоры:*

«Мәрҗанине онытсак, тел дә булмас, фикер дә булмас!»

– Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбһан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани – татар халкының иң күренекле кешесе. Ул – татарның Геродоты: тарихчы, этнограф, археолог, дин белгече. Ислам һәм төрки дөньяда аны белмәүче юктыр. Хөрмәткә лаек, мөхтәрәм хәзрәт... Без бу эшкә бик күптәннән әзерләнеп килдек. Үткән ел фикердәшләрем белән Ш.Мәрҗанинең туган нигезе Ябынчы авылында һәйкәл ачтык, «Мулла коесы»н өр-яңадан эшләдек. Шунда ук Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга да һәйкәл куйдык. Мәрҗанигә икенче һәйкәл – Ташкичүдә. Биредә эшләгән Мөдәррис Сәйфетдинов, Рөстәм Зәкуан, Рөстәм Гомәровларга зур рәхмәтемне белдерәм. Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә аеруча рәхмәтлемен. Ш.Мәрҗанигә бәйле фондларны барлаганда аның ярдәме искиткеч зур булды. Кызганыч, Шиһабетдин Мәрҗани әле тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Аның әсәрләрен татар укучылары өчен тәрҗемә итәргә кирәк. Урыс һәм башка милләт балалары да аны белергә тиеш! Без, Шиһабетдин Мәрҗанине онытмасак, алга барачакбыз, телебез дә, мәдәниятебез дә, фикеребез дә киләчәк буынга сакланачак. Әгәр дә инде Мәрҗанине онытсак, тел дә булмас, фикер дә булмас!

Рәфис БОРҺАНОВ, *Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры:*

«Мондый эшләрне башкарырлык сәләтле егетләребез бик сирәк»

– Акчалы кешеләр күп, ә мондый эшләрне башкарырлык сәләтле егетләр бик сирәк. Әлбәттә, бу – барыбыз өчен дә

үрнәк. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич әйтмешли, моны халыкка күрсәтергә, кулланырга кирәк. Иң беренчесе – тарихыбызны балаларга җиткерик. Әгәр дә без шулай эшлибез икән, бу киләчәк буынга да барып ирешәчәк. «Мәрҗани» музееның ачылуы, Арча халкына гына түгел, республикабыз, хәтта бөтен дөньяда яшәгән татарлар өчен дә зур тантана.

Илфар хәзрәт ХӘСӘНОВ, *мөфтинең рәсми органнар белән эшләү буенча урынбасары:*

«Мәрҗани – бөтен ислам дөньясының бөек шәхесләреннән»

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Аллаһы Тәгалә шушы күркәм чараларыбызны, җыеннарыбызны* мөбарәк кылса иде. Һичшиксез, әгәр дә агачның тамыры булмаса, ул корый. Халык та шулай ук. Милләт буларак сакланып калырга телибез, динебезне сакларга омтылабыз икән, үзебезнең тамырыбызны, үткән тарихыбызны өйрәнергә генә түгел, ә шәһит булганнарның исемнәрен дә белеп, әсәрләрен укып, алар белән горурланып яшәргә тиешбез. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре – безнең татар халкының гына түгел, ә бөтен ислам дөньясының бөек шәхесләреннән. Шунысы куанычлы: Шиһаб хәзрәтнең китапларын өйрәнә башладык, ләкин башка ислам дөньясында, Бәхрайн яки Мисырдамы, күптән инде аның китаплары, әсәрләре буенча мәдрәсәләрдә, ислам югары уку йортларында дәрес бирәләр. Аллага шөкер, менә без дә бөек шәхесебезне имам, галим, тарихчы буларак кире кайтардык. Киләчәктә, Раббым, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре яки башка галимнәребез булсынмы, аларның тарихларын өйрәнергә әлеге чаралар сәбәпче булса иде. Әссәләмү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! ■

*Узган елның 8 декабрендә Мәрҗани музее белән бергә тагын ике вакыйга – авылдан ерак түгел яңа төзекләндерелгән «Мәрҗани» чишмәсен һәм Симетбаш авылында «Нурислам» мәчетен ачу тантаналары да булган иде. Фоторепортаж – **beznenmiras.ru** сайтында.

КУКМАРА МИРАСЫ

КИЕЗ ИТЕКЛӘР ИЛЕ

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

БЕРТУГАН КОМАРОВЛАР

Кукмара авылында киез итек басу эшен иң беренче булып бертуган Комаровлар (гаилә башлыгы – Вятка губернасындагы Малмыж шәһәре мещаны Василий Алексеевич Комаров) җайга салып җибәрә. Бу якынча 1865 нче елларга туры килә. Башта кеше яллап эшләткән булсалар (әйтик, ике өлкән ир-ат, бер хатын-кыз һәм ике баладан торган гаилә, өзлексез 16-17 сәгать эшләп, бер көнгә 2-2,5 пар итек җитештерә алган), 1870 елдан соң исә Комаровлар эшне фабрикада алып бара башлый.

1890 елда Казанда узган фәнни-сәнәгать күргәзмәсендә Комаровлар хезмәте көмеш медаль белән бәяләнә. 1892 елның 19 декабрендә В.А.Комаров вафат була. Аның эшен уллары Николай һәм Сергей Комаровлар дәвам иттерә. Шул ук елны (1892) алар төп капиталы 20 мең сумлык булган «Бертуган Комаровлар» сәүдә йортын оештыра, үз эшләрен тагын да киңрәк җәелдерә башлый.

Комаровлар белән килешү нигезендә эшләүче Пётр Степанович Гусев калып ясаучы эшчеләр белән. 1910 ел

«Бертуган Комаровлар» сәүдә йорты бланкы

Брюссель күргәзмәсендә (1895) «Бертуган Комаровлар» сәүдә йортына бирелгән Зур алтын медаль

1896 елда фабрикада пар белән эшли торган машина ярдәмендә 32500 сумлык 10800 пар киез итек җитештерелә. Эшчеләр (якынча 75 кеше) елына 285 көн (12шәр сәгать) эшләгән.

Комаровлар Бөтендөнья һәм Бөтенроссия сәнәгать күргәзмәләрендә еш катнашкан. Әлбәттә, аларның хезмәте ул күргәзмәләрдә лаеклы бәясен алган: мәсәлән, 1895, 1905, 1907 елларда тапшырылган Брюссель күргәзмәләре медальләре, шулай ук Екатеринбург (1887), Харьков (1887), Казан (1890), Түбән Новгород (1890), Санкт-Петербург (1906) һәм Ростов-Дон шәһәрләрендә узган Бөтенроссия күргәзмәләрендә бирелгән медальләр шул хакта сөйли.

Фабрика янәшәсендәге ике катлы агач бинаның (хәзерге Вахитов урамындагы 2 нче йорт) беренче катында «Бертуган Комаровлар» Сәүдә йортының конторасы, ә икенче катта фабриканың хуҗалык-финанс эшләрен алып баручы Николай Васильевич Комаров хатыны белән урнашкан була. Мәгълүм Сәүдә йортының икенче хуҗасы – Сергей Васильевич Комаров үзе туган ике катлы агач йортта (хәзерге Ворошилов урамындагы

Комаровларның туган йорты. Бүгенге заман фотосы

6 нчы йорт) яшәгән. Бүгенге көндә ике бина да XIX гасырның архитектура һәйкәле булып санала һәм дәүләт тарафыннан саклана.

Фабриканың хуҗалык-финанс эшләрен алып баручы Николай Васильевич Комаров хатыны белән

«Бертуган Комаровлар» сәүдә йорты үз эшчәнлеге чорында фабрика белән язмышларын бәйләгән приказчиклар, эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең тулы бер династиясен (әйтик, Гусевлар, Черногубовлар, Симоновлар, Ошурковлар) булдырды. Бу уңайдан Михаил Алексеевич Ошурков биографиясе үзенчәлекле. Ул 1878 елда Вятка Аланында туган. Комаровлар фабрикасында тире белгече-приказчик вазыйфасын башкара. Михаил Алексеевич Түбән Новгород ярминкәсеннән (атаклы Мәкәрҗә ярминкәсе, дип аңларга кирәк) сыйфатлы тиреләр һәм тире үрнәкләре (анализ алу өчен) сатып алып кайта торган була. Миһербанлы бу кеше хатыны Анна Даниловна (1878-1959) белән бергә сигез бала тәрбияләп үстерә (ун баланың икесе бала вакытында ук вафат була). Шуларның дүртесе Комаровлар фабрикасында (соңыннан ул «Кызыл тукымачы» дип йөртелә башлый) эшли. Ошурковларның зур гаиләсе Комаровлар йорты (хәзерге Во-

Ошурковлар гаиләсе. XX гасыр фотосы

рошилов урамындагы 5 нче йорт) каршындагы өйдә яши. Михаил Алексеевич, Түбән Новгородка барып кайткан чакта үпкәсенә салкын тидереп, 1924 елның ноябрендә 46 яшендә вафат була. Аның бер улы – Иван Михайлович Ошурков 1930 нчы елларда ук фабриканың алдынгы эшчесы санала, уйлап табучы булып таныла.

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин (1954-2017), «Кукмара киез-киез итек комбинаты»ның 1988-2017 еллардагы генераль директоры:

«Элгәре елларда киез итекне солдатлар һәм эшчеләр генә кия иде. Соңга таба гади-гадәти киез каталарның рәвеше тулаем үзгәрде, аларга төрле бизәкләр, төсләр, уңайлы олтаннар өстәлде. Киез итек – Россиядә яшәүчеләр өчен менә дигән җылы, уңайлы аяк киеме! Өстәвенә, хәзерге киез итек тиз генә тузмый, ул бик нык-чыдам: аны озак еллар кияргә мөмкин».

КЫЗЫКЛЫ ФАКТ

Кукмара авылы фабрикантлары һәм сәүдәгәрләре, гадәттә, Малмыж, Мамадыш һәм Алабуга калаларыннан чыккан купецлар һәм мещаннар катлавына карый. Бу шуның белән аңлатыла: зур яки кече сәүдә эше белән шөгыльләнү өчен, «Шәһәр купецы» дигән таныкнамәгә ия булырга кирәк. Кукмара авыл саналганлыктан, җирле халык вәкиле, әлеге таныкнамәне алу өчен, якын-тирәдәге шәһәрләрнең берсенә мөрәҗәгать итәргә тиеш була. Моның үзенә күрә хикмәте дә бар: кечкенә шәһәрдән, әйтик, Малмыждан таныкнамә алу аеруча кулай саналган. Чөнки Казан белән чагыштырганда, Малмыжда салым түләү күпкә түбәнрәк булган. Шулай итеп, Кукмара кешесе бер кечкенә каланың купецы яки мещаны булып санала алган.

Тире иләү вакыты

Бертуган Комаровлар фабрикасының бер бинасы (хәзер ул әзер товар склады). Бүгенге заман фотосы

*Басмага **Ләбиб Лерон** әзерләде* ■

МАРТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 мартта Чистай районының Яуширмә авылында татар халкының бөек улы Гаяз Исхакыйның туууына 140 ел тулуга нисбәтле чара узды. Чарада язучылар – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Рабит Батулла, Марсель Галиев, Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Факил Сафин, Флера Тарханова, Рифкать Шаһиев, Миңзифа Әхмәтшина, «Безнең мирас» һәм «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Ләбиб Лерон һәм Рөстәм Галиуллин, галимнәр Лена Гайнанова, Фоат Галимуллин һ.б. катнашты.

● 1 мартта Казанның Бутлеров урамында урнашкан «Милан» ресторанында күренекле язучы-тәрҗемәче һәм журналист Саимә Ибраһим кызы Ибраһимовага 90 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды. Әлеге чарада юбилярны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин исеменнән аның урынбасары Римма Ратникова һәм Татарстан Мәдәният министрлыгының сәнгатьне үстерү һәм авторлык хокукларын яклау бүлегенең җитәкче урынбасары Рәшит Фәтхуллин котлады. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов хөрмәтле юбилярга каһарман-шагыйребез Муса Җәлилнең 110 еллыгы уңаеннан чыгарылган истәлек медален һәм М.Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилованың Рәхмәт хатын тапшырды. Юбилярны котлаучылар арасында Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Вахит Имамов, Вакыйф Нуриев, Шаһинур Мостафин, Рәмис Аймәт кебек язучы-шагыйрьләребез, шулай ук юбилярның дуслары Венера Ихсанова, Роза һәм Миралим Туфетуловлар, Зилә һәм Римзил Вәлиевләр, С.Ибраһимованың кызы Гөлнар Хәсәнова һәм юбилярның туганнары, Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин, «Сарман» якташлык җәмгыяте рәисе Нәсим Шәңгәрәев, журналистлар Хазбулат Шәмсетдинов, Фирая Бәдретдинова, Эльмира Закирова, Сөембикә Кашапова һ.б. бар иде. Кичәне Рабит Батулла, Камил Кәримов һәм Ләбиб Лерон алып барды.

● 1 мартта VII Бөтенроссия авыллары эшмәкәрләре җыены ачылды. Әлеге чара кысасында узган «Үзем уйныйм, үзем җырлыйм» татар җырларын башкаручылар III Бөтенроссия бәйгесенең гала-концертында «Татар авылы-2017» Бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрне котладылар. Бу конкурста эшләре югары бәя алган өч авторга – Наилә Потеева (Ульяновск), Зыятдин Нәҗметдинов (Киров өлкәсе) һәм Әнәс Сафуановка (Башкортстан) «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары Ленар Гобәйдуллин редакциянең махсус бүләген тапшырды.

● 9 мартта изге Болгардагы Ак мәчеттә Татарстанның һәм Ульяновск өлкәсенең дин әһелләре катнашында «XVIII Кулаткы укулары» узды. Район хакимияте башлыгы, эшкуар һәм меценат Эдуард Әнвәр улы Ганиев ярдәмендә уздырылган әлеге күркәм чарада Милли Шура рәисенең беренче урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р.Закиров, галимнәр Х.Миңнегулов, Җ.Мөхәммәтшин, Н.Таиров, И.Фәттахов һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон катнашты һәм чыгыш ясады.

● 19 мартта күренекле татар шагыйре, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты, 1990 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы Илдус Сабир улы Гыйләҗев вафат булды. Әдипнең җәсәде Азнакай районының Туйкә авылы зиратында җирләнде.

● 22 мартта Зәйдә Татарстанның халык язучысы Рабит Батуллага 80 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды.

Шундый ук кичә әдипнең туган авылы Шыкмайда да узды. Юбилярга нисбәтле әлеге чараларда Р.Батулланың каләмдәш дуслары – Марсель Галиев, Алмаз Хәмзин, Камил Кәримов, Данил Салихов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

● 23 мартта Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының Ислам һәм Ислам мәгарифе үсеше буенча Ресурс үзәгендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Ислам интеллектуаль мирасы һәм Татарстан өммәте» темасына лекцияләр курсын башлап җибәрде. Мөфти хәзрәтнең тәүге чыгышы «Имам Раббаниның рухи мирасы» булды.

● 23 мартта Азнакайда язучылар Р.Батулла, М.Галиев, А.Хәмзин, К.Кәримов, «Казан утлары» һәм «Безнең мирас» журналларының баш мөхәррирләре Р.Галиуллин, Л.Лерон район хакимияте башлыгы Марсель Шәйдуллин белән очрашты. Район китапханәчеләре, музей хезмәткәрләре, укытучылар һәм укучылар белән булган очрашуда исә каләм әһелләре ана телебезгә, әдәбиятыбызга һәм бүгенге матбугатыбызга нисбәтле чыгышлар ясады.

Шул ук көнне төштән соң язучылар Кәкре Елга мәктәбе мөгаллимнәре һәм укучылары белән дә очрашты. Язучыларны Азнакай район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев һәм район мәгариф бүлеге мөдире Альберт Рахманов озатып йөрде.

● 24 мартта Кукмарада язучылар һәм күп санлы кунаклар катнашында танылган шагыйрь һәм журналист Шаһинур Мостафинга 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды. ■

Мирасворд

Фәхрелислам ... (балалар язучысы)

Грек хәрефе

Ачыткы, камыр башы

Аббасов, Вергазов

Г.Тукайның 1911 елда язган шигыре

Борынгы Рим императоры

Хәсән Туфан поэмасы

Танылган рус шагыйре

Каеш пәрәкәсе

Рус хатын-кызларының борынгы бизәнү әйбере

Г.Тукайның 1909 елда язган шигыре

Аксыл кызыл

Хәрби дәрәҗә

АКШның Невада штатындагы шәһәр

Г.Тукайның яраткан кызы

Энә белән эре алдырып тегү

... барда кулың тый

Г.Тукайның 1911 елда язган шигыре

Житез, хәрәкәтчән, елгыр

Такта шомарту коралы

Җидегән чишмәдә ул җиде

Сөенү, куану

Г.Тукайның көйгә салынган шигыре

Тантаналы чакырулы мәҗлес (иск.)

Корьәннең беренче сүрәсе

Ефәк яки мамык тукыма

Язучы ... Хәсәнов

Орышу, тиргәү

... - ачык

Кунак ... - каракаршы

Ильясов, Халит, Надрюков

Умартада кәрәз җимерелеп төшмәсен өчен куелган агач

Эре бөртекле тыгызланган боз, кар

... Шәфигуллин

Туфан, Сарьян

Гурий Тавлин трилогиясе

Хат, записка (иск.)

Камыр чималы

«... оныгы» романы (Атилла Расих)

Кривой ...



Курган өлкәсендә татар, башкортлар куплап яши торган район

3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Расих, Ши, Адонис, тала, бөят, нәмаеш, «Самат», «Урал», раввин, чор, абыз, Уппсала, Наласа, сур, гид, шыгавыл, Гази, Шода, Риза, Бажан, Ак, ешу, йота.
Өстән аска: Бауман, «Батырша», ясавыл, Оже, Баттал, «Замандаш», уна, Ашот, чуагы, синантроп, «Ил», илә, Арпад, Хисамов, Гәрәй, Раев, иде, «ЛуАЗ», зат, Ниас, Итака.

Рәис Габдулла төзеде.

Татарстан Президенты Р.Миңнеханов һ.Такташның яңа ачылган һәйкәленә чәчәк сала. Казан. 30 август, 2017 ел

Михаил Фролов фотосы

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / АПРЕЛЬ

• 635 ел элек (1383)

Хәрәзем олысында Туктамыш хан исеменнән акча суга башлыйлар.

• 630 ел элек (1388)

Аксак Тимер, биниһая зур яу оештырып, Үргәнеч каласын җир белән тигезли, аның урынына тары чәчтерә.

• 240 ел элек (1778)

20 апрельдә мәгърифәтче, педагог, төрки телләр һәм татар теле белгече Ибраһим Исхак улы Хәлфин (1778-1829) дөньяга килә.

• 100 ел элек (1918)

13 апрельдә Үзәк мөселман комиссариатында Үзәк мәгариф коллегиясе төзелә. Мәгариф комиссарлары итеп Шәриф Манатов һәм Исхак Казаков билгеләнә.

• 95 ел элек (1923)

7 апрельдә Казанда язучы Фатих Халиди (1850-1923) вафат була.

12 апрельдә Дәүләт татар театрында «Җир уллары» спектакленең премьерасы була. Идея ролен әсәрнең авторы Һади Такташ башкара.

• 75 ел элек (1943)

3 апрельдә совет матбугатында «Ленинград фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына хаты» игълан ителә.

• 70 ел элек (1948)

2 апрельдә, «Алтынчәч» операсы (Муса Җәлил либреттосы) өчен, Нәҗип Җиһанов СССРның II дәрәҗә Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

• 60 ел элек (1958)

10 апрельдә Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе булдырыла.

• 45 ел элек (1973)

29 апрельдә күренекле татар совет композиторы Җәүдәт Фәйзи (1910-1973) вафат була.

• 25 ел элек (1993)

14 апрельдә Азнакай шәһәренең ике урамына язучылар Гариф Галиев һәм Мәхмүт Хәсәнов исемнәре бирелә.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Содержание. Апрель 2018

Историческое наследие: «Нурсултан». О.Иванова; «Москва и татарский мир»; «Кулаткинские чтения»; «Старая Пинигирь: судьба моей деревни в метриках». З.Назметдинов; «Трагедия «вилочников». Г.Мустафина-Рафикова; «Вклад татар в развитии Казахстана как государства». М.Каримов; «Поистине благовоспитана та нация, чьи женщины воспитаны...» Д.Гимранова; «Мусульманская газета» по случаю кончины Габдуллы Тукая» (заметки).

Татарский мир: «Совершение хаджа». И.Ахматзянов.

Тюркский мир: «Тукай, который просветил тюрко-татарский мир!» И.Карим; «Поэт, восхваляющий свой родной язык».

Литературное наследие: «Расстояние между Тукаем и Дусаем». М.Ахматзянов; «Наш Чингиз Айтматов». Р.Мирхайдаров; «Рано сошедшие с колыбели...» И.Фазлуллин.

В глубине памяти: «Стихи Макса Гатау»; «Вы знаете Равиля Шарафи?» Ю.Сафиуллин; «Немного о себе». Р.Шарафи; «В памяти, до сих пор в памяти!»; «Ветер дождя» – лечебный ветер». Э.Шарифуллина.

Эхо войны: «Люди, увековечившие исторические события». Ш.Мустафин.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Музей Марджани в деревни Ташкичу»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Content. April 2018

Historic heritage: «Nursultan» by O.Ivanova; «Moscow and the Tatar world»; «Reading in honor of Kulatka»; «The Old Pinigir: the destiny of my nation in birth certificates» by Z.Nazmetdinov; «The forklifts' tragedy» by G.Mustafina-Rafikova; «The Tatars' contribution to the development of Kazahkstan» by M.Karimov; «Really well-bred is that nation whose women are well-bred...» by D.Gimranova; «The notes in the «Muslim newspaper» in the event of Gabdullah Tukay's death».

Tatar world: «Doing hagj» by I.Akhmatzyanov.

Turkic world: «The very Tukay who enlighted the Tatar-Turkic world!» by I.Karim; «The poet glorifying his mother tongue».

Literary heritage: «Distance between Tukay and Dusay» by M.Akhmatzyanov; «Out Chingiz Aitmatov» by R.Mirkhaydarov; «Passed a long time that we grew up from» by I. Fazlullin.

From the deepest storage of memory: «The poems of Max Gatau»; «Do you know Ravil Sharafi?» by U.Safiullin; «A little bit about myself» by R.Sharafi; «Keeping the memory, still keeping!»; «The wind of the rain is the healing one» by E.Sharifullina.

The war's echo: «People immortalizing the historic events» by Sh.Mustafin.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «Mardjani museum is at the Tashkichu village»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

ТУКАЙГА МӘДХИЯ

Валерий СКОБЕЕВ «Тукай портреты».
Киндер, майлы буяу

Алсу ТИМЕРГАЛИНА «Шүрәле».
Кәгазь, акварель

Ирина КОЛМОГОРЦЕВА «Тукайның балачагы. Кырлай». Кәгазь, офорт

«Яуширмә». Наилә Потеева

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Маргарет ханым – татарларның дусты. Себастьян Цвиклинский
«Нимесчә аш». Эльмира Сәлахова
Иске Җөринең борынгы ядкәре. Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев
Русия мәмләкәтендә аутодафе. Ринат Фәхретдинов
Катай авылы һөнәрчеләре. Таһир Кәримов
«Кәлам-е шәриф»ме, әллә «Кәлам шәриф»ме? Айдар Хәйретдинов
Икшермә чиркәве. Гөлүсә Закирова
Яуширмә. Наилә Потеева
Аяз Гыйләҗев һәм мин. Фатих Кутлу

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.